ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№1 (325) – ГЫЙНВАР 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

«Россия Давосы» кырларында

Кырыс чорның көләч кешесе

Мәшһүр ханбикәләр: Нурсолтан

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Сафа Гәрәев, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: милли дизайнер Алсу Мусабирова
Фото: Ната Смирнова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-90
Басарга кул куелды: 25.01.19
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Сату бүлеге белгече: Гүзәл Подольская
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

2019: СИННӘН НИНДИ ЭЗ КАЛЫР?

Еллар очар кошларга тиң. Әмма, ни кызганыч, кошлардан аермалы буларак, кайта-китә йөрмиләр. Дөресрәге, без аларның, бер киткәч, кайда югалганын белмибез дә... Ничек эзләп табарга да, янә кайтарырга үзләрен? Эһ, серенә төшенсәң икән...

Юк шул, кеше тормышындагы мизгелләрне канаты белән сыпырып алып, очалар да юк булалар. Үзеңнең дә, 365 көн дәвамында янәшәдә яшәгән якыннарыңның да хәтерендә җете истәлекләр, теге йә бу белем-күнекмәләр, очрашу-аерылышуларның, шатлык-көенечләрнең, туу-үлемнәрнең эзе генә кала.

2018 ел инде галәм календарендә үз эзен калдырып китеп барды, мирас булып әверелде. 2019 ел әле адымнарын тизләтергә дә өлгермәде. Нинди эз калдырыр ул безнең тормышта – билгесез. Хәер, вакытыннан алда юрап кую нигә? Ул безнең белән булганда, һәр мизгеленнән тәм табып яшәп калыйк: истәлекләр, белемнәр туплыйк, очрашу, аерылышуларны йөрәк аша уздырыйк... Бернәрсә дә – яхшымы ул, яманмы – юкка гына бирелми ләбаса! Асылда, барысы да – яхшыга, һәр вакыйганың үз эчке мәгънәсе бар...

2019 елда яшәгән арада без калдыра барган олы эзләр әллә ни күзгә ташланмаска да мөмкин. Әмма 2020 елда инде без аларны яхшырак күрәчәкбез.

Иң мөһиме: әшәке эз калдырмыйк... Аяк киемен дә, уйларны да чиста тотарга кирәк, димәк!

СЕЗНЕҢ ЯҢА ЕЛ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

«Кунакка» Илдар Зарипов, 2001 ел

ЯНВАРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

5. Кремль, өметләр чыршысы. Президент ничек итеп Яңа ел хыялларын тормышка ашырды

12. Ташаяк һәм Мәскәү урамнары чатында. Урам исемнәрен ничек тәрҗемә итәргә

20. Алтын киләчәк. Ничек оста зәркәнче булырга

22. Милли киемнәр. Эшкуарлык нинди хәлдә

26. Авыллар турындагы китаплар. Белгечләр белән сөйләшү

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

32. Аш-су. Тутырган тавык пешерү осталыгы

36. Бәхет ачкычлары. Фатир мәсьәләсен ничек хәл итәргә

40. Күңел бизәкләре. Иң матур чыршы кайсы районда

48. Фаворитлар көндәше. Премьер-лига лидерлары кемнән курка

58. Борынгы ядкарьләр. Кенәз Оболенский тегермәне кайда яшеренгән

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

64. Кече ватан патриотлары. Кырыс чорның көләч кешесе

70. Безнең киштәдә. Татар аудиокитапларын ничек табарга

74. Тарих сәхифәләре. Мәшһүр ханбикәләр: Нурсолтан

84. Татар авыллары. Кече Елгага рәхим итегез

88. Астрологик фараз. 2019 елда Татарстанны ниләр көтә

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

12.01

Марат Әхмәтов, ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, – Татарстан Республикасының Хөкүмәт йортындагы киңәшмәдә:

– Лаеклы хезмәт хакы – иң яхшы стимул. Бөтен җитәкчеләргә моны аңларга вакыт инде, тик, ни кызганыч, күпләр моннан әлегә ерак. Авыл хуҗалыгында хезмәт хакын икътисадтагы шикелле уртача күләмгә җиткерү буенча эшне без активлаштырачакбыз, шул исәптән хезмәтне фәнни оештыру буенча галимнәр белән хезмәттәшлекне ныгыту, сакчыл җитештерү һәм хуҗалык исәбе мөнәсәбәтләре принципларын уңышлы кулланучы иң яхшы хуҗалыкларның тәҗрибәсен тарату ысулы белән дә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

31.12

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты, – татарстанлыларга Яңа ел мөрәҗәгатендә:

– Иҗади хезмәт нәтиҗәсендә 2018 ел республика өчен уңышлы булды. Бүген безгә заманча яңа җитештерүләр ышаныч бирә, сәламәтлек саклау белән мәгариф, мәдәният һәм спорт объектлары сөендерә. Безнең шәһәр һәм авылларыбыз уңайлы скверлар һәм парклар белән бизәлде. Барлык социаль программалар тормышка ашырылды.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

22.12

Салават Фәтхетдинов, җырчы, Россиянең атказанган артисты, Татарстанның халык артисты, – «Пирамида»да узган «Татар җыры» фестивалендә:

– Сәхнәдә яшьләр күбрәк булсын, балаларыбыз татарча сөйләшсен, татар моңы югалмасын иде – әнә шул чакта безне онытмаслар.

Фото ТР Президенты сайтыннан.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Президент **КЕМНЕҢ** Яңа ел хыялларын тормышка ашырды

Урам исемнәрен **НИЧЕК** тәрҗемә итәргә

Оста зәркәнчеләрне **КАЙДА** әзерлиләр

Милли киемнәрне таныту өчен **НӘРСӘ** җитми

Авыллар турындагы китапларга белгечләр **НИНДИ** бәя бирә

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Казан ханлыгының беренче ханы кем булган
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

МӘСКӘҮ. КРЕМЛЬ.
МИҺЕРБАНЛЫК ҺӘМ ӨМЕТ ЧЫРШЫСЫ

ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды.

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Дәүләт советының ихтыярилык хәрәкәтен үстерү сорауларына багышланган утырышы кысаларында уздырылган «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясендә катнашты.

КАЙДА:

МӘСКӘҮ, Кремль

КАЙЧАН:

27 декабрь

ТУЛЫРАК:

Халыкның социаль якланмаган катлаулары вәкилләренең (сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле затлар, ятим балалар, күп балалы гаиләләрдәге балалар, катлаулы тормыш хәлләренә тарыган затлар, каты авыруларга дучар булган балалар һәм өлкәннәр) гамәлгә ашмастай хыял-теләкләрен үтәү – Яңа ел акциясенең бурычы әнә шул иде. Россия Дәүләт советы утырышында катнашучыларның барысы өчен дә әлеге акциягә кушылу мөмкинлеге тудырылды. Моның өчен Малахит фойеда һәм Александр залында россиялеләрнең хыяллары язылган открыткалы уенчыклар белән бизәлгән ике чыршы урнаштырылган иде. Федераль түрәләр һәм төбәк җитәкчеләре, хыяллар язылган открыткаларны сайлап алганда, алдан ук аларның 2019 ел дәвамында һичшиксез үтәлергә тиешлеген беләләр иде.
Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Яңа ел чыршысыннан берьюлы өч уенчык алды. Нәтиҗәдә аңа 13 яшьлек Камил Бариевның һәм Владислав Банцыревның, һәм шулай ук Казан төзелеш көллияте студенткасы Полина Щербичның хыялы язылган открытка туры килде. Полина – Мәскәү Кремлендәге Чыршы бәйрәмендә катнашу, Камил – үз күзләре белән «Уральские пельмени» тамашасын күрү, ә Владик бүләккә таган алу турында хыялланган икән.

Шуны да хәбәр итәбез: журналыбызның әлеге саны дөнья күргәндә Татарстан балаларының барлык өч хыялы да тормышка ашырылган иде инде.

БЕЛЕШМӘ:

«Теләкләр чыршысы» Яңа ел акциясе «Минем белән бергә хыяллан» волонтерлык хәйрия проектының бер өлеше булып тора. Проект тормышларына куркыныч янаган авыруларга дучар булган балаларның (3 яшьтән 17 яшькәчә) һәм өлкәннәрнең (60 яшьтән өлкәнрәкләр) теләкләрен тормышка ашырырга ярдәм итүгә юнәлдерелгән. 2018 ел ахырында проектта Россия Президенты Владимир Путин катнашты. Ул тормыш өчен куркыныч авырулары булган биш баланың хыялын чынга ашырды. Исегезгә төшерик: дәүләт башлыгы Мәскәүдә узган Халыкара ихтыярилык форумы вакытында балаларның хыяллары язылган биш конвертны алды. Кремльдәге акция вакытында, кагыйдә буларак, шулай ук бер-ике открытка алу белән генә чикләнмәделәр. Мәсәлән, Мәскәү мэры Сергей Собянин өч хыялны гамәлгә ашырырга булды, Кырым башлыгы Сергей Аксенов исә дүртне чынга ашырачак.

БГӘ.
«БУРДЖ ХӘЛИФӘ» КҮЛӘГӘСЕНДӘ

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Emaar Properties компаниясе башлыгы Мөхәммәд Али Рәшид Әл-Аббар әфәнде Дубайда коммерциячел һәм торак күчемсез милек өлкәсендә уртак проектларны гамәлгә ашыру перспективаларын тикшерде.

КАЙДА:

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре

КАЙЧАН:

30 декабрь

Фото Татарстан Президенты рәсми сайтыннан алынды.

ТУЛЫРАК:

Гарәп эшлекле дөньясында иң зур йогынтыга ия шәхесләрнең берсе, Emaar Properties компаниясе башлыгы һәм Гарәп эшлекле советына нигез салучы Мөхәммәд Али Рәшид Әл-Аббар белән очрашу Рөстәм Миңнехановның эш сәфәре кысаларында Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә уздырылды. Emaar Properties компаниясенең халыкара дәрәҗәдәге отельләрен, молларын, офис үзәкләрен, заманча торак комплексларын төзүдәге һәм аларга хезмәт күрсәтүдәге тәҗрибәсе, инвестицион куәте Татарстанга, һичшиксез, кызыклы. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: нәкъ менә Emaar Properties дөньядагы иң биек бина – 828 метрлы «Бурдж Хәлифә»не төзеде, ул дөньядагы иң эре «Дубай Молл» сәүдә үзәгенең иясе һәм операторы булып тора. Компаниянең вәкиллекләре җир шарының 11 илендә эшли. Үзәк офис Дубайда урнашкан. Әңгәмә барышында ике як та уртак проектлар перспективаларын тикшерде. Татарстан Президенты Emaar Properties рәисен 2019 елның 24–26 апреле көннәрендә Казанда узачак XI «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисад саммитында катнашырга чакырды.

БЕЛЕШМӘ:

Emaar Properties компаниясенә 1997 елда БГӘндә нигез салынган. Эшчәнлекнең төп юнәлеше – Фарсы култыгы районында, нигездә Дубайда һәм Әбу-Дабида, барган төзелеш проектларына инвестицияләр кертү. Компания гарәп дөньясында иң эре девелоперларның берсе, төзелешнең төрле стадияләрендә булган 14 000нән артык бина аңа карый. Emaar Properties компаниясе шулай ук Gold and Diamond Park паркының хуҗасы һәм идарәчесе. Согыд Гарәбстанында компания диңгез портын, сәнәгать зонасын, эшлекле районны, мәгариф һәм медицина учреждениеләрен, сәүдә объектларын, һәм шулай ук курорт һәм торак районнарны үз эченә алган King Abdullah Economic City (KAEC) масштаблы проектының төп төзүчесе булып тора. Emaar Middle East – Emaarның бүлендек компаниясе, мәйданы 500 000 кв. метр булган Jeddah Gate-яңа Джидда сәүдә үзәген төзү белән шөгыльләнә.

Мөхәммәд Али Рәшид Әл-Аббар – Emaar Properties компаниясенең Директорлар советы рәисе. Дубай башкарма комитеты составына керә. 2006 елда ул Arabian Business журналы версиясе буенча 50 иң зур йогынтыга ия гарәп рейтингында 6 нчы урынны биләгән.

МӘСКӘҮ.
«РОССИЯ ДАВОСЫ» КЫРЛАРЫНДА

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Россия һәм дөнья: үсешнең милли максатлары һәм глобаль трендлар» X Гайдар форумы эшендә катнашты.

КАЙДА:

Мәскәү

КАЙЧАН:

16, 17 гыйнвар

Фотолар ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды.

ТУЛЫРАК:

Форум кысаларында «Үсешнең милли максатлары: Россия стратегиясе 2018–2024» пленар дискуссиясе үтте. Төп спикерлар сыйфатында РФ беренче вице-премьеры – Россия финанслар министры Антон Силуанов, Россия Федерациясе Хисап палатасы рәисе Алексей Кудрин һәм Мәскәү мэры, Дәүләт советының РФ Президентының Май указларын гамәлгә ашыру сораулары буенча эшче төркеме җитәкчесе Сергей Собянин катнашты. Антон Силуанов хәбәр итүенчә, агымдагы елда Хөкүмәт эре проектларны гамәлгә ашыруда бизнес-җәмәгатьчелеккә ярдәм итәчәк, төрле проблемаларны, аерым алганда, административ каршылыклар белән бәйлеләрен хәл итәргә булышачак. Вице-премьер сүзләренә караганда, бүген бизнеска табышын икътисадка инвестицияләргә булышырга тиешле стимул чараларын күрү буенча эш алып барыла. Алексей Кудрин, үз чиратында, хәзерге вакытта милли проектларда барлык җитди структур адымнарның барысының да язылмавы турындагы фикерен белдерде. Хисап палатасы җитәкчесе өстәмә чаралар эшләргә тәкъдим итте, алар планлаштырылган икътисадый үсешкә этәргеч бирәчәк. Мәскәү мэры Сергей Собянин фикеренчә, Россия икътисадындагы ыргылыш өчен эре агломерацияләргә игътибар итәргә, аннан соң эзлекле рәвештә калган территорияләрне үстерергә кирәк. «Эре агломерацияләрне үстерми, инвестицияләрне тупламый торып, инновацияле икътисадның алга китеше дә, хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше дә булмаячак», – дип нәтиҗә ясады ул.

Гайдар форумы кысаларында Россиянең Инновацияле төбәкләре ассоциациясенең гомуми җыелышы узды. РИТА рәисе итеп яңадан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сайланды. Алга таба катнашучылар Ассоциация эшчәнлегенә кагылышлы сорауларны тикшерделәр. Форумда Россиянең инновацияле төбәкләре рейтингы йомгаклары игълан ителде. Рейтингта беренче урынны – Санкт-Петербург, икенче урынны – Татарстан, өченче урынны Мәскәү алып тора.

БЕЛЕШМӘ:

Гайдар форумы ел саен үзләренең алдынгы казанышлары белән төбәкләрнең һәм илләрнең социаль-икътисадый үсешенә йогынты ясаучыларны берләштерә. ММЧнда Гайдар форумын «Россия Давосы» дип атау ныклап урнашты. Чит илләрдән килгән кунаклар өчен форум Россиянең социаль-икътисадый һәм сәяси үсешенең төп тенденцияләре, илдәге бизнес-мохит һәм инвестицияле климат турында мәгълүмат бирүче мөһим чыганак булып тора. Илебез экспертларына анда катнашу Россиянең алга таба икътисадый үсеше һәм дөнья икътисадына интеграциясе перспективаларын билгеләргә мөмкинлек тудыра.

Форум төрле дәрәҗәдәге һәм күләмдәге чараларны, мәсәлән, пленар сессияләрне һәм экспертлар катнашындагы түгәрәк өстәлләрне, панель дискуссияләр һәм дебатларны үткәрү өчен даими эшләп торучы мәйданчык хезмәтен үти. Дискуссияләрдә катнашучылар сыйфатында аның эшенә яшь галимнәрне актив җәлеп итү форумның иң мөһим үзенчәлекләреннән берсе булып тора. Форум сессияләре замананың иң кискен проблемаларына багышлана, РФнең дөнья күләмендәге хәленә һәм стратегик роленә бәйле темаларга зур әһәмият бирелә. Вакыт барган саен форум иң якын елда Россиянең социаль-икътисадый сәясәте тикшерелә һәм критик бәяләнә торган урынга әверелде.



ТАШАЯК ҺӘМ МӘСКӘҮ УРАМНАРЫ ЧАТЫНДА

Казан гаҗәпләндерергә ияләшеп килә. Стильләр, чорлар, мәдәниятләр үрелеше, күптеллелеге белән. Хәтта урам, мәйдан һәм тыкрык исемнәре белән дә. Сез тагын кайсы шәһәрдә Ташаяк яки Наратбаш урамын таба аласыз? Ә Кызыл Армия урамы ничегрәк? Әгәр дә инде таксист сезне Лебяжье урамы урынына шәһәрнең бөтенләй башка ягына – Аккош урамына алып китсә, үпкәли күрмәгез. Ихтимал, әлеге эпизод Татарстанда ике дәүләт телен дә белү зарурлыгына тагын бер дәлил булыр.

Автор:
Әскәр Сабиров

Казан урамнарының татарча исемнәре – җирле колоритның мәчет манаралары кебек үк аерылгысыз өлеше. Кайбер урамнар – варисларга тарих төпкеленнән юлланган хәбәр сыман (мәсәлән, шул ук Ташаяк – кайчандыр, әле Казан яулап алынганчы, Кирмән янында нәкъ шул исемдәге ярминкә мәйданы гөрләгән, диләр). Икенчеләре – әле күптән түгел булган вакыйгаларның кайтавазы: мөгаен, Киров районындагы Сабан яки Идел буе районындагы Ирек урамнары революцион

Фото: Александр Ефремов



үзгәрешләр чорында шулай аталгандыр.

Тар урам кебек бик гади исемлеләре дә бар – Челюскин урамына тоташкан әлеге урам чыннан да бик тар, кысан. Юл урам дигәне буйлап барасың икән – моның чыннан да шәһәр урамына караганда күбрәк юлны хәтерләтүен күрәсең. Әле тагын Ак Каен, Алмагач, Аксу, Чишмәле, Игенче кебек бик матур исемлеләре дә байтак. Барлык урам исемнәренең русчага тәрҗемәсен хәтереңдә калдырсаң, татар сөйләмен аңлый башлавың да бар.

ЗВЁЗДНАЯ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛЫ: АЕРМАСЫН ТАБЫГЫЗ

Татарстан башкаласында айлы мәчет манаралары янәшәсендә православие чиркәүләренең гөмбәзләре ялтырап тора, татарча урам исемнәре дә башкалары белән бик җайлы яраша. Аккош – Песенная белән, Балачак – Луговая, Ташаяк Мәскәү урамы белән тыныч күршелектә яши... Мәскәүлеләр өчен әллә кайчан үзләренекенә әйләнгән Арбат яки Ордынка урамнары исемнәре инде берәүне дә шаккатырмаган кебек, Казан халкын да әлеге русча-татарчалы «букет» бер дә гаҗәпләндерми.

Әмма һәрнәрсәдә толерантлыгы белән танылган Казан монда да Мәскәүне уздырган булып чыкты. Татарча исемле урамның һәр икенчесенең «игезәге» бар, ягъни шәһәрнең башка районында русча нәкъ шундый ук исемдәге урамны табып була. Мисаллар кирәкме? Рәхим итегез! Киров районындагы Большая урамының игезәге – Идел буе районындагы Зур Урам (Губкин урамы белән кисешә). Кече Дәрвишләр бистәсендәге Березовая урамыныкы – Авиатөзелеш районындагы Ак Каен. Киров районындагы Звёздная урамыныкы – Залесный бистәсендәге Йолдызлы. Киров районындагы Лебяжье урамыныкы – шул ук Залесный бистәсендәге Аккош урамы...

Дөресен генә әйткәндә, миңа әлеге русча-татарча урамгеография сүзлеге бер дә комачауламый. Ул дистәләрчә ел буена формалашкан. Планетаның теләсә кайсы почмагында «Айда, пошли» эксклюзив гыйбарәсеннән казанлыны танып булган кебек, бу да безнең үзенчәлекле калабызның үзенә күрә бер колорите булып тора. Әмма кайвакыт төрле телләрдәге, тик бер үк исемдәге урамнар чыннан да юлдан яздырырга мөмкин. Таксига утырасың, урам исемен бер дәүләт теленнән икенчесенә тәрҗемә итәсең дә, рәхәтләнеп шәһәрнең икенче ягына китеп барасың... Һәм икенче районда үзеңә кирәкле йортны таба алмый аптырагач кына, ничек ялгышканыңны аңлыйсың.

Хәер, төрле телләрдәге ике Березовая урамы бер үк телдәге нindидер егермеләп Поперечный, дистәләп Дәүләки, дистәләп Заречный, бишләп Новосельский яки ике Локаторный тыкрыгына караганда барыбер күпкә матуррак. Ә мондый ямьсез исемнәр Казан картасында һаман да бик күп әле. Иҗат өчен чын мәйдан менә кайда ул!

ул. Ноксинский спуск
Нокса яры ур.
11
ул. Ноксинский спуск
Нокса авышлыгы ур.
25
ул. Ноксинский спуск
Нокса төшеру ур.
9

НОКСА БУЕНА ТӨШҮ УРАМЫ – ӨЧ ВАРИАНТТА

Икетеллелеккә әйләнеп кайтыйк әле. Безнең Татарстанда ике дәүләт теле булгач, күрсәткечләрдәге урам исемнәрен дә ике телдә язу мәслихәттер. Әмма ничек язарга? Минемчә, моның ике варианты бар. Беренчесе – тәрҗемәсез язу. Ягъни мәсәлән, әгәр урам Большая Красная дип атала икән, татарча вариантта да «Большая Красная урамы» булсын. Һәм киресенчә, Алмагач урамы русча да «улица Алмагач» булып калсын, Яблоневая урамына әйләнмәсен.

Икенче юл – бөтенесен дә русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә итү. Озак уйлап тормасаң, бу юл белән дә китәргә мөмкин. Менә «Ноксинский спуск» урамын татарчага тәрҗемә иткән кешеләр дә озак уйлап тормаган. Моннан нәрсә килеп чыкканмы? Бик ямьсез килеп чыккан. Хәзер бу урам йортларындагы күрсәткечләрдә аның татарча атамасы өч төрле язылган.

Аңлашыла ки, икенче вариантны сайлаганда, тәрҗемә кыенлыкларына барып төртеләчәкбез. Монда эш тәрҗемәчеләрнең квалификациясендә генә дә түгел – кайбер сүзләрнең икенче телдә төгәл аналогы булмау мәгълүм. Кайбер сүзләрне исә бөтенләй тәрҗемә итеп булмый, бу очракта аның мәгънәсе югала. Менә Наратбаш урамын русчага ничек тәрҗемә итәргә? Бер варианты – Хвощ. Моның шундый үлән исеменнән икәнен белмичә, сүзен сүзгә «опушка соснового леса» дип тә тәрҗемә итәргә теләүче табылыр. Урам өчен кызык исем килеп чыга, әйеме? Иң мөһиме – оригиналь. Ә легендар Ташаяк урамы? Күрсәткечтә «Каменная Нога» дип язып куюга – Кытайның ялган эшләнмәләреннән тиз арада буяу кубып төшкән кебек, гасырлардан килгән борынгы исемнең бөтен даны юкка чыгуны көт тә тор.

Фото: Айсылу Корманова

ЮЛКҮРСӘТКЕЧМЕ, ӘЛЛӘ ЛИНГВИСТИК РЕБУСМЫ?

Тагын бер проблема да бар әле. Без бөтен татарча урам исемнәрен русчага һәм, киресенчә, бөтен русча исемнәрне татарчага тәрҗемә иткәч, Казанда бер үк төрле урам исемнәре күпкә артачак. Һәм шәһәр кварталларында кирәкле урамны табу кунакларга гына түгел, казанлыларга да кыенлашачак кына. Бер Ак Каен һәм бер Березовая урынына Ак Каен – Березовая һәм Березовая – Ак Каен урамнары пәйда булачак бит. Хатлар адресатларына барып җитмәстер – «Россия почтасы» хәтта Татарстандагы бүлекләрендә дә ике телдә сөйләшүче белгечләр күп түгел. Әгәр практик файдасы юк икән, мондый үзгәрешләрнең нигә кирәге бар соң? Шуны онытмау зарур: кварталлар, районнар, урамнар, тыкрыклар, аларның исемнәре... – болар барысы да лингвистик ребус чишәр өчен түгел, иң әүвәл безгә А пунктыннан Б пунктына юл табуны җиңеләйтү өчен кирәк.

Күрәмсең, беренче вариант акылга муафыйкрактыр. Өстәвенә, безнең урамнарның күпчелеге, бигрәк тә Казан үзәгендә, бөек шәхесләр хөрмәтенә аталган, һәм бернинди тәрҗемә дә таләп ителми. Ташкент, Киев, Мәскәү һәм Казандагы Муса Җәлил урамнары исеме, төрле алфавит хәрефләре белән язылса да, бер үк төрле әйтелә. Тбилиси, Ереван, Казан яки Бакудагы Пушкин урамнары белән дә шул ук хәл.

Географик атамаларга килгәндә, барысы да аңлашыла сыман. Монда дөнья тәҗрибәсе кулланыла: Лондон, Мәскәү, Нью-Йорк, Памир яки Монблан... – боларны үзгәртү, тәрҗемә итәргә маташу мәгънәсез гамәл. Димәк, Казандагы Мәскәү, Санкт-Петербург, Актаныш, Оренбург тракты урамнары исемнәре дә һәркем аңларлык булып калачак. Үткәннәрнең күңелсез тәҗрибәсен кабатламаган очракта әлбәттә – кайчандыр Татарстанда дистәләрчә географик атаманы бер телдән икенчесенә тәрҗемә итәргә маташып имгәткәннәр инде. Бу мәгънәсез гамәл карталарда һәм юлкүрсәткечләрдә үзенең эзен калдырган. Мәсәлән, гәрчә атамасында атка кагылышлы бер ишарә булмаса да, татарча Кун авылы исемен русча Конь дип үзгәртеп язганнар. Менә бу атамаларда күптән тәртип урнаштырырга вакыт...

Ә инде Татарстаныбыз башкаласында оригиналь татарча урам исемнәрен чыннан да арттырырга теләсәк, микрорайоннардагы яңа урамнарга матур исемнәр кушарга яки шыксыз исемнәрне яңартырга кирәк. Ләйсән, Идел, Сандугач... – булачак урамнар өчен искиткеч яңгырашлы татар сүзләре бихисап әле, сайлап кына өлгер. Салават Күпере микрорайоны, Чишмәле, Тансык урамнарының Казан көнкүрешенә ничек җайлы кереп китүе буенча фикер йөрткәндә, икетеллелек норма булган шәһәребездә яңа татар атамаларының кулланылышка бик җиңел керүе күренә.

...Казан урамнары исемнәрен ике телдә язуны тормышка ашырырга тиешле җаваплы затлар һәм әлеге гамәлне башкаручыларның кайсы юлны сайлаячагын мин белмим. Әмма шуңа өметләнәм: кылкаләмгә үрелгәнче, алар башта төсләрне бик җентекләп сайлар. Мантыйк, саф акыл, шикләнү һәм дөнья тәҗрибәсе – менә шул мөһим нәрсәләрдән башка бу эшкә тотынмаслар, дип ышаныйк. Т

«ДИНАМО-КАЗАН» ҺӘМ «МАХЕЕВЪ»: ҺӘРЧАК ҖИҢҮГӘ ЙӨЗ ТОТЫП

Профессиональ спортны сөючеләрне түбәндәге ике сорау гел борчый: җиңүче команданы төзүнең сере нидә һәм спортны финанслауга юнәлдерелә торган зур акчалар кая китә. Аларга җавап алыр өчен без «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы президенты, командага миллиард сумга якын акча керткән «Эссен Продакшн АГ» спонсор компаниясе генераль директоры Леонид Барышев һәм клуб директоры Сергей Чернышов белән очраштык.

Хатын-кызлар волейбол легендасы һәм «Динамо-Казан» командасының элеккеге уенчысы Екатерина Гамова үзенең автобиографик китабында Татарстан башкаласында: «Йә, нәрсә, нефть акчаларына уйныйсызмы?» – дигән сорауга ничек җавап бирүләрен искә төшерә. Җавап бер була: «Юк, майонезныкына». Эш шунда: хатын-кызлар волейбол командасы формасын менә инде җиде ел дәвамында команданың төп реклама бирүчесе – «Махеевъ» компанияләр төркеменең логотибы бизи. Спорт клубының эше белән «Эссен» бизнес-проектының эше бер-берсенә нәрсә белән охшаш соң? Охшашлык командаларны формалаштыруга якын килү ысулында. «Эссен АГ»да да, «Динамо-Казан»да да беркайчан да «класс» күрсәтергә тиешле йолдызлар командасын туплауга омтылмадылар. Барышев командасында да, «Динамо-Казан»да да ысул бер генә – үз белгечләреннән йолдыз ясау. Ә тарих Гамовадан башлана.

НИЧЕК ЯҢА ГАМОВА ТӘРБИЯЛӘРГӘ?

Ике ел элек, 2016 елның көзендә, бөек Гамова үзенең уен карьерасын Казанда хушлашу матчы белән тәмамлады. Әлеге уеннан соң ул бик җылы, тәэсирле чыгыш ясап, үзе дә елап җибәрде һәм хәтта волейболдан ерак торган кешеләрне дә дәррәү кубып алкышларга мәҗбүр итте. Әлеге чара вакытында күпләрне бер сорау борчыды: «Гамова китте, нишләргә?» Җавапны Екатерина үзе әйтте: «Яңа уенчы әзерләргә, Казанда моның өчен бөтен шартлар да бар».

«Динамо-Казан» волейбол проекты баштан ук хатын-кызлар волейболында иң алдынгы булырлык итеп уйланыла. Ун ел элек «Казаночка» хатын-кызлар волейбол командасы яшәвеннән туктады, ә «Динамо-Таттрансгаз» ир-атлар волейбол командасы Россия Газпромы карары буенча «Зенит-Казан» исемен алды. Шулай итеп, «Динамо» атамасы Татарстан профессиональ волейболыннан юкка чыкты. Менә шул вакытта ТР «Динамо» Физкультура-спорт җәмгыяте Иҗтимагый-дәүләти оешмасы советы рәисе Әсгать Сәфәров «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубын оештырырга карар кыла да.

– Җитди бурыч куелды: суперлигага чыгарга һәм анда чемпионлык өчен көрәшергә. Һәм бурыч ике ел эчендә хәл ителде дә, – дип искә ала «Динамо-Казан» клубы директоры **Сергей Чернышов**. – Мин инде ун ел монда, клуб белән бергә үсешнең барлык баскычларын үттем. Екатерина Гамова белән контракт төзү аерым сәхифә булып тора. Аны чакыру мөмкинлеге турында белүгә, мин Сәфәровка болай дидем: «Әлеге уенчыны чакырырга рөхсәт бирегез!» Өч секунд эчендә уңай җавап алынды һәм сигез ай дәвамында мин аны безгә күчерү белән шөгыльләндем. Нәтиҗәдә Гамова белән махсус алсу кәгазьдә контракт имзаланды, һәм ул шактый вакыт бездә уйнады.

Шунысын билгеләп үтик: 2011 елдан, клубның мөһим спонсоры булып «Эссен» эшли башлагач һәм реклама бирүчеләрнең төп командасы (бу, беренче чиратта, «ТТС», «Мелита», «Ак Барс», «Грань» һәм башкалар) формалашкач, «Динамо-Казан» брендын булдыру буенча максатчан эш башланды. Компаниянең финанс ярдәме иң югары дәрәҗәдәге легионерларны чакырырга булышты, һәм аларга карап башка, шул исәптән Гамова кебек төп уенчылар да тартылды. Хәзер, инде күпләгән бүләкләр яуланганнан соң, күпләгән турнирларда җиңгәннән соң, клубның исеме эшли дияргә буладыр.

Фотолар «Динамо-Казан» волейбол клубыннан алынды.

Реклама

Клуб тактикасын үзгәртүне кирәк дип тапты: көчле мәктәп һәм тренировкалар системасын булдыру нәтиҗәсендә үз уенчыларын үстерергә кереште.

– Гамова киткәннән соң, клуб биш адым алга атлар өчен, аңлы рәвештә бер адым артка атладымы?

– Юк, безнең җитәкчелек һәрвакыт максималь бурычлар куя. Титуллар өчен генә көрәшәбез. Аңлашыла ки, төрле бурычлар куярга мөмкин, әмма без чынбарлыктан этелергә тырышабыз. Шулай килеп чыкты: бу сезонда безнең атакалаучы өч уенчыбыз да алышынды – гадәттә иң күп очко җыючыларыбыз. Яңа уйнап бетерүчеләр һәм диагональ уенчы килде.

– Яңартылган команда үзен ничек күрсәтте?

– Россиядә өч турнир үткәрелә: Россия Кубогы, Россия чемпионаты һәм катнашу өчен илебездән өч команда сайланып алына торган Чемпионнар лигасы. Шулай ук икенче ел рәттән Суперкубок уздырыла. Анда Россия чемпионнары һәм узган елгы Россия кубогы иясе катнаша. Узган елдагы кебек үк без быел да Суперкубокта «Динамо-Мәскәү» белән уйнадык. Ләкин, ни кызганыч, икенче ел рәттән җиңеләбез: 3-1. Россия Кубогы узды. Финал Калининградта, декабрь аенда үтте. Анда дүрт команда сайланды, шул исәптән «Динамо-Казан» да. Без тагын, кызганыч, ярымфиналда Красноярск «Енисеена» оттырдык, шулай да өченче урын өчен уенда хуҗалар – Калиниградның «Локомотив» командасын җиңдек. Тик шулай да ярымфиналга үтә алмау безнең өчен җиңелү санала. Уенчылар, белгечләр һәм җитәкчелек Красноярск белән йомшак уйнадык дип саный. Хәзер безнең ике турнир калды, Россия чемпионаты дәвам итә. Ул төп өлештән тора. Командалар бер-берсе белән бер уенны өйләрендә, икенчесен кунакта уйныйлар. Алга таба сигез иң яхшы команда плей-оффта очрашачак. Бу – тамашачылар өчен чемпионатның иң кызыклы өлеше. Чемпионнар лигасында уеннарның якынча этабы бара. Без бер уенда оттык, берсен оттырдык. Безгә кыенга туры киләчәк, чөнки итальян, төрек командаларының әзерлек дәрәҗәләре югары. Безнең каршыда аларның өстенлекләре шунда: без тыгыз график буенча – атнасына ике уен уйныйбыз. Без әле Калининградка, әле Сахалинга, әле Красноярскига, әле Краснодарга очабыз.

Очышлар ешрак Мәскәү аша. Командага көчен торгызу, шөгыльләнү өчен вакыт бик аз кала. Бигрәк тә кунакта ике уен уйнаганда, аннан команда физик яктан арып, йончып кайта. Хәл җыю өчен вакыт таләп ителә. Һәм көндәш командаларның составы да бик көчле. Без, әлбәттә,ирешмибез. Ләкин бик авыр булачак. Март-апрель айларында узачак плей-оффта үзебезнең иң яхшы уеныбызны күрсәтеп, Россия чемпионатының финалына чыгарга тиешбез, аннан инде Чемпионнар лигасына чыгу гарантияләнгән. Ә финал финал инде – иң көчле команда җиңәчәк.

– Ләкин җиңелүләрсез җиңү булмый бит...

– Әйе, әлегә бу сезонда команданың эше канәгатьләнерлек түгел. 2015–2016 елны санамаганда, соңгы еллардагы иң йомшак график буенча барабыз. Бу команданы яшәртү, үз кадрларыбызга таяну кебек кыю карарның нәтиҗәсе.

Диагональдә бездә алты ел дәвамында Екатерина Гамова уйнады. Аңардан соң кемгә дә булса чагыштырырлык уен дәрәҗәсен күрсәтү бик авыр. Быелгы сезонда без командага әлегә бик билгеле булмаган чех кызы Соня Микискованы чакырырга булдык. Ул яхшы уйный, әмма ниндидер бик көчле физик сыйфатлар белән аерылып тормый. Уйнап бетерү позициясендә – Анна Котикова һәм Россия волейболында яхшы таныш Анастасия Бавыкина. Без аны әле ике ел элек үк Казанга чакырган идек, уенын күзәтеп бардык. Плюс безнең Татьяна Кадочкинабыз бар, аңа әле 15 яшь кенә, ләкин ул бүгенге көндә үз позициясендә дөнья күләмендә әлеге яшь категориясендә иң яхшы уенчы санала.

Котикова, Малыгина, Кочурина шулай ук осталыкларын арттыра баралар. Кочурина – үзәк блок куючы. Кызганычка, үзебезнең уенчы, блок куючы Самойлина травма алды, аңа Яңа ел алдыннан гына операция ясадылар, шуңа сезон ахырына кадәр уйный алмаячак. Ләкин шулай да команда көчәя диген ышанычыбыз бар, уенчыларыбыз яшь, алар барысын да үзләренә сеңдереп бара. Аларга мондый атмосфера, мохит, югары казанышлар спорты, уйнап кына калмыйча, җиңәргә тиешле стресслы матчлар кирәк. Казанда «Зенит»ны алсак та, «Динамо-Казан»ны алсак та, һәр уенчы уйнарга әзер түгел, чөнки биредә җиңү таләп ителә – һәрвакыт һәм теләсә кайсы шартларда. Ә башка кайбер клубларда мондый бурыч куелмый: тренировка процессында да, уеннарда да, уеннарны тикшергәндә дә – һәрвакыт чагылыш таба торган басым юк һәм кешеләр җиңелүләргә төрлечә карыйлар. Уенчыларның җиңәселәре килә, барып чыкмый – үзләрендә казыналар, тагын уенга чыгалар һәм җиңәләр. Болардан башка җиңәргә бик авыр. Минемчә, бу вакытлыча вазгыять, эшләнергә тиешле адым, тешне кысарга һәм сабыр булырга кирәк.

Ә гомумән алганда, бернинди дә трагедия юк. Бер яктан икенче якка бәргәләнү шулай ук яхшыга китерми. Әйе, җитәкчелек безне тәнкыйтьли – әлбәттә, хаклы рәвештә җиңү таләп итә, ләкин шул ук вакытта елның гади генә ел түгеллеген, команданың яшь, кызыклы булуын, әмма шул яшьлеге, составның шактый үзгәрүе аркасында,

тотрыклы була алмавын да аңлый. Без кайчак искиткеч уен күрсәтәбез, кайвакыт бөтенләй килеп чыкмый. Язга көч тупларбыз һәм җиңү өчен көрәшербез дип ышанам. Әлегә чемпионат тәгәлләнмәгән, көрәш дәвам итә.

– Ягъни стратегияне алыштыру булмаячак?

– Бу сезонда тәгаен булмас, ә икенче елга команда нинди булачагы сезон тәгәлләнгәч кенә аңлашылачак. Без, әлбәттә, уйлыйбыз, анализлыйбыз,төрле вариантларны карыйбыз, гәрчә, югары класслы уенчыларның күп булмавы сәбәпле, вариантлар чикләнгән булса да. Бүген Россиядә топ-уенчыларны табу җиңел түгел, хәер, алар дөнья күләмендә дә бик аз санда.

«БЕЗ ТРЕНЕРЛАР ШТАБЫ ЯКЛЫ»

Сергей Чернышов – кызыклы әңгәмәдәш, ул команданың оешуы турында әллә никадәр кызыклы фактлар турында сөйли ала. Финанс аспекты турында да сөйләде ул.

– Суперлигада безнең беркайчан да иң зур бюджет булганы юк. Хәтта клубта дөнья дәрәҗәсендәге волейбол йолдызлары Гамова, Ларсон, Дель Коре, Бородакова уйнаганда да.

– «Махеевъ» компаниясе белән хезмәттәшлек кайчан башлануы турында сөйләсәгез иде…

– 2011 елдан башланды. Игътибар иттегезме: формада язу кайсы урында урнашкан – иң күренеп тора торган җирендә. Бу бик кадерле. Бервакыт Омскида уйнаган вакытта: «Сыр, дави майонез!» диган тавышлар ишетелде. Безнең спонсор майонез компаниясе бит, ә аларның командаларының исеме «Омичка» сыры белән аваздаш.

– Клуб матчларда ареналарның буш булмавы проблемасын ничек хәл итә?

– Бездә дә, «Зенит»та да бер принцип: без чакырып китергән легионерлар Казанда озак вакыт уйнарга тиеш. 22 гыйнварда без Джордан Ларсонның футболкасын Волейбол сарае гөмбәзенә күтәрәчәкбез. Чемпионнар лигасы җирәбәсе буенча безгә ниһаять ул уйный торган команда туры килде. Без Джордан катнашында аның «Динамо-Казан» клубын үстерүгә керткән өлешен билгеләп үтәргә телибез. Күптән түгел генә музей ачылды, ул бик кызыклы булачак. Клублар белән атрибутикаларны, волейболга караган архив әйберләре һәм башка күп нәрсәләр белән алмашачакбыз.

– «Динамо-Казан» инде ун елга якын тренерын алыштырмый…

– Әйе, без Ришат Гыйлаҗетдиновка, аның үз эшенә иҗади якын килә белүенә ышанабыз. Бүген бездә барлык тренировкаларда датчиклар эшли – барлык мәгълүмат тренерлар штабына килә. Мондый тренировкалар үткәрүне дә баш тренер сорады, без аның үтенечен канәгатьләндереп, быелгы җәйдә кирәкле җайланмаларны сатып алдык. Бу дөнья волейболы үсеше тенденциясе, Гыйлаҗетдинов боларны тотып ала белә. Бу «бәр дә – кач» түгел, бу яңа технологияләр, әгәр нәтиҗәгә ирешергә булыша икән, аларны эштә кулланырга кирәк.

Беләсезме ни өчен кайбер волейболчы кызлар уен тәнәфесләреннән соң тупны аутка җибәрә яисә сеткага эләктерә? Чөнки аларның пульслары түбәнәйгән! Әгәр шундый моментларны барлап, пульсны тиешле дәрәҗәдә тотсаң, уен барышын яхшырак контрольгә алырга, туп бирүне нәтиҗәлерәк итәргә мөмкин. Бер сүз белән әйткәндә, без тренерлар штабы яклы.

КОМАНДАГА 1 МЛРД СУМГА ЯКЫН АКЧА КЕРТЕЛГӘН

«Динамо-Казан»га катнашы булган һәркемнең үз эше белән шөгыльләнүен аңларга кирәк: «Эссен» командасы акча кертә, Сергей Чернышов йөзендә менеджмент акчаны дөрес кулланырга тырыша, волейболчы кызлар нәтиҗә китерә торган уен күрсәтә.

– Теләсә кайсы клубның төп керем чыганагы – спонсор акчалары һәм гамәлгә куючыларның кертемнәре, – дип сөйли волейбол клубы президенты һәм «Эссен Продакшн АГ» ЯАҖ генераль директоры Леонид Барышев. – «Динамо-Казан»га төп ярдәм «Динамо» спорт җәмгыятен гамәлгә куючылардан һәм спонсорлардан килә.

– Цифрларны атый аласызмы?

– «Динамо-Казан» белән «Эссен»ның хезмәттәшлеге 2011 елдан башланды, гәрчә компаниянең төрле дәрәҗәләрдә клуб белән бәйләнеше әле 2008 елга кадәр үк бар иде. Ул чакта клуб «Казаночка» дип атала иде. Спонсор республика волейбол федерациясе белән хезмәттәшлеген башлаган, ә ир-атлар волейболында Казанның үзенең «Динамо»сы уйнаган вакыт. «Казаночка»ны «Динамо-Казан» командасы итеп үзгәрткәч, җитди спонсор ярдәме таләп ителә башлады. Барлык бу еллар эчендә команда үсешенә берничә йөз миллион сум акча салынды.

Команданың брендын булдыру беренчел бурыч итеп куелды. Уйнау дәверендә командага реклама контрактлары нигезендә 1миллиард сумга якын акча кертелде. Хәзер бу кертемнәр безгә имидж дивидентларын китерә.

Клубларның кризис чорында да иганәче ярдәме булачагына ышанычлары булырга тиеш. Берике ел элек девальвация булды,

Реклама

чит ил валютасы көчәйде, бу хәл команданың бюджетына тискәре йогынты ясамый калмады. Безгә спонсорлар буларак әлеге мәсьәләне оператив хәл итәргә туры килде. Республиканың клуб бюджетында катнашуы турында да онытмаска кирәк, ул лаеклы өлеш кертә. Бу медицина җиһазларын сатып алу да, бүләк ителгән автобус та… Аллага шөкер, спонсорга да, клубның үзенә дә матчларны кайда үткәрү турында баш ватарга туры килми – республика менә дигән волейбол комплексы бүләк итте. Ышаныгыз, Россиянең һәм дөньяның күп кенә клубларына мондый инфраструктурага көнләшеп карарга гына кала.

Моннан тыш, кертемнәрнең зур өлеше уенчыларның хезмәт хакына һәм очышларга бәйле чыгымнарга бара: хәзерге вакытта Суперлигада Калининградтан Сахалинга кадәрге командалар катнаша. Мондый дәрәҗәдә инде спонсор ярдәменнән башка үз каршында җитди бурычлар куючы командага нәтиҗәгә ирешү мөмкин түгел.

Һәм инде бик әһәмиятле бурыч – көчәергә һәм яңа легендар уенчылар белән баерга мөмкинлек бирә торган хатын-кызлар волейболы мәктәбен төзү һәм ярдәм итү. Эзлеклелек һәм гомуми җиңү кәефе булдырыла.

ЭШ БИРҮЧЕ БУЛАРАК БЕЗНЕҢ КЛУБ СЫЙФАТ БИЛГЕСЕН ФОРМАЛАШТЫРДЫ

– Ялда һәрвакыт иртәнге һәм кичке волейбол тренировкаларында катнашмый калудан куркам. Минем бөтен ялым әлеге ике чара арасында үтә, – дип дәвам итте сүзен Леонид Барышев. – Ихтимал, мин начаррак уйнап бетерүче яисә диагональ уенчыдыр, ләкин либеро буларак ярыйсы гына уйныйм, кайвакыт коткарып калам, саклауда ярдәмем тия. Матчны караганда, бәлки, тренерларның тактик нюансларына тирәнтен төшенеп бетә алмыймдыр. Ләкин зур стажлы җанатар буларак, уенның гомуми картинасына бәя бирә алам.

– Сез Гамова китабын укыдыгызмы?

– Әйе. Аның китабында барысы да уенчы күзлегеннән языла. Мин бу ситуацияне башка яктан күрәм. Хәтерлим әле, Екатеринаны чакырыр алдыннан клубның иганәчеләр советы узды, һәм безгә әйттеләр: «Клуб үсешенең ике вариантын күрәбез: зур ыргылыш һәм команданы бер кеше тирәсендә формалаштыру яисә этаплап төзү». Сүз уңаеннан, без ярты ел дәвамында Гамовага «җайлап» йөрдек, аның төгәл безгә киләчәгенә ныклы ышаныч булмады – топ-клубларның шактые уенчыны үзенә чакыра иде. Ләкин нәтиҗәдә безнең клубка килсә, брендинг һәм команданың имиджын булдыру юнәлешендә үзебезнең алга таба гаять зур адым атлаячагыбызны без аңлый идек.

«Динамо-Казан» төзелгән генә вакытта безгә базарга үтеп керергә һәм Россиядә «беренче номерлыга» әйләнергә кирәк иде. Сүз уңаеннан, бизнестагы кебек үк. Нәтиҗәдә аның белән сөйләшүләр тактик яктан шулкадәр дөрес алып барылды ки, безгә шунда ук Гамованың Казанга киләчәге билгеле булды. Без гарантияләр бирдек, чөнки ул вакытларда мондый дәрәҗәдәге волейболчыларның бер клубтан икенчесенә күчү очраклары сирәк иде. Безнең өчен Гамованың күчүе гомумән алганда барлык эшебезнең сыйфат дәрәҗәсен билгеләүне аңлатты. Хәзер, Екатерина биредә берничә сезонын үткәргәннән соң, югары дәрәҗәдәге уенчыны Казанга чакыру белән авырлыклар бөтенләй юк. Барысы да бездә заманча инфраструктура, менә дигән шартлар булуын белә. Аңлашыла ки, шул ук Мәскәү күпләрне башкала буларак җәлеп итә, анда яшиселәре килә, ләкин Казан – спорт башкаласы, инфраструктура күзлегеннән караганда, өстенлекләребез күбрәк.

– Гамова Казанга күчкәннән соң, «Динамо-Казан» бренды формалашты дип әйтеп буламы?

– Әйе, безнең клуб эш бирүче буларак сыйфат билгесен формалаштырды. Казанга күчкән барлык волейболчы кызлар югары позицияләр өчен генә түгел, нәкъ менә трофейлар өчен көрәшергә кирәклеген аңлыйлар иде. Нәтиҗәдә «Динамо-Казан» трофейлар өчен көрәшкә кушылды, һәм Татарстан клублары арасында, Казанның «Зенит», «Ак Барс», «Рубин» клублары белән беррәттән, без мөстәкыйль спорт бренды булуга ирештек.

– Спортта һәм бизнеста команданы формалаштыру – болар охшаш процесслармы яисә бер-берсеннән нык аерыла торганмы?

– Әйе, бизнеста махсуслашкан шикелле үк, спортта да уенчыларның махсуслашуы бик мөһим. Без волейбол командасында һәрвакыт дөрес эшләргә тиешле уенчылар бәйләнешен – «связка»ларны туплыйбыз. Әгәр яхшы пас бирүче юк икән, яхшы уен, команда белән контакт та килеп чыкмаячак. Либеро турында да шуны ук әйтергә була. Ул кем белән уйнаячагын, кемгә ярдәмгә әзер булырга тиешлеген белергә тиеш. Бизнеста да шулай ук. Яхшы «бәйләнешләр» бизнеста да бер-берсе белән элемтәсе булмаган ике суперпрофессионалга караганда күбрәк нәтиҗә бирә. Шуңа күрә супейолдызлар командасы түгел, ә беренче чиратта нәтиҗә бирергә сәләтле бердәм команда тупларга кирәк. ▪

остадан СОРАГЫЗ!

Августта Казанда кабат дөньякүләм ярышлар – WorldSkills-2019 чемпионаты узачак. Анда 60 тан артык илнең иң яхшы яшь һөнәрмәндләре катнашачак. Агач эше осталары һәм чәчтарашлар, флористлар һәм икмәк пешерүчеләр, инженер-электрониклар һәм токарьлар – барлыгы 56 компетенция тәкъдим ителәчәк. «Татарстан» журналы әлеге вакыйга хөрмәтенә «Остадан сорагыз!» рубрикасын ача, анда без сезне үз осталыклары белән бөтен илне генә түгел, бөтен дөньяны шаккатырырга җыенган Татарстан яшьләре белән таныштырачакбыз.

РӘХӘТ ТӘ, КЫЙММӘТ ТӘ

Казан халык һөнәрчелеге техникумында зәркән эше остасы Данил Җәләев, горелка һәм бораулау машинкасы, лобзик һәм эскәк белән коралланып, металлны «буйсындыра». Эшче һөнәрләрнең Татарстан чемпионаты җиңүчесе WorldSkills бәйгесенең Россия этабына әзерләнә.

1. Ни өчен бу һөнәрне сайладыгыз?
Мин, барыннан да бигрәк, үземне рәссам дип саныйм. 6 нчы сыйныфта укыганда рәсем ясап караган идем, ничектер күркәм генә килеп чыкты. Бу рәсемнәр туган ягым Самара өлкәсендә район конкурсларында беренче урыннарны ала башлады. Казанга укырга килдем – мине бу шәһәр һәм аның мөмкинлекләре җәлеп итте. Халык һөнәрчелеге техникумына бизәүче-рәссам һөнәрен үзләштерер өчен укырга кердем, аннары миңа зәркәнче һөнәренә өйрәнергә тәкъдим иттеләр. Әлеге һөнәр нәрсәсе белән җәлеп иттеме? Үз кулың белән иҗат итү мөмкинлеге белән! Ниндидер идеяләреңне тормышка ашырырга, кызыклы бизәнү әйберләре ясарга мөмкин. Әлегә минем үз өслүбем юк, тик мин аны эзлим инде.

2. Үткән WorldSkills ярышларында нинди кыенлыклар кичерергә туры килде?
Иң мөһиме – әлбәттә инде, дулкынлану. Бигрәк тә минем өчен беренче булган ярышларда. Кешеләр килә, янәшәгә басып, ничек эшләгәнне карап тора – бу бик нык каушата, чөнки зәркәнче хезмәте игътибарны туплап эшләүне таләп итә. Бик дулкынландыргыч мизгел дә булды – ярышның соңгы көнендә минем биремем бераз... таралды. Эшләнмәне катырак кыздырганмын... Аны эскәк белән тиз генә алмакчы идем, ләкин бер детале очып төште. Ә вакыт инде унбиш минутлап кына калган иде... Беренче реакция, билгеле, берничек тә өлгермәм инде дигән курку. Әмма тренерым Фәннур Вәлиуллин кирәкле киңәшләрен бирде, барысына да өлгереп була әле, дип ышандырды. Тынычландым һәм барысын да җиренә җиткереп эшләдем.

3. Эшче һөнәрләр чемпионатында катнашу сезгә ни бирә?
Минем өчен – үз һөнәремдә мөмкин кадәр алга китү, остару мөмкинлеге. Бу бик зур тәҗрибә! Күнекмәләр вакытында яңа нәрсәләргә өйрәнәсең. Һәм хәтта ярышларның үзендә дә күп нәрсәгә өйрәнеп була – эш серләренә, ниндидер «фишкаларга». Нәрсәнедер үзең аңлыйсың, кайбер серләргә остазлар төшендерә. Мин әле тагын куркуымны һәм дулкынлануымны җиңәргә дә өйрәндем.

4. Булачак ярышларга ничек әзерләнәсез? Халыкара WorldSkills стандартлары безнең белем бирү рәвешеннән нык аерыламы?
Аерма зур, дип әйтә алмыйм, тик алар бар. Хәзер без тренерым белән һәр аерым модуль буенча эшлибез – пайкалау, кисеп ясау... Көн саен шөгыльләнәбез, билгеле бер элементларны камилләштерәбез. Мин ярышта җиңәргә ниятлим – моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Иң мөһиме, йомшак якларны ныгыту һәм барлык операцияләрне дә үзләштерү. Әле күп нәрсәгә өйрәнәсе бар. Эш шунда: безнең техникумда зәркәнчелек хезмәтенә нибары ике елда өйрәтәләр, ә менә, мәсәлән, Мәскәүдә – дүрт ел. Шунлыктан безгә тагын да тырышыбрак әзерләнергә туры килә.

5. Киләчәккә нинди өметләр баглыйсыз? Якын арада эшче һөнәрләргә алмашка роботлар килмәсме?
Роботлаштыру инде зәркәнчелек эшенә дә үтеп керде. Бүген зәркәнче бизәнү әйберенең 3D-моделен төзүгә үк, аны коеп була. Димәк, кулдан эшләргә туры килми. Бер яктан караганда, бу останың эшен харап итә, аны арзанайта. Икенче яктан караганда, катлаулы бизәкле эшләнмәне ясауны күпкә җиңеләйтә. Һәм бу начар түгел! Останың заказлары бик күп булса, 3D-принтер ярдәмгә килә ала бит. Әмма мондый технологияләр файдаланылган очракта да, эшләнмәнең дизайнын кеше уйлап таба, шунлыктан зәркәнче хезмәте тулысынча машина белән алыштырыла алмый!

6. Һөнәрне үзләштерү өчен нинди сәләткә һәм шәхси сыйфатларга ия булу сорала?
Мин, техникумга укырга кергәндә, зәркәнчелек турында бөтенләй бернәрсә дә белми идем! Әмма биредә әкренләп барысына да өйрәтәләр – эш коралларын куллану, операцияләргә... Шунлыктан мин зәркәнчелек эшен һәркем үзләштерә ала, дип саныйм. Бары тик кемнеңдер ул эшкә сәләте зуррак булачак, кемнеңдер – кимрәк. Ә мондый күп тырышлык таләп итә торган эшнең күпләр күңеленә хуш килмәве – инде икенче мәсьәлә, кемнедер ул бик тиз арада туйдырырга мөмкин.

7. Ун елдан соң үзегезне кем итеп күрәсез?
Рәссам итеп! Мин рәсем ясарга бик яратам – аннан беркайчан да туктамадым. Ихтимал, зәркәнчелек эше минем өстәмә һөнәрем булыр. Бизәнү әйберләре дизайнымы? Бик мөмкин! Өстәвенә, зәркәнче һөнәре кызыклы һәм югары бәяләнә. Бүген мин үзем нәрсәләрдер уйлап табам. Үзем ясаган балдакларны үзем киеп йөрим. Бүләккә дип тә теләгән эшләнмәне ясый алам! Үзем ясаган бизәнү әйберләрен еш кына туганнарыма һәм якыннарыма бүләк итәм. Мәсәлән, яраткан кызыма үз дизайным буенча асма бизәк ясадым. Эшләнмәләрне һәрвакыт конкрет кешенең зәвыгын күз алдында тотып башкарам.

Фото: Ната Смирнова

ПЛ

ҮЗЕБЕЗЧӘ КИЕНӘСЕ КИЛӘ

Игътибар иткәнегез бардыр: соңгы елларда милли кием чын-чынлап модага керде. Сабантуй, башка берәр күләмле чарамы, хатын-кызлар башына калфак кия. Милли бизәкле сумка, алка, муенса кебек бизәнү әйберләре бүген бик күп гүзәл затларның тартмасында бар. Рәсми затлар арасында да милли колоритлы кием-салым киючеләрне очратырга туры килгәли. Дөрес, һәрвакыт түгел, шулай да аерым чараларда шартын туры китерергә тырышалар.

Милли киемнәребезне дөнья аренасында димим, Россия күләмендә булса да танытып буламы? Моның өчен нәрсә кирәк? Башлангыч милли дизайнерлар белән очрашып, шул хакта сөйләштек.



Автор:
Руфия Фазылова

«ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ КИРӘК»

Игътибар иткәнегез бардыр: соңгы елларда милли кием чын-чынлап модага керде. Сабантуй, башка берәр күләмле чарамы, хатын-кызлар башына калфак кия. Милли бизәкле сумка, алка, муенса кебек бизәнү әйберләре бүген бик күп гүзәл затларның тартмасында бар. Рәсми затлар арасында да милли колоритлы кием-салым киючеләрне очратырга туры килгәли. Дөрес, һәрвакыт түгел, шулай да аерым чараларда шартын туры китерергә тырышалар.

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова исә һәрвакыт милли киемнән йөри. Бу аңа тагын да затлылык өсти кебек. Гардеробында иллеләп калфак кына бар икән. Ул аларның күбесен үз кулы белән чигә. Күлмәкләрен исә махсус тектерә.

– Безгә үзебезчә, чын татарча киенергә кирәк, – ди Кадрия ханым. – Кызганыч, бүген күпчелек хатын-кызлар милли йөзебезне югалта бара. Төркия, Гарәп илләренә охшатып тегелгән озын күлмәкләргә өстенлек бирәләр. Ә бит татар кызлары гомергә күтәртмә якалы күлмәк кигән. Яулыгын артка бәйләп йөргән. Шуңа да бу юнәлештә эшләргә дә эшләргә әле.

Кадрия ханым татар күлмәкләрен дә дөньяга танытып була дип саный. Тик аның өчен дәүләт ярдәме кирәк, дип исәпли.

– Чит төбәкләрдә, чит илләрдә дә еш булабыз. Минем өс-башымны күреп: «Кадрия Рәисовна, безнең дә сезнең кебек йөрисе

Фотолар: Ната Смирнова; дизайнерларның шәхси архивларыннан.

килә», – диләр. Һәм бу бер сәяхәттә генә түгел, бөтен җирдә шулай. Ягъни милли күлмәкләргә, читек, кәвешләргә сорау бик зур. Бүген шушы өлкәне җайга салып, тегү фабрикасы оештыру – төп мәсьәлә. Әлбәттә, бу турыда уйлаучылар, хәтта бизнес-план төзегән кешеләр дә бар. Тик дәүләттән зур ярдәм булмаганда, коры инициатива белән генә булмый шул…

Казанда милли дизайнерларны берничә уку йорты әзерли. Шуларның берсе – КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтының дизайн һәм милли сәнгать кафедрасы. Әлеге уку йортын тәмамлаган егет-кызларның кайберләре бүген үз эшләрен ачкан, алар милли бизәкле камзул-күлмәк, калфаклар эшли. Дизайн һәм милли сәнгать кафедрасы каршында «Tatar style» исемле декоратив-гамәли сәнгать һәм дизайн иҗат остаханәсе эшли. Аның җитәкчесе – Россия дизайнерлар берлеге әгъзасы, мөгаллимә Рада Инсаф кызы Сәлахова. Тормыш иптәше Расыйх Фарук улы Сәлахов та биредә укыта, алар – чын мәгънәсендә иҗади гаилә. Бүген гаилә бизнесы булдыру юнәлешендә эшлиләр: Кукмара итекләренә милли бизәкләр тегеп, сатуга чыгаралар.

Рада ханым белән «Tatar style» остаханәсе һәм милли киемнәребез турында сөйләштек.

– Татарның милли киемнәрен күпләр һаман да чабата, яулык белән алъяпкыч итеп кенә күз алдына китерә. Ә бит халкыбызның милли мәдәни мирасы заманча аһәңнәр белән баетылган киемнәр, күн мозаика эшләре, үргән челтәр изүләр белән дә бай ич. Мәсәлән, Нырты челтәрчеләре тарихта гына калган. Безнең студентлар әнә шул тарихны торгызырга алынды…

Рада ханым студентлар белән төрле коллекцияләр булдырган. Кызлар аларны киеп төрле кичәләрдә чыгыш ясыйлар ди. Бөтен җирдә сокланып калалар икән үзләренә!

– Милли юнәлештә эшләүче дизайнерларның, һичшиксез, киләчәге бар, – ди Рада ханым. – Моны студентлар да аңлый. Гел яңа идеялар белән янып яшиләр. Киләчәктә дәүләт тарафыннан бу юнәлеш үстерелсә, бер дигән кадрларыбыз бар…

«БАЕП БУЛМЫЙ»

Өендә милли бизәкле кием, бизәнү әйберләре ясап сатучыларның төгәл санын әйтү авыр. Рәсми рәвештә теркәлү узмагач, аларны каян беләсең? Шулай да милли стильдә башлап иҗат итүче дизайнерлар саны меңгә туларга мөмкин, дип фаразлыйлар. Арада шактый танылганнары да бар. Шуларның берсе – Алсу Мусабирова. Ул нигездә күннән бизәкле букча, янчык, бизәнү кебек әйберләр эшли. Алсу мәгълүм табышмактагы кебек: «Ура, суга, җилгәрә, үзе төяп җибәрә». Башта теге яки бу модельне уйлап таба, аннан аны кәгазьгә төшерә. Шуннан күнгә сыза, кисә, тегә… Һәм әзер эшләнмәләрне тарату, сату белән дә шөгыльләнә: фонга туры китереп, зәвыклы итеп фотога төшерә. Иң соңгы эше – Интернеттагы шәхси аккаунтына урнаштыру. Әлбәттә, боларның барысына да кеше яллап, «биз-

нес» белән зурлап шөгыльләнергә дә була. Тик... әлегә бу Алсу өчен хыял гына. Җәелеп эшләргә, беренчедән, урын кирәк. Аның өчен арендага аерым бина булуы шарт. Ә бу өстәмә чыгым дигән сүз. Шуңа күрә бүген аның Казандагы фатиры остаханә дә, сәүдә үзәге дә. (Мин килгәндә Алсу аш бүлмәсендә каптырмалар ясый иде).

– Яшерен-батырын түгел, яшь дизайнерга җиңел түгел, – диде ул.

Алсу үзе ясаган эшләнмәләрне аш өстәленә тезеп салды. Букчаларның бәясе 5 мең сум тора, алкалар – 1500 сум.

– Гади сатып алучы өчен бик арзан түгел икән, – дим.

– Алар барысы да чын күннән эшләнгән, Италиядән заказ белән кайтартам, шуңа кыйммәт, – ди яшь оста.

– Ә бәлки, чын күн урынына арзанлы чимал кулланырсың? Клиентларың күбәер иде, – дигән булам.

– Милли бизәкле букча, янчык, бизәнү әйберләре гомер-гомергә чын күннән эшләнгән. Ясалма күн яки арзанлы чимал куллансаң, сыйфат икенче чыга. Шуңа күрә үзебездә эшләнгән күннән андый әйберләр ясамыйм. Дөресен генә әйткәндә, мондый юнәлештә эш башлармын дип башыма да китерми идем. Кечкенәдән рәсем ясарга яраттым. Мәктәпне бетергәч, Н.И. Фешин исемендәге Казан Сынлы сәнгать училищесына укырга кердем. Аннан соң Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать университетының Казан филиалын тәмамладым. Беренче алканы үзем өчен ясадым. Миннән күреп дус кызларым да шундый алка ясап бирүне сорады. Алардан күреп башкалар заказ бирде. Кыскасы, «чыбыксыз телефон» яхшы эшли булып чыкты. Тора-бара милли бизәкле муенсалар да ясый башладым. Аннан калфак эшләдем, шуннан акча янчыгы, клатч һ.б.

Алсу, башка яшь дизайнерлар кебек, «Печән базары», Сабантуй кебек милли чараларда актив катнаша. Андый җирләрдә кул эшләнмәләрен сатып алучылар күп була икән.

– Әлбәттә, үз кибетләремне булдыру турында хыялланам, – диде яшь дизайнер. – Тик бу әлегә хыял гына. Ничек кенә булмасын, мин бер урында таптанмыйм. Ел саен яңа коллекция уйлап чыгарам. Даими сатып алучыларымның сүзенә дә колак салам. Бу минем өчен эш кенә түгел, ә күңелгә рәхәтлек, җанга ләззәт бирә торган шөгыль дә...

КАЗАННЫҢ ҮЗ СӨЛГЕСЕ БАР

Милли кием-салым, букча, бизәнү әйберләре эшләүче дизайнерларны барларга, алар белән аралашырга тотынгач, «Казан сөлгесе» искә төште. Әлеге бренд исеме күпләргә таныштыр. Проектның җитәкчесе – Гөлнара Нурмөхәммәтова. Гөлнараның эшкуар ханыма әйләнүе һәммәбезнең дә күз алдында булды. «Татарстан» радиосында эшләп, декрет ялына киткәч, яшь ана социаль челтәрләргә чигүле сөлгеләр куя башлады. Һәм «Казан сөлгесе» исеме астында үзенең брендын да булдырды. Бу бренд тиз арада популярлык яулады.

Бер карасаң, чигүле яулык, сөлгеләр безнең халык өчен яңалык түгел. Кадерле ядкарь булып, әбиләр сандыгында сакланган ул әйберләрне яңартып, Гөлнара Америка ачмаган. Бары халыкка нәрсә кирәклекне тоемлап, вакытында эшкә тотынган.

– Мәктәптә укыганда, Сабантуй бәйрәме алдыннан ярыша-ярыша кульяулык чигә идек бит, – дип «акланды» Гөлнара. – Шулай булгач, белгән һөнәремне яңарттым гына. Авылларда бүген дә чигү чиккән хатын-кызлар бар. Милли бизәкле киемнәр, заманча эшләнгән калфаклар, түбәтәйләр безнең халык өчен яңалык түгел. Ә өйдә кулланыла торган көнкүреш әйберләре сирәк. Шуны уйладым да: «Нишләп әле үзебезнең милли үзенчәлегебезне күрсәтмәскә? Аш бүлмәсендә – милли тастымаллар, юыну бүлмәсендә – милли сөлгеләр, йокы бүлмәсендә урын-җир комплектлары булмаска тиеш?» – дидем.

Гөлнара дөрес фикер йөрткән: көнкүрештә кулланыла торган милли бизәкле әйберләргә сорау зур булып чыга. Тормыш иптәше Азат та бу ниятне хуплый – эшне

бергә алып баралар. (Азат – профессиональ көрәшче, спорт остасы.) Һаман эзләнүдә алар – әле менә милли бизәкле көрәш костюмнары тегәләр.

Гөлнара шәхси эшмәкәр булып теркәлгән, ягъни салымнарны түләп, барысын да рәсми эшли. Тик Гөлнара кебекләр республикада күп түгел. Ни өчен дигәндә, бүген милли дизайнерларның күбесе теркәлми генә эшли, чөнки аларның әле эшләре тотрыклы түгел, бүген бар, иртәгә юк дигәндәй.

– Мин дә башта шәхси эшмәкәр булып теркәлми генә эшләдем,-диде. – Эшләр җәйләнып, ярдәмгә кешеләр алып, җәелеп эшли башлагач, күмәртәле заказлар барлыкка килде. Ягъни төрле оешмалар заказ бирә башлады. Ә алар бары документ буенча – шәхси эшмәкәрләр белән генә эшли. Шуңа күрә, телимме-юкмы, теркәлергә туры килде. Тик мин зарланмыйм, Аллага шөкер, тырышсаң, эшне алып барып була. «Салым түлә дә тыныч йокла!» – дигән сүзнең чын мәгънәсен аңладым хәзер.

Гөлнара сөлге, тастымалларга, урын-җир комплектларына рәсемнәрне компьютер ярдәмендә ясый. Ләкин һәр бизәкне үзе уйлап таба. Шуннан программаны чигә торган машина өчен көйлиләр. Һәм машина чигеп бирә. Моның өчен аерым кешеләре бар. Тукымаларның сыйфаты югары, Россиядә эшләнгән чын киҗе-ма-мыкны гына сатып ала. Бәяләргә килгәндә, сөлге-тастымаллар 300 сумнан 1 мең сумга кадәр, урын-җир комплектлары 3 мең сумнан 5 меңгә кадәр.

– Киләчәктә әбиләребездән килгән бизәкләрне яңартып эшлисем килә, – диде Гөлнара. – Аларга үсемлек, чәчәк бизәкләре мулдан төшерелгән бит.

– Гөлнара, эшләр болай җәйлыга киткәч, журналистиканы ташларсыңмы икән? – дим.

– Әлегә белмим, журналистика минем өчен бик якын. Ләкин «Казан сөлгесе» проекты да балам кебек кадерле. Ул да бит – иҗат. Әлбәттә, декрет ялында тик утырганчы дип кенә алынган идем... Хәзер инде кереп чумдым. Иртә белән заказны илтергә, тукымаларны алып кайтырга, кешеләр белән очрашырга кирәк. Шул арада Интернет, телефон аркылы сатып алучылар белән аралашам. Бер сәгатькә дә контрольне югалтырга ярамый, эшкуарлык шулай икән ул...

Гөлнара эшенә тагын да ныграк «кереп чумарга» җыена – ТР Икътисад министрлыгыннан эш башлаучы эшкуарларга бирелә торган грант алып, эшен тагын да киңрәк җәелдерергә уйлый.

...Сүз башында татар милли киемнәрен Россия күләмендә чыгару мөмкинме дигән идем бит. Әйе, мөмкин. Миңа калса, моның өчен иганәчеләр, эшкуарларны тартырга кирәк. Ә нәрсә, сорау бар, бары тик эшне системага кертеп, (әлбәттә, эш иң беренче акчага кайтып кала) бизнес-план төзеп эшләтеп җибәрергә генә кирәк. Милли кием, бизәнү әйберләренә Татарстанда гына түгел, ә Россиянең башка шәһәрләрендә дә ихтыяҗ зур. Шул ук Казанда эшләүче дизайнерлар да әйтеп тора: кул эшләнмәләрен Интернет аша чит илләргә дә еш соратып алалар.

Милли киемнәребез модага керде, монысы – бәхәссез. Әлбәттә, әлегә бу күренеш татарлар арасында гына күзгә ташлана, әмма тора-бара, бәлки, кызыгып китеп, башка халыклар да безнең милли бизәкле алка, чуәкләрне киеп йөри башларлар? Ә нәрсә, кызыгырлык бит!

ФАКТЛАР

Татар чигү сәнгатенең чәчәк аткан чоры XVIII–XIX гасырларга туры килә. Ул чорда алтын җеп белән чигү дә модада булган. Совет власте елларында алтын җеп белән чигү әкренләп юкка чыга.

Чигүне ике төргә бүлеп йөрткәннәр: шәһәрчә һәм авылча. Шәһәр чигүенә Көнбатыш модасы йогынты ясаган. Халык чигеше (авылча) элеккеге традицияләрне, йолаларны күбрәк саклап калган. Авылларда кыз балаларны 5 яшьтән кул эшләренә – эрләргә, тукырга, чигәргә, бәйләргә өйрәткәннәр. Унбиш яшькә җиткән кыз бала үзенә бизәкләп чигеп эшләнгән бирнә хәзерләгән.

Чигү үрнәкләрен Азия, Европа, Американың борынгы цивилизациясе һәйкәлләрендә очратырга мөмкин.

Автор:
Руфия Фазылова

ТӨБӘК ТАРИХЫ КЕМГӘ КИРӘК?

Язманы бер вакыйгадан башлыйм. Узган ел, «Мәңгелек кыйммәтләр. Авылларыбыз» рубрикасы кысаларында Саба районының бер авылы турында язган идек. Әлеге авылның тарихын яктырткан китап та чыккан иде. Язмада шул китап турында да әйттек, анда әйтелгәнчә, авыл якынча мең ел элек оешкан дип бирдек. Мәкалә басылып, берничә көн узгач, редакциягә китапның икенче авторы килде. «Анда дөрес мәгълүмат түгел. Безнең авыл мең ел элек оешмаган, ә соңрак», – диде. Озын сүзнең кыскасы, бергә эшләсәләр дә, авторларның фикере икегә бүленгән булып чыкты. Бу бәхәсле теманы куертмаска булдык. Ә шулай да күңелдә төер калды: ничек шулай соң? Фикерләр ни өчен икегә бүленгән? Төбәк тарихына багышланган китапларны берәр фәнни оешма карап, күзәтеп барамы? Шуны ачыкларга булдык.

КИЛӘЧӘККӘ ТАПШЫРЫР ӨЧЕН...

Тарихтан беләбез: татарның күп кенә танылган шәхесләре – Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Һади Атласи, Ризаэтдин Фәхретдинов һәм башкалар татар тарихын өйрәнү белән шөгыльләнгән. Алар барысы да XIX–XX гасыр башында яшәгән кешеләр. Милләтебезнең бу акыллы затлары төрле төбәкләрнең тарихына кагылышлы күп кенә хезмәтләр дә язып калдырган.

Тик шуннан соң упкын барлыкка килгән, диярсең. Сәбәбе – Сталин репрессияләре. Төбәк тарихын профессиональ, фәнни нигездә өйрәнүчеләрнең күбесе репрессия корбанына әверелә. Әйе, репрессияләр татар элитасының бик күп зыялыларын юк итә, әмма «төбәк тарихын өйрәнү» өлкәсендә хезмәт куючыларның тулы бер плеядасын кырып ташлаганнан соң, бу тармак озак еллар дәвамында мантый алмый. Хәер, СССРдагы ул чор вазгыятендә аның актуальлеге дә әллә ни булмый...

Бу өлкәдә җанлану дистә еллардан соң, XX гасырның өченче, дүртенче чирегендә генә яңадан сизелә башлый. Ә Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек тарихчыларның хезмәтләре таяну ноктасына әйләнә.

Бүген республикада якынча 2 мең авылның тарихы китап рәвешендә дөнья күргән. Татарстанда 4 мең 300 авыл барлыгын исәпкә алсак, әле ике саланың берсенең тарихы, үткәне өйрәнелмәгән булып чыга. Тагын бер кызыклы сан. Төбәк тарихына багышланган китаплар саны районы-районы белән дә аерыла. Мисал өчен, Чирмешән районында 43 авыл бар һәм аларның тарихы буенча 80нән артык китап нәшер ителгән. Ә аерым бер районда 10 китап та юк. Бу күп очракта район җитәкчелеге игътибарыннан, шундагы эшмәкәрләрнең, иганәчеләрнең үзаңыннан тора. Туган як тарихы аларга ни дәрәҗәдә кирәк тә, никадәр кызыклы?

Тарихчы галимнәр хафаланмаска киңәш итә – әлеге курс белән барсак, барлык авылларның да тарихын өйрәнеп, киләчәк буыннарга тапшырырга мөмкин булачак. Һәрхәлдә, шуңа өмет, ышаныч һәм мөмкинлекләр дә бар икән.

Мөмкинлекләр нинди дигәндә, бер ел элек рәсми рәвештә Татарстан Республикасының татар төбәген өйрәнүчеләр җәмгыяте оешкан. Монда татарлар да, чувашлар да, башка милләт вәкилләре дә бар. «Теркәгәндә географик урынчалыкка бәйләр өчен генә оешманы «татар төбәген өйрәнүчеләр» дип атадык», – дип аңлатканнар иде Бөтенроссия татар төбәк тарихы съездында. Ә максаты – бөтен төбәк тарихын өйрәнүчеләрне бергә туплап, фикер алышу, мәгълүмат белән бүлешү.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе **Альберт Борһанов** белән төбәк тарихы китаплары, аның авторлары турында сөйләштек.

– Татарның зыялы шәхесләре элек-электән үз тарихлары белән кызыксынган, – диде ул. – 1920 нче елларда Татарны өйрәнү («Татароведение») үзәге төзелә, шуның нигезендә татар авыллары барлана. Сталин чорында төбәкчеләрнең эше туктатыла. 1960 нчы елларда галим Равил Фәхретдинов һәм башкалар тарафыннан әлеге мәсьәлә кабат кузгатыла. Ә 1990 нчы елларда яңа дулкын калыкты: үз авылларының тарихын язучы үзешчәннәр барлыкка килә башлады. Китап нәшер итәргә булышучы эшмәкәрләр дә табылды. Бу безнең милләт өчен яңа, бик сөенечле баскыч.

Эшне алга таба да дәвам итәргә кирәк. Беренчедән, археологик казу эшләрен алып барырга. Төбәк тарихына багышланган күп китапларда археологиягә кагылышлы мәгълүмат юк. Әле бүгенге көндә дә өйрәнелмәгән археологик һәйкәлләр бар. Икенчедән, эпиграфика, ягъни кабер ташлары юкка чыгып бара. Алар, үзләрендә бик күп мәгълүмат саклаган килеш, җир астына китәләр – иңеп югалалар. Аерым районнар бөтенләй өйрәнелмәгән. Өченчедән, үткән гасырларда өйрәнелми калган архитектура объектлары бихисап. Монда мәчетләр, чиркәүләр, мәдрәсәләр дә керә. Алар өйрәнелмәсә, күпме тарихны белми калабыз дигән сүз. Дүртенчедән, сәнәгать объектлары. Татарның бит үз сәнәгате бар, аны күрүче генә юк...

«ХАЛЫК ХӘТЕРЕ – МӨҺИМ ДОКУМЕНТ»

Нурулла Гариф, язучы, галим, тарих фәннәре кандидаты:

– Мин үзем төбәк тарихына багышланган егермедән артык китап авторы. Әле тагын дистәләп авторга китапларын эшләргә ярдәм иттем. Бүген дә шушы юнәлештә эшлим. Башлап шуны әйтәсем килә: авыл китабын язу бик авыр эш. Мин аны диссертация язуга караганда да авыррак дияр идем.

Кызганыч, документлар белән эшләү шактый катлаулы. Ни өчен дигәндә, барлык документлар да диярлек Мәскәү, Уфа архивларында. Анда барып, ниндидер мәгълүмат алыр өчен шактый акчалар, вакыт кирәк. Мисал өчен, гел шул өлкәдә эшләгәч, архивларда минем таныншларым бар. Документларны табу, алу җаен беләм. Ә бит авыл тарихын профессионаллар гына язмый.

Туган төбәге тарихы белән кызыксынучыларга эшне авыл өлкәннәре, гаилә архивындагы булган фотоларны өйрәнүдән башларга киңәш итәм. Халык хәтере бик мөһим документ ул. Сәяси вакыйгалар белән бәйле күп кенә документлар юк ителгән. Тик ул фаҗигаләрне күргән кешеләрнең оныклары исән. Алар ата-бабалары сөйләп калдырган шактый мәгълүматларны сөйләп бирәләр.

Искәндәр Гыйләҗев, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры:

– Тарих – шулкадәр кызыклы, гаҗәеп дөнья ул: аның бөтен нечкәлекләрен аңлап та җиткереп булмый. Әгәр дә профессиональ тарихчы билгеле бер теманы өйрәнә икән, ул аны үз күзлегеннән карый, әмма тарихның бөтен нечкәлекләрен күреп бетерә алмый. Шуңа да бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга кирәк дип саныйм. Бу очракта профессиональ тарихчылар үзешчәннәр белән бергәләп эшләргә тиеш. Без бер-беребезне баетабыз гына бит.

«ХУҖАСЫЗ КАЛГАН СФЕРА»

Сүз башында төбәк тарихына багышланган китапларны берәр структура күзәтеп барамы дип сорау куйган идем. Баксаң, нәшриятка киткәнче кульязмаларны карап, тикшереп чыгучы махсус кешеләр юк икән. Моның сәбәбен, гомумән, төбәк тарихына кагылышлы аерым проблемаларны безгә тарих фәннәре докторы **Дамир Исхаков** аңлатты.

– Иң беренче эш итеп шуны әйтим: хәзер һәр теләгән кеше китап чыгара ала. Ничек уйлый, теге яки бу вакыйганы ничек күрә, шулай тота да яза. Бу яктан авыл тарихына багышланган китаплар аерым бер урынны алып тора, дип әйтә алмыйм. Җирле тарихчыларның күбесе иганәчеләрне эзли, ә калганы техник мәсьәлә, дип кенә карыйлар. Әлбәттә, китапны нәшер иткәнче, башта галимнәргә мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Тик моның аерым таләбе юк. Татарстан эчендә җиңелрәк ул. Әле бит читтә чыга торган китаплар да бик күп. Анда яшәүче милләттәшләребезгә Казанга килеп җитәргә, безне эзләп табарга кирәк. Менә шуларны уйлап, күздә тотып, Бөтенроссия тарих төбәк җәмгыяте оештырып ятабыз. Әле ул рәсмиләшмәде. Әмма шундый оешма кирәк дигән карар бар, аның съезды үтте. Ул төзелеп, юридик яктан документлаштырылса, Татарстаннан читтә дә эшләргә мөмкин булачак. Төбәк тарихын өйрәнүчеләр арасында профессиональ тарихчылар да бар. Чит төбәкләр белән контактлар булдырып, бергәләп эшләргә тиешбез. Шулай ук Төбәк тарихын өйрәнүчеләр» җәмгыяте оештырдык. Устав нигезендә ул ТР Юстиция министрлыгында расланды.

Дамир Мәүлиевич төбәк тарихына багышланган китапларга даими рәвештә рецензияләр яза икән. Ләкин галим яшерми, бу шактый катлаулы эш. 500 битлек кульязманы укып, анализ ясар өчен шактый вакыт кирәк. Өстәвенә, бу хезмәт өчен түләнми дә бит.

– Чынлыкта төбәк тарихларының барысын да галимнәр карап, анализлап чыгарга тиеш, – диде безгә Дамир Исхаков. – Чөнки алар чыганакларны, тарихны яхшырак беләләр. Дөресрәк фикерләр кертергә мөмкиннәр. Ялгышларын исә – дөресләргә.

Нигездә, авыл тарихы китапларын җирле һәвәскәрләр, укытучылар, журналистлар яза. Юк, алар белемсез шәхесләр түгел, әмма тарих буенча фундаменталь белемнәре булмаска мөмкин. Шуңа күрә тарих буенча методик ярдәм таләп ителә. Минемчә, моның белән Тарих институты шөгыльләнергә тиеш. Кызганыч, әлегә төбәк тарихына рецензияләр язу белән шөгыльләнер, юл күрсәтүче була алырлык конкрет оешма да, кешеләр дә юк. Бу хуҗасыз калган сфера кебек...

«Рецензиясез китапларны бастырмагыз», – дип нәшриятләргә киңәш тә бирергә була, тик мәҗбүр итеп булмый. Ә хосусый нәшриятләрдә теләгәнеңне бастырырга була. Миңа калса, тарихка кагылган китапларның кулъязмасын кабул иткәндә һәм бастырганда «рецензияләре булырга тиеш» дигән таләп катгый куелса әйбәт булыр иде. Рәсмиме, ярымрәсмиме, анысы мөһим түгел.

Ничек кенә булмасын, тарих фәннәре докторы төбәк тарихчыларына карата һәрвакыт хәерхахлы мөнәсәбәттә икән. Кулъязмаларны да кире бормый.

– Яшермим, сыйфатсыз китаплар була, рецензия язудан баш тартканым бар, – ди. – Тик шулай да төбәк тарихы буенча китапларның күпчелеге чыганаклар һәм тарих буенча язылган. Әлбәттә, профессиональ дәрәҗәдә түгел, әмма шактый якын. Шуңа күрә аларны үткәреп җибәрергә тырышабыз. Профессиональ тарихчылар өчен дә төбәк тарихы китаплары файдалы, алардан үзебез дә кулланабыз. Безнең кул бөтен җиргә дә җитми, без бит күп түгел. Шулай булгач, төбәк тарихын өйрәнүчеләр күпмедер дәрәҗәдә безнең эшне дә башкара. Бары ике араны җайга салып, бергәләп эшләргә генә кирәк.

...Бүген иҗат ягыннан бернинди киртә, цензура юк. Җырчылар сәхнәгә теләсә нинди материал алып чыга. Бу әдәбиятка да кагыла, акчаң булса, рәхәтләнеп проза, поэзия җыентыгы чыгара аласың. Тик авыл тарихына багышланган китаплар үзгәрәк. Күпмедер дәрәҗәдә алар тарихи документ буларак та киләчәк буыннарга барып җитәчәк бит. Шулай икән, һәр төбәк тарихына багышланган китап рәсми чыганакларга таянып, тарихчылар күзлегеннән тикшерелсен иде дигән теләктә калам.



СТРАТЕГИЯ – МИНЕМ ФИКЕР

Журналыбызның соңгы санында Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү турында фикерләр биреп барачакбыз дигән идек. «Вәгъдә – иман», дигәндәй, яңа елда да әлеге теманы дәвам итәбез. Узган санда Ленинград өлкәсе Тосно шәһәренең «Изге юл» татар җәмгыяте җитәкчесе Иниятулла Кутуев: «Читтә яшәүче татарлар өчен татар йортлары төзергә кирәк», – дип әйтте. Бу санда сүзне эшмәкәр яшьләргә бирәбез. Документны алар ничек күзаллый?

«ЮК, МЕНӘ БҮГЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ!»

Тәуфыйкъ Хисамов,
Мәскәү шәһәре

Фото Тәуфыйкъ Хисамовның шәхси архивыннан

– Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан Татар халкы үсеше стратегиясе буенча Мәскәү татар җәмгыятендә сөйләшү булды. Әйе, мондый түгәрәк өстәлләр бик кирәк. Тик эш сүздә генә калмыйча, аның нәтиҗәсе дә булсын иде...

Татар – талантлы милләт. Татарлар Россия буйлап кына түгел, ә бөтен дөнья буйлап таралып яши. Миңа калса, мөһим документны раслаганда, имзалаганда, читтәге милләттәшләребезнең фикерен дә исәпкә алырга кирәк. Ни өчен дигәндә, араларында Татарстан, Россиядә генә түгел, ә бөтен дөньяга билгеле шәхесләр бар. Аларның фикерләренә, тәҗрибәсенә колак салу да файдага булыр иде.

«Стратегия нинди булырга тиеш?» дигән сорауга килсәк, миңа калса, эшне беренче чиратта икътисад, социология белгечләре белән сөйләшүдән башларга кирәк. Икенче адым – татарның аксакаллары белән фикер алышу булырга тиеш. Мисал өчен, күптән түгел арабыздан киткән Әгъдәс Борһанов Татар халкының үсеше стратегиясен төзү турында күп уйланды, күп язды. Шундый галим, зыялыларыбызның хезмәтләренә таяну әйбәт булыр, дип уйлыйм. Галим стратегияне ике яссылыкта күрә иде. Аның беренчесе – хосусый милек җәмгыятьләре төзү. Ни өчен кирәк бу һәм нәрсә бирә? Безгә мәдәни, милли проблемаларны хәл итү өчен финанслар кирәк. Яшерен-батырын түгел, бүген татарлар нигездә хөкүмәткә өметләр баглый. Безнең теге яки бу фикеребезне хупларлармы, кутәреп алырлармы? Ә хосусый милек җәмгыятьләре, үзара оешып, аерым бер кооперация төзесә, күп кенә проблемаларны хәл итә алырлар иде. Тарихка күз салсак, революциягә кадәр татар зыялылары үзебезнең меценатлар ярдәмендә чын мәгънәсендә милли алгарышка ирешә алган. Зыялы байларыбыз мәчетләр, мәдрәсәләр салдырган, шәкертләргә Шәрык илләренә барып укырга булышкан. Газета-журналлар, нәширлек эше дә меценатлык ярдәменнән башка ул кадәр алга китә алмас иде...

Сорау туа: нәрсә, бүген андый эшкуарларыбыз юкмыни? Бар, әлбәттә. Тик аларның үзаңы әле моңа әзер түгел. Менә бу иң четерекле мәсьәлә. Хәер, яшьрәк буын, мисал өчен, безнең чор ир-егетләре, инде меценатлыкка әзер. 90 нчы елларга караган буындагы эшкуарлар әле моңа әзер түгел. Бу аңлашыла да, Советлар Союзы җимерелгәч, алар җитешсезлек, билгесезлек чорында яшәгән. Шуңа да алар аңында күпмедер дәрәҗәдә шикләнү-саклану, үзеңне генә кайгырту тенденциясе сизелә. Ә бүгенге яңа буын эшкуарлары инде бөтенләй икенче төрле фикер йөртә. Ни дисәң дә, без җитеш заманда үскән, чит илләргә чыгып йөргән яшьләр.

Чит илләрдә йөргәндә, шул ук күпмилләтле Латин Америкасына баргач, күрәбез: анда халыкның милли йөзе, үзенчәлеге югары бәяләнә. Татарның да үз йөзе бар бит. Аны башка халык белән бутап булмый. Моны башка милләтләр дә таный. Яшь буын да менә шушы кыйммәтләрне аңлый, күрә. Шуңа да аның ата-бабаларыннан килгән традицияләрен, телен, динен, ягъни үз йөзен югалтасы килми. Минемчә, яшьләр татар исемле бөек милләтнең юкка чыгуына ирек куймаслар. Һәрхәлдә, мин моңа ышанам...

Сүз башында аксакалабыз Әгъдәс Борһанов Стратегияне ике яссылыкта күрә иде, дидем. Димәк, аның беренчесе – хосусый милек җәмгыятьләре оешып, аларның бер милли кооперация хасил итүе. Икенчесе – милли-мәдәни автономияләрнең эшен яңарту, үстерү. Белгәнебезчә, бездә федераль һәм региональ дәрәҗәдәге автономияләр бар. Кызганыч, 90 нчы елларда башланган реформа азагына кадәр эшләнеп бетмәде. Бүген милли-мәдәни автономияләр үз эченә бикләнеп утыра кебек, ачылып китеп яши алмый. Аларның эше Сабантуй үткәрү белән генә чикләнергә тиеш түгел. Тагын бер мәсьәлә: милли автономияләрдә буыннар алмашы юк, ә бу бик кирәк. Ул яктан безнең Мәскәүдә үзгәрешләр сизелә башлады: җитәкчелек азмы-күпме яшьләр белән эшләргә керешә.

Милли-мәдәни автономияләр нәрсә эшләргә тиеш соң? Балаларны ана телендә укыту – иң беренче бурыч. Моны автономия җитәкчеләре оештыра ала. (Без Мәскәүдә соңгы елларда шуның белән шөгыльләнәбез.) Тәҗрибәдән күренгәнчә, яшь ата-аналарның балаларын татар итеп тәрбиялиселәре килә. Һәм тагын шундый нәтиҗәгә дә килдем: закон нигезендә милли телләр кысылгач, ата-аналарда, әйтерсең, процесска каршылык йөзеннән, үзебезне саклау инстинкты уянып, балаларына ана телен өйрәтүне беренче планга куйды. Элек без: «Ярар, кайчан да булса да өйрәнербез әле», – диеп йөри идек, хәзер исә: «Юк, менә бүген өйрәнәбез!» – дибез.

Әзерләде:
Руфия Фазылова

facebook.com/protatarstan

Реклама 16+

ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Тутырган тавыкны **КАЙДА** оста пешерәләр

Фатир мәсьәләсен **НИЧЕК** хәл итәргә

Иң матур чыршы **КАЙСЫ** районда

Премьер-лига лидерлары **КЕМНӘН** курка

Кенәз Оболенский тегермәне **КАЯ** качкан

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

АКСУБАЙЧА ТУТЫРГАН ТАВЫК

Моннан берничә ел элек эш сәфәре белән Аксубайга баргач тутырган тавыктан авыз иткән идем. Ак ит сап-сары йомырка белән «реакция»гә кергән дә тәме буенча үзенә бертөрле ризыкка әйләнгән. Менә шул ризык ни өчендер күңелгә кереп калды. Бер Аксубайга барып, тутырган тавык пешерергә өйрәнеп кайтырга кирәк әле, дип уйлап йөрсәм дә, һич җае чыкмады. Форсат дигәне Яңа елны көткән икән...

Автор:
Руфия Фазылова

«КОНКУРЕНЦИЯ КИРӘК...»

Аксубайда татар авыллары чагыштырмача күп түгел. Ләкин алар традицияләрне саклап, күмәкләшеп, матур итеп яшиләр. Динле халык биредә. Бер авылда икешәр, өчәр мәчет булу да – гадәти күренеш.

Тутырган тавык пешерергә Кызыл Тау авылына бардык. Могыйновларда – укытучылар гаиләсендә булдык. Хуҗабикә Гөлсинә апа гомер буе мәктәптә балаларга алгебра, геометрия укыткан. Тормыш иптәше Искәндәр абый – тарих укытучысы, күрше Иске Кыязлы авылының төп белем бирү мәктәбендә директор булып эшли. Гөлсинә апа узган елда лаеклы ялга чыккан, ләкин әле дә эшен дәвам итә.

– Мәктәптән китимме дип тә уйлаган идем, җибәрмәделәр, – дип, тыйнак кына елмайды Гөлсинә апа.

– Миңа терәк кирәк бит! – дип куйды Искәндәр абый.

Баксаң, Искәндәр абый мәктәп директоры булып яңа уку елыннан гына эшли башлаган икән. Дөрес, 2001 елдан 2011 елга кадәр бу вазыйфаны бер башкарган булган инде. Аннан шунда ук тарих укыткан. Менә яңадан җитәкче итеп куйганнар үзен.

Иске Кыязлы мәктәбе әлегә кадәр урта мәктәп булып саналган. Яңа уку елыннан тугызъеллыкка калган. Статусны үзгәртүнең сәбәбе бик гади – 10 нчы сыйныфка килүче бала булмаган. Тугызынчыны 10 бала тәмамласа да, барысы да укырга Казанга киткән.

– БДИны тапшырырлык яхшы укучылар да бар иде, калырга теләмәделәр, – ди Искәндәр абый. – БДИдан шулкадәр куркалар. Югыйсә укытучылар аерым да шөгыльләнә инде үзләре белән. Бер-берсеннән күреп тә шәһәргә китәләрме шунда, аптыраган.

Бүген Иске Кыязлы төп белем бирү мәктәбендә 39 бала белем ала. Бер генә укучылы сыйныф та бар икән. Ә сигезенче сыйныф бөтенләй юк.

– Балалар бакчысына 10 бала йөри, – диде Искәндәр абый. – Бакчага киләсе тагын унга якын сабый бар. Шулай булгач, мәктәпнең, кимендә, ун-унбиш еллык киләчәге бар әле. Әлбәттә, бик авыр вазгыять. Тик бу бездә генә түгел, республиканың бик күп авылларында шушы хәл бит.

– Бала саны аз булу укучы, укытучы өчен әйбәтме? Һәр укучы белән аерым эшләргә була кебек, – дим.

– Моңа бер яклы гына итеп җавап биреп булмый. Әлбәттә, укучыларга игътибар күбрәк тия. Ләкин бит һәр баланың «максимум»ы бар. Аның белән күпме эшләсәң дә, артыгын барыбер алмый ул. Аннан, укучыларга да конкуренция кирәк, үзара ярыша-ярыша укырга тиешләр.

ГӨЛСИНӘ МОГЫЙНОВАДАН ТУТЫРГАН ТАВЫК РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:

1. Тавык – 1 данә
2. Сөт – 1 стакан
3. Йомырка – 8–10 данә
4. Каймак яки сөт өсте – 1 стакан
5. Тоз – тәменчә

Фото: Лилиана Вәлитова

Редакция кухнясы

АВЫЛНЫКЫ – БЕРЕНЧЕ!

Искәндәр абый белән сөйләшеп алган арада Гөлсинә апа ризык әзерләү барышында кирәк булачак әйберләрне җай белән генә өстәлгә тезеп куйды. Укытучыларга хас пөхтәлек, зыялылык бар аңарда.

– Гөлсинә апа, гадәттә тутырган тавыкны кунакларга әзерлисезме? Әллә ул көндәлек ризыкмы? – дим.

– Хәзер инде көндәлеккә әйләнеп бара. Ә элек зур мәҗлесләргә, ашларга гына әзерли торган идек. Балалар кайтасы булса, тавыкны йомырка белән тутырып пешерәм. Аның бит шулпасы да әрәм булмый, токмачлы аш итәсең.

Һәр ризыкның үз сере булган кебек, тутырган тавыкка, мәсәлән, авыл йомыркасы кирәк икән. Ни өчен дигәндә, сарысының төсе куерак була. Ә димәк, тавыгыбыз да матур, сары булып пешә.

– Элек әбиләр, әниләр тавыкның тиресен ачып, йомырканы шунда агызалар иде, – дип сүзен дәвам итте Гөлсинә апа. – Хәер, әле без дә шулай итә идек. Соңгы биш-ун елда гына заманчалаштык – йомырканы тавык тиресенә шприц белән тутырабыз. Ничектер шулай җайлырак күрәбез. Йомырка тавыкның бөтен җиренә, мускулларына кадәр кереп сеңә.

Тавык тутырганда, хайваннар өчен каралган шприц кулланалар икән. Аны халык район ветеринария бүлегеннән барып ала. Анда исә нигә алганнарын беләләр, хәтта сорап та тормыйлар, бирәләр ди.

– Гади шприцның энәсе кечкенә, йомырка сарысы кысып чыгарганда тыгыла, – диде хуҗабикә.

Гөлсинә апа килүгә безне кисәтеп куйган иде: авылда ут беткән. Ә бу ризык әзерләгәндә аерым кыенлыклар тудырачак иде, чөнки тавык эченә саласы эчлекне блендер белән бутарга кирәк.

– Ярар, кул белән болгатып карармын, төерләре калмаса инде, – дип куйды хуҗабикә, борчылып.

Гөлсинә апа башта йомыркаларны кәстрүлгә салып болгатты. Аннан аңа каймак салды һәм янә бутады. Шуннан сөт өстәде һәм тоз сипте.

– Минем каймак сепараттан чыккан, бик куе, – диде, эштән буленмичә. – Кибет каймагы яки сөт өсте дә ярый. Хәзер бит авылда да күпләр сыер асрамый, сепарат каймагы бөтен кешедә булмаска мөмкин. Блендер бу массаны тиз арада бер куелыкка кертә, төерсез итә. Кул белән бутап бетереп булырмы инде, белмим...

Гөлсинә апа массаны шактый озак туглады. Ахыр чиктә, йомырка белән каймак кушылып, сап-сары сыекча хасил итте.

– Шәһәр кешесендә мондый эчлек булмаячак, – дим. – Авыл ризыкларыннан тутырган тавык шуңа да тәмлерәк буладыр...

– Юк, кибет ризыкларыннан да ясыйлар аны. Әйбәт була, борчылма. Минем дә тавыгым кибетнеке әле. Үстергән тавыкларны ашап бетердек инде. Әбиләр чакырып аш уздырган вакытта да кайчак кибет тавыгыннан әзерлибез. Ул бит тиз пешә, ите йомшак була. Авыл тавыгын ике сәгать пешерергә кирәк.

«КҮРДЕМ ДӘ, КҮЗ УҢЫННАН ЫЧКЫНДЫРМАДЫМ...»

Эчлек әзер булды. Гөлсинә апа зур кәстрүлгә су куеп җибәрде. Суган, кишер кебек яшелчәләр салып тормады.

– Тоз салам да шуның белән шул, – диде.

Гомумән, тутырган тавык үз тәме белән генә әзерләнә икән. Борыч, башка тәмләткечләр дә кирәк түгел ди.

Эшкә кереште хуҗабикә. Карап торышка бу хирургиянең бер этабына тиң күренеш, диярсең. Гөлсинә апа шприцка эчлекне тутырды да тавыкның төрле җирләренә кадый башлады. Башта түш җирләренә, аннан канат өлешләренә. Шуннан тавыкны икенче ягына әйләндерде. Тавык исә кабарып, түгәрәкләнеп килә торды. Үзе бер хикмәт!

– Тәки булды бит бу! – дип, җиңел сулап куйды хуҗабикә. – Блендерсыз да эшләп була икән.

Ул арада кәстрүлдә су кайнап чыкты. Гөлсинә апа тавыкны күтәреп газ плитәсенә юнәлде. Шуны гына көткән кебек, хатыны янына Искәндәр абый йөгереп килде. Икәү бергә җайлап кына түшкәне кайнап торган суга салдылар. Мин исә бу хәлне тын да алмыйча күзәтәм. Хуҗабикә карашымны сизде, ахрысы, елмаеп җибәрде:

– Без шулай инде, бөтен эшне бергә эшлибез, – дип куйды.

Могыйновларның гаилә корып яши башлауларына 33 ел булган. Өч балалары бар – ике кыз, бер ул. Айгөл белән Алсинә кияүдә, икешәр бала үстерәләр. Төпчек уллары Илфат, югары белем алып, хәрби хезмәткә киткән.

– Краснодар краена эләкте, армиягә бик теләп китте, – диде ата кеше.

Искәндәр абый җор телле. Теләсә кайсы сүздән мәзәк ясый. Гөлсинә апа белән очрашып йөргән вакытларын да кызык итеп сөйләде.

– Икебез дә Кызыл Тау авылыннан булып, бер мәктәптә укысак та, Гөлсинәгә күз төшереп була торган кыз итеп карамаганмын баштарак. Мәктәпкә студентлар

очрашуына баргач, күреп алдым да үзен, аптырап киттем. Буйга үсеп, матураеп, тәмам өлгереп җиткән. (Ир белән хатынның яшь аермасы 3 ел. – Авт.) Мин Алабуга дәүләт педагогия институтында укыдым, ә ул – Казан дәүләт педагогика институтының математика бүлегендә. Шуңа да юллар кисешмәгәндер. Күрдем дә бүтән күз уңыннан ычкындырмадым. Гел саклап кына йөрттем. Иске Кыязлы мәктәбенә эшкә үзем чакырып кайтардым. «Синсез мин нишлим?» – дидем.

– Кыю иде ул, – дип сүзгә кушылды Гөлсинә апа. – Хәер, хәзер дә шулай. Кешеләр белән аралашырга, юктан да кызык табарга ярата. Телефонын ачып карасаң, кемнәр генә юк анда. Күргән бөтен кешесен фотога төшереп, балаларга, туганнарга җибәреп ята. Тынгысыз кеше инде.

Ул да түгел, Искәндәр абый безне дә телефонына төшереп, кемнәргәдер җибәреп өлгерде.

– Истәлеккә калсын, – дип елмайды.

ЮКА БЕЛӘН ТОКМАЧЛЫ АШ

Тавык пешкән арада хуҗабикә табын әзерли башлады. Өстәлгә кайнатылган каймак, корт, катык чыкты.

– Барысы да үзебезнеке, – диде Искәндәр абый.

– Мактәп эшегез дә бар. Гафу итегез, яшегез дә унсигездә түгел, сыер асрау мәшәкать тудырмыймы? – дим.

– Юк инде, – диде хуҗа кеше. – Коллегалар: «И, сыерсыз бик рәхәт, сез дә бетерегез», – дип киңәш биргән була. «Безнең рәхәттә яшисе килми», – дип кенә җавап кайтарам.

– Дөресен генә әйткәндә, быел сыерны бетерикме дип тә уйлаган идек, – дип, тормыш иптәшенең сүзенә кушылды Гөлсинә апа. – Сыер буазлаган иде, җәлләдек. Бозаулап та куйды. Без сыерсыз тормышны белмибез. Рәхәте шул – иртән савасы юк. Тик гел кешегә сөт сорап керү дә рәхәт түгел. Җәй буе балалар, оныклар монда яши. Рәхәтләнеп катыгын, каймагын ашыйлар. Сөтне җыючыларга тапшырганыбыз юк. Әле кортын, эремчеген, башкасын ясыйм. Балаларга, туганнарга, дусларга бирәбез. Искәндәр – юмарт кеше, шулай кешегә бирүдән тәм таба. Бер сыер белән бер бозауны гына карарга була әле.

Гөлсинә апа табынга тагын бер ят ризык чыгарды – юка. Әмма бу без журналыбызның алдагы бер санында сезгә тәкъдим иткән юка түгел. Кетердәп торган нәзек камырлы ризык ул. Бу да Аксубай якларында әзерләнә икән.

– Туй мәҗлесләренә, Коръән ашларына юка пешерми калмыйбыз, – диде хуҗабикә. – Тагын аны Корбан, Ураза гаетләренә дә әзерлибез. Бер рәтен белгәч, бик җиңел эшләнә ул. Кош теле рецепты кебек: камыр йомыркага басыла. Аннан аны җәеп, кайнар табага саласың. Өстенә кайнап торган сыек май агызасың. Шуны электр мичендә пешерәсең. Табынга тәлинкәгә өеп чыгарасың.

Тавык кырык биш минут дигәндә пеште. (Ярты сәгатьләп кайнагач, Гөлсинә апа кәстрүлдә килеш әйләндереп тә алган иде). Шуннан ирле-хатынлы ипләп кенә тавыкны шулпадан алдылар.

– Менә бу бик мөһим процесс, – диде хуҗабикә. – Бигрәк тә тавыкны кунакларга чыгарасы булганда. Тавык изелеп китеп, бөтенлеген югалтырга мөмкин. Шуның өчен аны җәй белән генә алырга кирәк.

Менә ул тутырган тавык... Хуш исле пар чыгарып, матур булып балкып тора. Шуңа игътибар иттем: тавык кечерәймәгән. (Гадәттә шулпада пешкән тавык массасын югалта бит).

– Искәндәр, мәле, кис, – дип, Гөлсинә апа иренә пычак китереп бирде.

Ул арада үзе шулпага токмач салды. Шулпа дигәннән, ул бик үзенчәлекле. Йомырканың сарысы таралып киткән, шулпа димәссең дә.

Искәндәр абый итне бик оста итеп турады.

– Тәҗрибә бар, ахрысы, сезнең? – дип шаяртам.

– Бар, итне кисү гадәттә минем өстә, – диде хуҗа.

Тавык кисәкләренә күз салам: бик үзенчәлекле – сырлы-сырлы булган. Дөрес, ит төсе үзгәрмәгән, ак килеш калган, әмма йомырка белән чиратлашкан кебек.

Ул арада Гөлсинә апа йомыркалы шулпада пешкән токмач ашын да табынга чыгарды. Авыз итәбез... Шулпа тәме бөтенләй үзгә: йомырка тәме үзен сиздерә. Ит тә сусылрак кебек... Безгә ошады!

Авыздан сулар килдеме? Пешереп карагыз, әллә ни авырлыгы юк кебек. Аксубайлылар белми генә тавыкны шулай әзерләми. Якыннарыгыз гаҗәпләнсен әле!

1. Сытабыз!

2. Салабыз!

3. Өстибез!

4. Тозлыйбыз!

5. Туглыйбыз!

6. Суыртабыз!

7. Тутырабыз!

8. Әйләндерәбез!

9. Алабыз!

10. Бизибез!

БӘХЕТ АЧКЫЧЛАРЫ

Буран никадәр генә котырынмасын, 16 гыйнварда Казанның «Салават Күпере» микрорайонында җыелган халыкның кәефен төшерә алмады. Гаҗәп түгел: әле генә куллануга тапшырылган 340 фатирлы йортта яшәргә тиешле кешеләргә фатир ачкычлары тапшырдылар. Яңа өйгә аяк атларга ашкынган кешеләрнең йөзендә бәхет балкый.

Автор:
Алёна Кутыркина

Республикада социаль ипотека программасы эшләп киткәннән соң, 116 мең ярымнан артык гаилә ташламалы шартларда торак алды. Бу йортта фатирлар бюджеттагыларга, социаль өлкә хезмәткәрләренә, ягъни фатирларны базар бәясеннән сатып алу авыр булган кешеләргә бирелде. Социаль ипотека булышты.

Рәсми өлешне артык озакка сузып тормадылар. Яңа йортка күченүчеләрнең (күпләр гаиләләре белән килгән иде) тизрәк фатир бусагасын атлап керәсе килә. ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды башкарма директоры урынбасары Рөстәм Гыйлаҗев моны аңлый:

– Сез көчәсе фатирларның җылы, уңайлы булуын, озак еллар дәвамында күңелләрегезне җылытып торуын телим!

Алга таба – зур булмаган формальлекләр, документларны тутыру этабы, аннан инде фатирлар буйлап таралышырга да була.

Фото авторныкы.

«Салават Күпере» торак комплексы.

Хәмзиннар гаиләсе.

ТУЛАЙ ТОРАКТАН – «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НӘ

Яңа йортта Хәмзиннар өч бүлмәле фатир алган.

– Хатыным РКХндә шәфкать туташы булып эшли, – дип сөйли гаилә башлыгы Айрат Фазыйхович. – Соципотека республика программасы турында без күптәннән белә идек, ләкин озак вакыт чиратка басарга кыймый тордык, нәрсәгәдер ышанып бетми идек... 2010 елда, ниһаять, бер карарга килдек. Озак көттекме? Фатирны алдарак та алырга мөмкин иде, ләкин бөтен вариантлар да безгә туры килмәде, сайладык.

Хәмзиннар гаиләсендә ике бала тәрбияләнә. Кызлары Алинә көллияттә укый, ә уллары Алмаз – әлегә мәктәптә. Дүрт җан 18 квадрат метрлы тулай торак бүлмәсендә яшәгәннәр. Хәзер аларның иркен – 80 квадрат метрлы өч бүлмәле фатирлары бар. Дөрес, эшкә шәһәрнең икенче башына йөрергә туры киләчәк, ләкин Хәмзиннарны бу куркытмый. Инфраструктура үсәр, яхшы эш урыннары да якындарак пәйда булыр, дип ышаналар.

Гаилә башлыгы ачкыларны улына бирә: яңа фатир ишеген ул ачып керсен.

– Минем бала чагымда да шундый очрак булды. Үземнең әти-әнием фатир алгач та, ишекне ачып керер өчен ачкычны миңа биргәннәр иде. Гаиләбезнең үзенә күрә бер традициясе булсын әле бу, – дип аңлата Айрат Фазыйхович.

Фатир сөенерлек. Планировкасы уңайлы, бүлмәләре иркен. Хуҗаларга барысы да ошый. 17 нче каттан тәрәзә аша карасаң – әкияти манзара! Әле бу кышын! Ә җәен, тирә-юнь яшеллеккә күмелгәч һәм якында гына ике ясалма сулык барлыкка килгәч, тагын да матуррак булачак. Яңа микрорайонда ял итеп йөрер өчен дә урын күп. Йорт янында тиздән уңайлы машина кую урыны да барлыкка киләчәк.

– Хисләр ташый, ниһаять, фатирлы булдык! Кемнең кайсы бүлмәдә яшәячәген инде планлаштырдык, урын барыбызга да җитә, – ди гаилә башлыгы.

ОЛЫЛАР СҮЗЕ

Гайнетдиновлар гаиләсе шулай ук ачкыч алырга тулы составта килгән, әбиләрен дә чакырырга онытмаганнар. Фатир ишеген ачар алдыннан өлкән буын вәкиле һәркайсына ипи телеме суза:

Гайнетдиновлар гаиләсе.

– Бу йортта һәрвакыт муллык, бәрәкәт булсын, ипотека түлибез, дип, ач тормасыннар, үзләреннән кысмасыннар, – дип елмая әби.

– Мин КМТТУ-КАИда бухгалтер булып эшлим – дип сөйли Диләрә Гайнетдинова. – Чиратка алты ел элек бастык. 29 декабрьдә – Яңа ел алдыннан фатирларны уйнаттылар. 30 нчы декабрь көнне иртән үз сәхифәмә кереп карасам, күченүчеләр исемлегенә эләккәнебезне күрдем. Яңа елга моннан да яхшырак бүләк булырга мөмкинме соң! Безнең фатирыбыз бар, ләкин ул кечкенә – 36 квадрат метрлы гына, ә гаиләдә ирем белән үземнән башка, ике бала да бар. Иркенрәк фатирга күченү, һәрберебезнең бүлмәле булуы турында күптән хыялландык. Яңа фатир мин күз алдына китергәнчә: җылы, якты, иркен һәм уңайлы. Без бик бәхетле, юкка гына шулкадәр озак көтмәгәнбез.

СҮЗ УҢАЕННАН
2018 елда Татарстанда соципотека программасы буенча 2 миллион 409 мең квадрат метр торак тапшырылды.

НЕФТЕХИМИКЛАР ШӘҺӘРЕНДӘ ЯҢА ФАТИРЛАР

Түбән Камада социаль ипотека программасында катнашучыларга фатир ачкычлары Яңа ел алдыннан – 28 декабрьдә тапшырыла. Бу көнне биредә 35А микрорайонында салынган 90 фатирлы яңа йортка күченә башлыйлар. Күченүләр арасында Шабалиннар гаиләсе дә бар.

– Ирем белән без Кострома өлкәсеннән, – дип сөйли Татьяна Александровна. – Татарстанга күченер алдыннан ике ел Мәскәү янында, Коломнада яшәдек. Хәзер мин Түбән Камадагы психоневрология диспансерында эшлим, ирем җайлы гына «Түбән Кама Нефтехим»да эш тапты. Дөресен генә әйткәндә, Татарстандагы социаль ипотека программасы күченүгә сәбәп булды да, бу турыда Интернеттан укып белдек. Үзебезнең фатирыбыз булуын шулкадәр теләдек, арендалап торудан туйган идек. Башта без Татарстанга җәен кайттык, шәһәрне карадык, кешеләр белән аралаштык, барысы да бик ошады. Монда тормыш дәрәҗәсе башкала янәшәсендәге шәһәрдәгегә караганда яхшырак та хәтта.

Ике балабыз бар. Улыбызга өч яшь ярым, кызыбызга 10 яшь, ул яңа мәктәпкә китте. Түбән Камада – шаккаттык! – кытай

Шабалиннар гаиләсе: яңа фатирда селфи.

теле курсларына кадәр бар икән, кызыбыз шунда йөри, тагын инглиз телен өйрәнә, бию белән шөгыльләнә, модельләр мәктәбендә укый, язын ат спорты секциясенә йөрергә җыенабыз. Монда дәресләр һәм түгәрәкләр ягыннан төрлелек зур, барысы да шәһәр кешеләре йөрерлек.

Таныш табибларым арасында без ачкычларны беренче алдык, ләкин быелгы Яңа елны үз фатирыбызда каршы алырга туры килмәде – эштә кизү торырга туры килде. Бу, әлбәттә, алай ук мөһим түгел. Безнең хәзер үз фатирыбыз бар, тулысынча эшләнеп бетерелгән булуы да әйбәт. Шушы көннәрдә күченергә җыенабыз.

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

ТАТАРСТАНДА ИҢ МАТУР ЧЫРШЫ КАЙДА?

Гыйнвар ае буена Татарстан шәһәрләре һәм районнарының төп чыршылары, бәйрәм утлары белән балкып, олыларның һәм кечкенәләрнең кәефен күтәреп торды. Һәр чыршы башкасыннан купшырак һәм матуррак күренде. «Татарстан» республикадагы иң матур чыршының кайда икәнлеген protatarstan.ru сайты буенча ачыклады – халык үз районының яшел гүзәлкәе өчен шунда тавыш биргән иде. Нәтиҗәләр буенча беренче урынга Чүпрәле районы чыкты. Икенче урында – Тукай районы чыршысы. Өченче урын – сарманлыларныкы.

protatarstan.ru

ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ



Фото: Гөлия Фәизова һәм Резедә Җамалетдинова. «Татмедиа» АҖ филиалы – «Туган як» газетасы редакциясе, Чүпрәле районы.

ӘН!
СНОВЬ

ТУКАЙ РАЙОНЫ

Фото ТР Тукай муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды.

САРМАН РАЙОНЫ



Фото «Сарман» газетасы редакциясеннән алынды.



ХЫЯЛДАГЫ КОМАНДА. ИРТӘГӘГӘ БИРЕМ

Кар баскан кыр, әчпошыргыч уен һәм буш трибуналар. Премьер-лигадагы күпчелек команда өчен футбол сезоны әнә шулайрак тәмамланды. Әмма «Рубин» өчен түгел. Аның Санкт-Петербургтагы декабрь уенында батырлыгы җанатарларына өмет нуры бүләк итте. Бу чыннан да үзен аклаячакмы? Командаларның ялдан соң яңа сезонга әзерләнә башлаган гыйнвар ае – моны аңларга тырышу өчен иң яхшы вакыт.

Автор:
Сафа Гәрәев

Моннан 1 ай элек булган вакыйганы искә төшерик. 2018 елның 9 декабре, Санкт-Петербург, Крестовский утравындагы стадион. Чемпионат лидеры «Зенит» Казанның «Рубин» командасын кабул итә. Бу көнне биредә стадионга «Газпром-Арена» исемен рәсми төстә бирүгә багышланган бәйрәм уздырыла, хуҗаларга чиктән тыш куәтле иганәчеләре каршында берничек тә хур булырга ярамый. Белгечләр питерлыларның җиңүенә шикләнми дә. «Рубинның» кирәкле сандагы уенчыларны көч-хәл белән туплаган чагы – төрле сәбәпләр буенча кырга төп составтагы җиде футболчы чыга алмый, казанлыларның төп һөҗүмчесе Сәрдар Азмун да матчта катнашмый. Хәтта «Рубинның» иң тугры җанатарлары да могҗиза буласына ышанмый: чөнки хуҗалар ягындагы бер Леандро Паредес кына да Казандагы бөтен футболчыдан кыйммәтрәк тора. Космик эш хакы алучы «Зенит» йолдызларына ничек каршы тормак кирәк?

Тик «Рубин» капитаны Сесар Навас кына матч алдыннан буар елан кебек тыныч:

– Аларның составы Премьер-лигада иң яхшысы, җиңел булмаячак, әмма без җиңәргә тырышачакбыз, – дип вәгъдә бирә ул журналистларга.

Киеренке матч башлана. Кадрлар кытлыгыннан Казан клубының өч яшь шәкерте хисабына котылалар. 18 яшьлек малайлар команда белән бергә сынауны лаеклы үтә – йөгерә, егыла, алга бара, соңгы көчләре беткәнче капканы саклый, көндәшләренең уен бетәр алдыннан туктаусыз бер-берсен алыштырган һөҗүмнәрен тыеп кала. Һәм – нәтиҗә! «Газпром-Аренаның» шаккаткан 50 меңлек аудиториясе күз алдында Казан командасы 2:1 исәбе белән сенсацион җиңүгә ирешә.

– Безнең шәкертләребезнең беренче уенда ук ил чемпионаты лидерын җиңүе өчен мин Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтлемен, – диячәк гадәттә хисләрен тыярга күнеккән Корбан Бердыев матчтан соңгы матбугат очрашуында. Казанлыларның баш тренеры соңрак болай шәрехләячәк: «Зенит»ка каршы уенга тәҗрибәсез яшьләрне чыгарырга килеп туган шартлар мәҗбүр иткән, әмма нәтиҗәдә ул «моңарчы беркайчан да тоймаганча тренерлык бәхетен татыган».

Яраткан командаларының дөнья шаулаткан җиңүләренә сусаган җанатарларның иң оптимистлары шундук «Рубинның» Европа кубокларында «Барселона» һәм «Интерны» буйсындырган чемпион чакларын искә төшерде. Ходаем, бездә кабат грандларны җиңәргә һәм Россия беренчелеге алтыны өчен көрәшергә сәләтле шундый команда туып ятамы әллә?

ТЫРЫШЫП ЯУЛАНГАН ҖИҢҮЛӘР СЕЗОНЫ

Чемпионатның декабрьдә «Рубин»ның лидерны героик җиңүе белән тәмамланган беренче яртысы команда өчен җиңел булмады. Әйе, беренче турда ук Казанда амбицияле «Краснодар» командасы җиңелде, әмма аннары җиңүләр сирәгәйде. Вакыт-вакыт команда аутсайдерлар зонасына якынлашты, бик озак вакыт буе кунакта җиңә алмады – нәтиҗәдә Санкт-Петербургтагы җиңү казанлыларның чит кырдагы бердәнбер уңышы буларак теркәлде. Дөрес, рубин төсендәгеләр 17 турның икесендә генә җиңелде, әмма җиңүләр дә нибары биш кенә шул. Хәтта быелгы чемпионатта артта өстерәлгән өметсез «Анжи», «Уфа», «Динамо» да казанлылардан очко тартып ала алды.

Уртача уйнаучылар һәм аутсайдерлар белән матчларда очко югалту 2018 елгы «Рубинның» чын мөмкинлекләрен күрсәтә дә инде. Команда уенчылар дәрәҗәсе буенча Премьер-лигадагы күпчелектән көчлерәк түгел, акылга сыймаслык контрактлы суперйолдызлар да юк хәзер биредә. Әйе, Сәрдар Азмун бар, аны казанлыларның остазы Корбан Бердыев премьер-лигадагы иң яхшы үзәк һөҗүмчеләрдән берсе дип саный. Сесар Навас бар, утыз тугыз яшьлек уенчы электәге кебек өлгер булмаса да, оборонада элеккечә үк (команданың моннан тугыз ел элеккеге алтын чорындагы кебек) акыллы һәм ышанычлы уйный...

Әмма «Рубинга» команда уенын лаеклы дәрәҗәгә күтәрү өчен ике-өч топ-уенчының тырышлыгы гына җитми. Бигрәк тә, бүген Казан клубы өчен уйнаучыларның күбесе әле бер ел элек кенә башка командаларда уйнаганны, анда да төп рольләрдә булмауны исәпкә алганда. Кем белсен, аларны команда механизмына уңышлы урнаштыру һәм әлеге механизмны бербөтен сыйфатында эшләтеп җибәрү өчен остазга никадәр вакыт кирәк булачак бит әле. Һәм гомумән, башкаручыларның бүгенге дәрәҗәсе теләккә ирешергә мөмкинлек бирерме икән соң?

Яраткан командалары чыгышы статистикасын анализлап һәм аның көзге чемпионаттагы әллә ни мавыктыргыч булмаган матчларын хәтерләрендә тотып, пессимист җанатарлар якынча менә шулай фикер йөртә. «Казан-Аренаның» бик сирәк очракта гына яртылаш тулган трибуналарына карап нәтиҗә ясасаң, мондый җанатарлар шактый булып чыга.

ЛИДЕРЛАР КЕМНӘН КУРКА?

Оптимистларның дәлилләре исә оппонентларыныкына караганда саллырактыр, мөгаен. Беренчедән, хәзер команда рулендә торган Корбан Бердыевның тренерлык таланты күптән һәм һичшиксез танылган. Остазның уртача уенчылар белән дә нәтиҗәгә ирешергә сәләтлелеге хакында сүзләрнең инде әллә ничә тапкыр расланганы бар, башка тренерлар өметен өзгән уенчылардан йолдыз ясый алуы да мәгълүм. Икенчедән, «Рубинның» оста

Фотолар «Рубин-Казан» футбол клубы рәсми сайтыннан алынды.

уенчыларга кытлыгыннан башланган бу сезонда ук командага яңа алынучылар һәм кичәге алмашчыларның Бердыев кул астында һөнәри яктан никадәр үсүе күренә – алар төп составта калу гына түгел, футбол белгечләренең үзләре турында ихтирам белән сөйләүгә ку̀чүенә дә иреште һәм Россия җыелмалары остазларының игътибарын җәлеп итте.

Санкт-Петербургта кирәге чыкмаган сакчы Егор Сорокин «Рубинда» инде үз кешегә әйләнде һәм берничә тапкыр туп та кертте. (Декабрьдә «Зенит» капкасына кертелгән җиңүле ике туп та аның эше). Башкаланың «Спартак» командасында файдасыз саналган ярымсакчы Игорь Коновалов «Рубинда» яхшы яктан ачылды, кайбер мәгълүматлар буенча, аның белән топ-клублар, шул исәптән үзен кирәксезгә чыгарган клуб та кызыксына икән. Ә капкачыларга килсәк, хәзер Премьер-лиганың бөтен клублары казанлыларга көнләшерлек. Тәҗрибәле Сослан Джанаев имгәнгәч, аны шундук Иван Коновалов алыштырды. Ул тотрыклы һәм ышанычлы уен күрсәтә. «Зенит» Казанга арендага биргән Егор Бабурин да куандыра. Санкт-Петербургта үзен күрсәтә алмаган Бабурин Бердыев биргән мөмкинлектән тулысынча файдаланды. Өч кубок уенында капкасына туп керттермәде, «Газпром-Арена» кырында иптәшләрен әллә ничә тапкыр коткарды, пенальтидан тибелгән тупны гына тотып өлгермәде.

Игътибар итегез, болар барысы да Казанда ачылган яшь уенчылар. Хәер, дипломат һәм педагог Бердыев үз шәкертләрен мактап очындырырга яратмый. Сорокинның алга китешен билгеләп үтеп, барыбер үз фикерен җиткерә: «Егетнең әзерлеге дулкынсыман бара: әйбәт уйнаганда – без аңа ышанабыз, бик үк барып чыкмаса – ышанып бетмибез...» – ди. Игорь Коновалов турында катгыйрак та әйтеп җибәрә, янәсе, аңа әле күп тырышырга кирәк, моның өчен исә үзеңне артык югары бәяләмәү мөһим...

Дөресен әйткәндә, команда күрсәткән нәтиҗәләр барысына бергә дә, һәркайсына аерым да мактау яудырырлык түгел бит. Соңгы турда җиңү казанлыларга чемпионаттагы тәнәфес вакытына турнир таблицасының алтынчы урынына эләгеп калырга булышты. Тупланган очколары саны буенча рубин төсендәгеләр

командаларның зур төркеменнән аз гына югарырак, нәтиҗәләрнең тыгызлыгы шундый ки, ике-өч тур эчендә бөтен нәрсә тамырдан үзгәрергә мөмкин. Команданың дәрәҗәсе? Бу сорауга да шул ук статистика җавап бирә ала: үзе җиңгән биш уенның берсендә дә «Рубин» бер туптан артыграк булган өстенлеккә ирешә алмады.

Турнирның икенче этабында «Рубиннан» нәрсә көтәргә? Фаразлауга күчкәнче, ике нәрсәгә тукталыйк. Яңартылган һәм яшәргән «Рубинның» турнирның көзге өлешендә күрсәткән уены камиллектән бик ерак әле. Икенче яктан караганда, идеалдан ерак булган бу состав белән дә премьер-лиганың әйдәп баручы клубларына каршы торып була икән. Чемпионлык ярышы башында торган ике клубны да җиңү – моңа иң шәп дәлил.

АЗМУННЫ ДА САТМАКЧЫЛАР?

«Рубиннан» зур акчалар китте, һәм Корбан Бердыев килде. Казанда Россия футболы өчен яңа исемнәр кабат тусын өчен, әлеге ике фактор җитәрлек булып чыкты». Күптән түгел рубин төсендәгеләргә һәм аларның остазына championat.com сайты хәбәрчесе шундый мактаулы бәя бирде. Әгәр медальләрне яңа исемнәр ачу өчен бирсәләр, казанлылар инде бүген үк тәбрикләүләр кабул итәр иде.

Кызганыч, футболда бүләкне башка нәрсә өчен бирәләр шул. Җиңәргә кирәк, һәм һәр матчта диярлек җиңү зарур. Әмма бер-ике сезон эчендә яшь һәм өметлеләрдән генә топ-команда ясау хәтта даһи тренерның да хәленнән килерлек бурыч түгел. Зур футболда ныгый гына башлаган яшьләрдән бөтен турнир барышында тигез тотрыклы уен көтү дөрес булмас.

Әгәр без сезон азагында «Рубинны» җиңүчеләр өчлегендә күрергә телибез икән, инде бүген үк команданы Бердыев футболы фәлсәфәсен кабул итәргә сәләтле оста уенчылар белән көчәйтү зарур. Казанлыларның трансфер базарында үзләренә кирәкле уенчыларны сатып алу мөмкинлеге булу-булмау исә икенче мәсьәлә.

Командадан җитәкчеләрнең бер дә җибәрәсе килмәгән берничә оста футболчының китүе, хезмәт хакын түләүдәге тоткарлыклар турында соңгы елларда матбугат чараларында әледән-әле күренгән хәбәрләр командадагы финанс хәленең бик шәп булмавына ишарәләсә дә, күптән түгел «БО» газетасына биргән интервьюсында Бердыев үзе моңа ачыклык кертте: «Без аз акчага риза булырлык ирекле уенчыларны гына чакыра алабыз...» – диде. Остаз аңлатуынча, вазгыять шул кадәр аяныч ки, «Рубин» теләсә кайсы уенчысын, хәтта Азмунны да сатарга әзер. Сатып алуга килгәндә исә – яшь һәм өметлеләрне, бер-ике елдан чынлап уйнап китәрлекләрне генә сайлап була, әгәр алар тәкъдим ителгән эш хакына ризалашса, әлбәттә.

Һәм Бердыев бер дә шаяртканга охшамый. Медаль яулауларына ышанган командалар Европа дәрәҗәсендәге йолдызлар белән ныгырга теләп трансфер базарында активлык күрсәткәндә, «Рубин» тыйнак кына үз сафларын артык кыйммәт тормаган уенчылар белән тулыландыра. Беренче уенчы – Владислав Пантелеев, Милли футбол лигасының «Спартак-2» клубы ярымсакчысы, ул тиз арада идеаль футболчы булып үсеп җитәргә охшаган. Шул ук вакытта клуб үзенең уенчылары белән дә сөйләшүләр алып бара һәм аларны азрак эш хакына ризалашырга өнди. Владимир Гранат моңа ризалашкан, ә менә Федор Кудряшов инде «Рубин» уенчысы түгел...

Аңлашыла ки, «Рубинның» яңа җитәкчелеге чыгымнарны һәрьяклап киметү курсын үз ихтыяры белән сайламаган. Элгәрләре җибәргән хаталар өчен интегергә туры килә – алар сый-



фатлы уен күрсәтмәгән футболчылар белән бик зур суммалы контрактлар төзеп ялгышкан. Ул чакта чыгымнар табыштан күпкә арткан һәм УЕФА санкцияләр кулланырга мәҗбүр булган – клубны ике сезон буе Европа кубокларында уйнаудан тыйган.

Хезмәт хакы түләүне һәм башка чыгымнарны шактый киметеп, «Рубин» якын арада Европа турнирларында катнашу хокукын кире кайтарыр кебек. Әмма бу сезонда яшь һәм өметле футболчылар командасы медаль өчен көрәшә алмастыр. Әлбәттә инде, Бердыев чираттагы берәр могҗиза тудырмаса…

> **«Рубиннан» зур акчалар китте, һәм Корбан Бердыев килде. Казанда Россия футболы өчен яңа исемнәр кабат тусын өчен, әлеге ике фактор җитәрлек булып чыкты».**

АКЧАСЫЗ, ӘММА ЯШЬЛӘРЧӘ ДӘРТ БЕЛӘН

Ә «өмет нуры» белән нишләргә соң? Парадокс, әмма Татарстан клубы тудырган вазгыять, чыннан да, киләчәккә оптимизм белән карарга мөмкинлек бирә. Рубин төсендәгеләрдән беренче тапкыр «биредә һәм хәзер» максималь нәтиҗә көтмиләр һәм тренерлык штабына өстән каты психологик басым юк. Перспективага эшләү, нәтиҗәләре өчен курыкмыйча талантлы яшьләрне җыю һәм хәрби шартларда тикшерү өчен идеаль атмосфера бу. Карьералары төгәлләнеп килгән чит ил гастролерларыннан түгел, бәлки яшь, талантлы россиялеләр, җирле уенчылардан хыялдагы куәтле команданы төзү өчен бер дигән мөмкинлек. Казан командасының «Газпром-Арена» кырындагы сенсацияле җиңүендә катнашучылар – «Рубин» академиясен тәмамлаучы 18 яшьлек Артур Сәгыйтов, Даниил Степанов, Раил Абдуллин – безнең «беренче карлыгачлар». Казанлыларның төп составында җирле өч шәкерт уйнаганны хәтерләүче дә юктыр инде…

Күзәтүебезне әлеге күтәренке нотада төгәлләргә дә мөмкин иде, әмма кырыс чынбарлык итәктән тарта. Чөнки тренер Бердыев кул астында һичшиксез камилләшәчәк талантлы яшьләрне үзебездә саклап калу – аларны тәрбияләү кебек үк катлаулы эш. Базар үз кагыйдәләрен һәм үз бәяләрен урнаштыра, кызганычка, алар еш кына баш тренерның абруе һәм ышандыруларыннан куәтлерәк булып чыга. «Зенитка» киткән Эльмир Нәбиуллин һәм карьерасын ЦСКАда уңышлы дәвам итүче Илзат Әхмәтов мисаллары күз алдында.

Һәм әгәр без чыннан да «Рубинның» Татарстанны Европа аренасында лаеклы күрсәтүен телибез икән, чыгымнарны киметү турында гына түгел, команданың уенчыларга реаль контрактлар тәкъдим итәрлек һәм югары класслы футболчылар сатып алырлык халәттә булуын да кайгырту кирәк. Боларның барысына да финанс «фэерплэй» шартларын бозмыйча да ирешергә мөмкин – логотиплары «Рубин» уенчылары футболкаларына төшерелгән иганәчеләрнең теләге һәм зиреклеге генә таләп ителә…

Тренер-максималист Корбан Бердыев үзен «Рубинга» чакырулары тикмәгә генә түгел, кыенлыкларны кичерергә һәм сыйфатлы ыргылыш ясарга әзер булырга кирәк, дип белдергән иде. Бердыев – стратег. Һәм ул барысын да алдан уйлаган, дип ышанасы килә. Әгәр шулай икән, димәк, киләчәктә Европа кубокларында «Барселона», «Реал» һәм «Ливерпульнең» тагын бер лаеклы көндәше пәйда булу ихтималы зур.

ТАТАРСТАНЧА КЫШКЫ КҮҢЕЛ АЧУЛАР

Чаңгы, тимераяк һәм чана – елның иң салкын фасылын кызу һәм күңелле итеп үткәрергә теләүчеләрнең башына килә торган беренче кышкы күңел ачу ысуллары әнә шулар инде. Чынлыкта кышкы мавыгулар болар белән генә чикләнми әле! «Татарстан» кышкы каникулларда республика буйлап шактый «шуып» йөрде һәм бу исемлеккә тагын әллә никадәр кызыклы, экстремаль, гадәти булмаган чараларны өстәде.

Алена Кутыркина, Александр Ефремов фотолары

ТҮБӘН КАМА ЯНЫ

КАЕНЛЫ АВЫЛЫ: АТЛАРДА ҖИЛДЕРҮ ЙОЛАСЫ

…Киенгән-ясанган бәйрәм итүчеләр төялгән атлар кыңгыраулар чыңы һәм атларны әйдәкләүченең «Тррр, малкай!» дигән тавышлары астында урамнар буйлап сыздырып үтте. Без моны Иске яңа елны каршылар алдыннан күрдек. Каенлы авылында әнә шундый традиция бар икән. Бәйрәм тантанасын тәгәрмәч эзенә генә сыйдырырлык түгел иде, шуңа да шау-гөр килгән халык төялгән атлар бистә кырыендагы көртләрне җиңел генә кичеп уздылар да басу түренә үк барып чыктылар.

Ат тояклары астыннан бурандай күтәрелгән кар авызларга, күзләргә тула. Ләкин бу һич кенә дә манзараның ямен бозмый: шәльяулык япкан кыз-кыркынның, бала-чаганың шат авазлары, яңа ел символы – алсу дуңгыз карачкысы, чаналар чыжлавы күңелдә гаҗәеп хисләр уята. Еракта калган елларның үзенчәлекле маҗарасы технологик 2019 елда – супер күңел ачу әнә шулай була ул!

Алена Кутыркина, Александр Ефремов фотолары

КАЗАН ЯНЫ

ЗӘҢГӘР КҮЛ. СУ КОЕНУ ҺӘМ ЧУМЛАУ ЙОЛАСЫ

Кышын да, җәен дә су температурасы +4 килеш торган данлыклы Зәңгәр күл. Җәй көне анда чумсаң – салкын, ә кыш көне шактый җылы. Һәрхәлдә безнең бүгенге геройларыбыз – балачактан дуслар һәм егерме ел стажлы (!) коенучылар Аида Латыйпова белән Павел Николаев шулай дип ышандыра.

– Коену – безнең өчен сәламәтлек тә, драйв та һәм тормыш рәвеше дә! – ди Аида. – Һәм тагын дусларның җылы компаниясе дә. Без ял саен бирелә коенабыз. Аннан башка яши алмыйбыз диярлек инде. Күл безне үзенә тарта, кызыктыра, чакыра.

«Татарстан» журналы хәбәрчесе Алёна Кутыркина да, шаккатырып сөйләүләрен тыңлап һәм коенучыларга кызыгып карап торганнан соң, түзмәде – Зәңгәр күлгә чумды һәм чын Су кызына әверелде. Әкияти күңел ачу булды бу!

Алёна Кутыркина, Александр Ефремов фотолары



НУРЛАТ ЯНЫ

СУ ТЕГЕРМӘНЕ. ҮТКӘННӘР БУЕНЧА ЭКСКУРСИЯ

Әлеге тегермән тарихи фильмнар төшерү өчен уңайлы урын – менә дигән «декорацияләр». Барысы да табигый һәм дөрес. Һәм бераз куркыныч, салкын хәтта. Ләкин экскурсовод килеп керүгә, барысы да «җанлана» һәм эшли башлый.

– Биләрдән Нурлатка кадәрле юл гомумән тарихи, – дип сөйли Нурлат шәһәре һәм Кама аръягы тарихының төбәк музее директоры Флюра Морзаханова. – Нурлатның бөтен тарихы шушы юл белән бәйле. Ә су тегермәне – аеруча, бу инде уникаль һәйкәл! Тик проблема шунда: әлеге һәйкәлне яңартырга кирәк, ә реставрацияләү өчен акча юк!

КНЯЗЬ ОБОЛЕНСКИЙ СӘЛАМЕ

Тегермәнгә инде йөз яшьтән артык, ул – инженер Аносов проекты. Аннары аны, әле революциягә кадәр үк, князь Оболенский сатып алган һәм төзеп бетергән.

– Шул ук Оболенскиймы инде ул?

– Безнең кайбер чыганакларда ул Сергей Александрович дип искә алына, ә икенчеләрендә – Алексей Оболенский. Сез гаҗәпләнмәгез, чөнки Сергей Александрович Оболенскийның бөтен Россия территориясе буенча утарлары булган. Нурлатта гына түгел, сезгә аның турында Чистай музеенда да сөйләгәннәре бардыр. Алар рентага яшәгән. Биш тегермәне, йөз баш ат асралган ат заводы булган. Сыерлары – 250 баш. Александровка бистәсендә үзенең шәраб сыгу заводы – соңыннан ул Төрнәс совхозы дип атала башлаган. Хәтта Пётр Столыпин үзе, бу юлдан узганда, алпавыт Шульц янына да, Оболенский янына да керә торган булган. Чулпан авылында хатыны Ольганың утары урнашкан. Бөек реформатор хатынына язган хатларында Оболенский турында бик җылы сүзләр әйткән: «Алексей – бик акыллы һәм тәрбияле кеше», «Мин Алёша янында булдым...» Алар бергәләп бу тегермән янына тимер юл сузарга уйлаганнар. Тегермән тирәсендә олаулар тезелеп торган, халык төрле яклардан ашлык алып килгән. Бу олаулар еш кына куна калганнар, чөнки онны тарттырып өлгермәгәннәр. Әтием сөйләвенә караганда, тегермән озак еллар халыкны туендыручы булып торган. Чана арты чана килә иде, дип сөйли иде ул. Чиратның ничек баруына карап... Әллә кайчан булган хәлләр, башка тормыштагы кебек, башка гасырда, тик мин моны бүгенгедәй күрәм...

ШВЕЙЦАРИЯ ТЕХНИКАСЫНЫҢ СОҢГЫ СҮЗЕ БУЕНЧА

...Менә карагыз: тегермән тирәсендә үскән бу имәннәргә йөз яшьтән артык, алар тегермәннең яшьтәшләре. Ә тегермән

Фото: Александр Ефремов

үзе 1964 елга кадәр эшләгән. Халык аны Оболенский тегермәне дип йөрткән. Аннары ул Татмелтрестның 35 нче тегермәне дип йөртелә башлаган. Карагыз мондагы җиһазларга – Швейцариянеке! Шул заманнардан бүгенге көнгә кадәр билгеле «Братья Бюлер» тегермән заводы монда үз җиһазларын урнаштырган. Аларны Уцвиль шәһәреннән китергәннәр. Күрәсезме аларның табличкасын? Барысы да исән.

Проект буенча бу тегермән кирпечтән түгел, агачтан салынган. Биш катның өчесен генә төзегәннәр дә мансарда өстәгәннәр. Күрәсезме, хәтта он тарттыру күзлекләренә кадәр сакланган. Тегермән үзе имән баганаларда тора. Су Зур Чирмешән елгасыннан килгән, һәм барысы да сәгать кебек эшләп торган. Монда бөтен нәрсә шул чордагы Швейцария техникасының соңгы сүзе буенча җиһазландырылган.

– Ничек бу байлыкны бүгенге көнгәчә ташып бетермәгәннәр?

– Авыл кешеләре саклый. Моның өчен аларга хезмәт хакы түлиләр. Янәшәдә Единение авылы. Карагыз, менә моннан чип-чиста он агып чыккан, – дип, Флюра Җамаловна кабат он тарттыру темасына кайта. – Ул көрпәгә һәм беренче-икенче сортларга аерылган. Моны бүтән беркайда да күрә алмассыз! Беренче катта капчыкларны әзерләп куеп торганнар. Аларның авызларын теккәч, шунда ук коридорга – урамга чыгарганнар. Бөтен корылмалар әлегәчә егәрле, нык. Гасырларга җитәрлек итеп төзелгән.

ТУРИСТЛАРНЫҢ МОНЫ КҮРГӘНЕ ЮК

– Туристлар киләме?

– Юк, монда куркынычсызлык кагыйдәләре сакланмый, бу беренчедән. Кайчаннан бирле тегермән ташландык хәлдә. Һәм ул туристлар өчен эстетик яктан да әзер түгел.

– Шулай булгач, «Татарстан»нан башка, сез моны тагын кемгә күрсәтәсез инде?

– Беркемгә дә күрсәтмибез. Әмма районыбызның яңа башлыгы креатив кеше, минемчә, ул тегермәнне игътибарыннан читтә калдырмас. Иң мөһиме, монда барысы да табигый, натураль. Бәлки, бу тегермән бирегә юл булмаганга күрә, шул беренчел халәтендә сакланып калгандыр да. Аны Республика әһәмиятендәге һәйкәл дип игълан итүен иттеләр, ә реставрация планына кадәр саклау өчен дә берниндәи ярдәм юк. Бер кеше генә берни дә эшли алмый бит. Ә бит ул иң куәтле тегермән булган! Туктаусыз эшләп торган. Оболенский онының оныгы бирегә 2014 елда килде. Тегермән буйлап йөрде дә китте, дип сөйлиләр. Англиядә яши икән.

– Ә үзегез бу тема белән кайчан кызыксына башладыгыз?

– Бу тегермәнгә җитди игътибар музейдан башланды. Без туристик маршрутлар буйлап йөрдек, районда туризмны үстердек, грантларга гаризалар бирдек... Әмма бик кыйммәтле проект булып чыга. Шуңа күрә безнең тегермәннән әлегә баш тарталар.

ОНЫТЫЛГАН ГЕРОЙ ҖИРЕНДӘ

– Реставрациядән соң тегермәннең беренчел рәвеше югалмасмы соң? Хәзер әле монда тарихи кино төшерсәң дә була – мондагы манзара шундый чын һәм уникаль...

– Юк, әлбәттә. Объект тегермән буларак та, музей буларак та сакланачак. Мин монда мини-пекарня да ясар идем, икмәк исе дә таралып торсын өчен. Кешеләргә су тегермәненең ничек эшләгәнен күрсәтер өчен, механизмны да хәрәкәткә китерсәң иде ул! Монда, гомумән алганда, нибары биш-алты кеше генә эшләгән, шул дәрәҗәдә акыл белән механикалаштырылган булган барысы да.

– Тегермәнне азмы-күпме үз хәленә кайтарыр өчен күпме акча кирәк соң?

– Мөгаен, 40 миллион чамасыдыр. Мәдәният министрлыгында безне хупладылар, әлбәттә, бу тегермән турында барысы да белә. Әлмәттә дә, Казанда да, Мәскәүдә дә беләләр. Мондый уникаль объект өчен ул кадәр үк зур акчалар да түгел югыйсә. Без Швейцария фирмасына ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәч, «Братья Бюлер» заводының Мәскәүдәге вәкилләре тегермәнне җире белән бергә сатып алырга теләгәннәр иде, ләкин мин бирмәдем. Үз сүземдә торып, саклап калдым.

Гомумән, бу якларда барысы да тарих белән сугарылган. Единение авылы революциядән соң гына барлыкка килгән, ә аңа кадәр әнә тегендә – урман артында – Герой Авылы (Деревня Героя) булган. Анда 1812 ел сугышы герое яшәгәнгә күрә, аның хөрмәтенә шулай дип атаганнар.

БРАТЬЯ БЮЛЕРЪ
ЗАВОДЪ ДЛЯ УСТРОЙСТВА МЕЛЬНИЦЪ
31457
УЦВИЛЬ ШВЕЙЦАРІЯ

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Кутуйның **НИНДИ** хыялы тормышка ашмый кала

Татар аудиокитапларын **КАЙДАН** табарга

Нурсолтан турында **НИЛӘР** беләбез

Тиңе булмаган мәдәният үзәге **КАЙДА** урнашкан

2019 елда Татарстанны **НИЛӘР** көтә

КЫРЫС ЧОРНЫҢ КӨЛӘЧ КЕШЕСЕ

Без аның «Рөстәм маҗаралары»ндагы Рөстәменә кызыгып, урманны аркылыга-буйга иңләп, абага чәчәге эзли идек. Галияне яклап, Искәндәргә нәфрәтләнә... Балачакта татар әдәбияты кабинетында эленеп торган язучы портретлары арасында иң күзне ямьләгәне, ирен читләрендә күз төшерү белән елмаю уята торганы – аныкы. Һич онытасым юк: дәресләр беткәч, җыештыручы апалар да, швабраларына иякләрен терәп, аның дөньяны яктыртырдай көләч елмаюына сихерләнеп тора иделәр. Торалар-торалар да: «Бигрәк чибәр, сөйкемле кеше булган инде...», – диеп, кабат эшләренә тотыналар...

Тормышта да көләч, якты, ихлас, кешелекле, намуслы зат буларак теркәп калдырган аны истәлекләрендә замандашлары. Сүзебез Гадел Кутуй турында. Сезне аның тормыш сәхифәләре буйлап сәяхәткә чакырам.

«АҢА ТАТАР ДӨНЬЯСЫ ҖИТМИ ИДЕ...»

«1917 елда Самарадан 7 чакрымдагы поселокка – Кряжга күчтек. Гадел белән мин Куйбышевтагы 1 нче мәктәпкә кереп укый башладык. Гадел бик яхшы укыды. Тыйнак булса да, кешеләр белән тиз аралашып китә иде. Ишек алдындагы карчыклар бик ярата иде үзен. Бик ярдәмчел, җитез малай иде. Сугышканын, бәхәсләшкәнен, тәртип бозганын хәтерләмим. Мәктәптә укыган чагында 14 яшендә беренче шигырен язды. Шигырь, әлбәттә, русча язылган иде. Без бит класста татарлардан икәү генә. Үзара да русча сөйләшә идек. Татарча сөйләшсәң, үртиләр чөнки.

Гадел сүз тыңлаучан бала булды. Кушкан эшне тиз генә эшли дә үзенә буш вакыт калдыра иде. Буш вакытында клубка, театрга бара. Әдәбият түгәрәгенә йөри башлады. Шулай да канәгать түгел иде ул. Аңа татар дөньясы җитми иде.

Уналты яшендә Куйбышевтагы университетка укырга керде... Казанга ашкынды. Әнинең ризалыгын алып, минем белән киңәште дә, әтигә әйтмичә генә, Казанга китеп барды. Юкса әти җибәрмәс иде...»

Апасы Зәйнүл Кутуева истәлекләреннән.

– Кутуй татар поэзиясендә үзен беренче футурист шагыйрь дип игълан иткән кеше. Кайнар заман. Ул шул чактагы әдәби хәрәкәтнең үзәгендә тора; трибунада ул, матбугатта ул – яза, бәхәсләшә, якалаша!.. Яшь, чибәр, гаять дәртле, энергияле, үзе бик оста оратор, тавышы көр, шигырьләрен ялкынлы пафос белән сөйли; күп укыган, бик күпне белә, русчасы шәп, татарчасы да әйбәт. Кыскасы ул өстен, күп өстен иде бездән ул чагында...

Язучы Әмирхан Еники.

Әзерләде:
Луиза Янсуар

Фотолар Гадел Кутуйның «Илһам» җыентыгыннан, ТР Дәүләт архивы, ТР Милли китапханәсе рәсми сайтларыннан алынды.

Гадел Кутуй гаиләсе белән. 1938 ел.

ҖИҢНӘН БАШЛАНГАН МӘХӘББӘТ

«Берсендә Гомәр Гали әйтә:

Нигә бу чибәр кыз да безнең белән бармый? – ди.

Шулай итеп мин алар компаниясенә керәм. Гадел бик чибәр, яшь, бик оста сөйли, мин гашыйк булып йөри идем. Ләкин безнең мәхәббәт тиз генә кушылып китмәде. Алар Такташ белән икесе бер кичне өйләнделәр: Такташ – Гөлчәһрәгә (Гөлчәһрә Хәмзина), Гадел – аның Газзә (Газзә Бадамшина) исемле дус кызына. Такташның «Алсу» поэмасындагы Газзә инде ул. Озак тормадылар. Газзә Мәскәүгә Гөлчәһрә янына китеп барды…

Безгә еш килеп йөри башлады Гадел. Мин сабыр гына, оялчан гына кыз идем. Бик тиз кызара идем… Бер көнне киногa чакырды. «Унион» га (хәзерге «Родина» кинотеатры) бардык. Килсәк, сеанс башланырга бер сәгатьтән артыграк вакыт бар.

– Менә яхшы булды, сөйләшәсе сүзләр дә бар. Синең егетең бармы? – ди Кутуй.

...Аннары сөйләшеп йөрдек. Кинодан миңа кайттык. Чәй эчтек. Гадел ул чакта тун киеп йөри иде. Тунының җиңе ертылган. Мин аны тегеп бирдем. Гадел көлде:

– Гадәттә, мәхәббәт сәдәфтән башлана, безнеке җиңнән башланды, – ди.

1926 елның 26 декабрендә өйләнештек. Өйләнешү бик гади булды. Гадел ике кәрзинен күтәреп миңа килде. Кәрзиннәрендә китаплар, солдатлар кия торган ише белье иде.

Мин укыйм, Гаделдән алдарак кайтам. Кечкенә мичемне ягып җибәрәм, бәрәңге әрчеп турыйм да, бер озынча чирәп савытым бар иде, шуның бер ягына суган белән бәрәңге, икенче ягына котлетлар ясап куям. Бераздан Гадел кайта, аның артыннан ук диярлек Такташ килеп керә.

– Сез, дуслар, уйламагыз, ник бу безгә көн дә килә, дип. Сезнең бергә тормыш уңар микән дип карап йөрим, – диде ул берсендә.

Үзенең Гөлчәһрә белән тормышы әйбәт түгел иде.

– Тормышыгыз булыр шикелле, Галимә өй эшен ярата кебек, – диде.

Гадел белән Такташ бик дуслар иде. Яшь булсалар да, бервакыт Такташ әйтә: «Мин алдан үлсәм, син минем каберемә беренче уч туфракны салырсың, син үлсәң, мин салырмын. Шулай килештеләр».

Хатыны Галимә Кутуева истәлекләреннән.

– Гаделне кызлар бик ярата иде. Зәйнәп Бәширова сәгать урынына аның фоторәсемен кулына бәйләп йөрде. «Сәгать ничә?» – дип сорасалар, «Хәзер Кутуйдан сорыйм, ул ни әйтер», – дия иде.

Апасы Зәйнүл Кутуева.

«БЕЗ КИЛГӘННЕ КЕШЕ КҮРМӘСЕН...»

«1931 елның февралендә Гаделне «җидегәнчелек»тә* гаепләп кулга алдылар. Тугыз ай тоттылар. Аклап чыгардылар, бер гаеп тә тапмадылар. Ләкин җәмәгатьчелек арасында аларга мөнәсәбәт яхшырмады. Бер җиргә дә эшкә алмыйлар, беркем исәнләшми, сөйләшми, кайсы күрмәмешкә салына, кайсы, күзгә-күз очрашса да, дәшми үтә. Гадел кайта да башын ике кулы арасына салып утыра. Ул чагында дуслар ташлады, туганнар да бик сирәк киләләр. Килсәләр дә:

– Ишекне бикләгез, без килгәнне кем дә күрмәсен, – диләр.

Гадел көн буе йөреп эш эзләп кайта да башын тотып утыра, сөйләшми. Мин дә аңа сүз дәшәргә куркам. Беркөнне бик шатланып кайтты. Үзе белән бергә РТЯ** да укыган укытучы эшкә чакырган… Укыту эшен бик яратты Гадел…

Бервакыт ул өйдә юк чакта бишалты кыз килеп керде. «Адельша Нурмухаметович дома?» – дип сорыйлар, ә үзләре, юри аның өйдә юк чагын туры китереп, мине карарга дип килгәннәр… Гадел – бик чибәр, бик яхшы сөйли, шәп оратор иде бит ул. Күп шигырьләрне яттан белә. Кызларны тәмам авызына караткан… Аның ярты гомере театрда, артистлар арасында үтте. Театрда бик яраталар иде үзен…

Бераздан Гаделнең әсәрләрен баса башладылар. Сугыш алдыннан биш-алты ел бик әйбәт, рәхәтләнеп торып калдык. Тормыш мул түгел иде. Гаделнең кышкы пальтосы булганын хәтерләмим, һәрвакыт туңып йөрде. Чөнки балалар үсә, өч бала бит, укый башладылар. Әле дә хәтеремдә: базардан салам көлтәләре алып кайттым да, шуларны киндергә төреп матрас ясадым. Гадел сугышка киткәндә дә әле безнең караватта теге салам матрас иде».

Хатыны Галимә Кутуева истәлекләреннән.

* 1930 елда татар әдәбияты вәкилләренә карата контрреволюцион, милләтчел берләшмә төзүдә гаепләүгә корылган сәяси эш. Исеме – җидедән, ягъни ул җиде язучыны берләштерә дип фаразлана.
** РТЯ - Татар телен гамәлгә кую институты (Институт реализации татарского языка).



Ялкынлы иҗат дәвере. 1925 ел.

ҮЛМӘСКӘ ТИЕШЛЕ ДУСЛЫК ХАКЫНА...

«Такташ белән Кутуй бик дуслар иде. Җан дуслар дип әйтәсем килә, чөнки алар – аерылгысыз, кая гына барма, алар гел бергә!.. Җыелышларда, кичәләрдә, театрда җиңел сөякле Кутуй белән салмаграк хәрәкәтле Такташ, энә белән җеп шикелле, гел бер-берсенә тагылып йөриләр. Ә бит болай чынлабрак караганда, бер-берсеннән шактый нык аерылалар иде. Табигатьләре дә бер түгел, иҗатларында да охшашлык юк. Такташ басынкырак, сабыррак, кешеләр белән мөгамәләдә йомшаграк булса, Кутуй, киресенчә, дәртлерәк, кайнаррак, кискенрәк кеше иде...

Менә Такташ үлде... Табут алып чыгар алдыннан Такташ белән бәхилләшергә Кутуй килде.

– Иптәшләр, рөхсәт итегез әле миңа да бер сүз әйтергә!

Барысы да көтелмәгән тавышка борылып карады, кайберәүләр бер мәлгә ни әйтергә белмичә уңайсызланып калды. Комиссия членнарының берсе – Закир Гали:

Ку-туй! – дип куйды, аннары кинәт кызып: – Каян килеп кердең әле син, кем чакырды?! Такташка синең берниндидә мөнәсәбәтең юк, хәзер үк чыгып кит! – диде.

Кутуй тагын нидер әйтергә омтылып карады, ләкин аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Бу юлы инде берничә кеше, кайсы ачуланып, кайсы үгетләгәндәй итеп, аңа чыгып китәргә куштылар. Шагыйрьнең гәүдәсен Мәдәният йортыннан алып чыккач, Кутуй юл буе диярлек күтәрешеп барырга күпме генә омтылып караса да, аны табутка якын җибәрмәделәр. Зиратка барып җиткәннән соң, кабергә туфрак ташларга хәтта көрәк тә бирмичә азапладылар үзен. Кыскасы, үлгән Такташны тере Кутуйдан әнә шулай «сакларга» тырыштылар.

Кутуй, кусалар да, Такташ табуты артыннан бер адым да калмыйча ияреп бара, шагыйрьнең гәүдәсен җиргә иңдергән чакта, кысыла-кысыла булса да кабер якасында басып тора – күпме чыдамлык һәм «әрсезлек» кирәк булгандыр аңа?! Үлмәскә тиешле дуслык хакына. Такташны озатырга килгән халык зур югалту кичергәнен аңлый иде, әмма ләкин бу минутта иң бәхетсез кеше Кутуй булгандыр, мөгаен...»

Язучы Әмирхан Еники истәлекләреннән.

«ИРЛӘРЧӘ НЫК БУЛ!»

«Кутуй театрны, аның артистларын, режиссерларын, композиторларын ярата, аларга хөрмәт белән карый, иҗатлары белән кызыксынып тора иде. Бер бик әйбәт сыйфаты бар – ул объектив була белә. Эшләрең ошаганда югары бәя биреп күңелне канатландырса, ошамаганда, җитешмәгән яклары булса, шактый каты итеп әйтә дә белә иде.

Иҗат эшенең югарылыгын һәм матурлыгын күрергә яратты. Бүген ирешкән белән генә тынычланырга теләми, киләчәкне тизрәк җиткерәсе, дөресрәге, үсешне тизләтәсе килә иде аның. Ул үзенең яшәешендәге идеалга омтыла иде. Кешенең эше дә, уйлары да, мәхәббәте дә матур булырга тиеш, дип ышанып яшәде ул. Мин аның бер генә тапкыр да исерек вакытын күрмәдем. Аңа кәеф күтәрер өчен эчәргә кирәк түгел, аның кәефе һәрвакыт диярлек күтәренке иде.

Бик кешелекле кеше иде Кутуй. Уртак танышыбыз булган бер ханым сөйләде: 1939 елның салкын, пычрак көзендә Ирек мәйданы туктальшында бер баласын күтәреп, икенчесен җитәкләп трамвай көтеп дер-дер калтырап торганда, Кутуй килеп чыккан. Ул инде бу ханымның авыр хәлдә калуын, иренең фаҗигале рәвештә юкка чыкканлыгын ишеткән булган. «Хәлең турында ишеттем. Түземле була күр. Ирләрчә нык бул», – дип, ике баланы ике кулына күтәреп, Куйбышев мәйданына кадәр төшереп, квартирына ук илтеп куйган. Балаларга конфет биреп китеп барган...»

Режиссер Ширъяздан Сарымсаков истәлекләреннән.

«НИНДИ ЧӘЙ ДИ УЛ!..»

«1934 ел. Җәйнең бик ямьле, кояшлы көннәренең берсе. Татар дәүләт академия театры бинасыннан чыктым да уйлана-уйлана барам. Берәү кычкыра:

– Риза, тукта әле!

Кызу-кызу атлап каршыма Кутуй килә.

– Синең янга бара идем әле, – ди бу, серле генә елмаеп. – Ярый үзең очрадың.

Аерылмас җан дуслар. Һади Такташ белән Гадел Кутуй. 1929 ел.

«Тапшырылмаган хатлар»ның рус теленә тәрҗемә басмасы. Әсәрне Советлар Союзында яшәүче халыкларның тагын башка бик күп телләренә тәрҗемә итеп бастыралар. Ул бик популяр була.

«МИН ДӘ БАРМАСАМ, БҮТӘН ДӘ БАРМАСА...»

«Мин аны солдат итеп күз алдыма да китерә алмый идем.

– Китмә, – дим.

– Мин дә бармасам, бүтән дә бармаса, кем сугышны бетерер? – ди. Кутуй кешенең киңәшен тыңлап тора, әмма үзенчә эшли иде.

Соңгы тапкыр сугыштан кайтканда Кутуй элеккеге Кутуй түгел иде инде. Рухсыз иде. Әллә үзенең язмышын алдан сизенгәнгәме, ул бик үзгәреп кайткан иде. «Җидегәнчелек» вакытында да мин аның алай күңелсез булганын хәтерләмим».

Актриса Фатыйма Ильская истәлекләреннән.

– Нәрсә әллә безгә – академия театрына атап берәр пьеса яздыңмы?

– Язуын бер нәрсә яздым да. Тик пьеса түгел... Озын хикәя, повесть... Синең фикереңне ишетү кызыклы... Кульъязмамны укырга авырсынсаң, үзем үк укып чыгам. Вакытың булса, бүген үк, хәзер үк... Әле яңа гына тәмамлап, нокта куеп чыктым. Димәк, иң кайнар килеш сиңа укыйм. Беренче булып син хөкем чыгарасың... Өй аулак, Галимә дә, балалар да юк...

Унбиш-егерме минут узмагандыр, мин инде Кутуйның Комлев урамындагы фатирының кечкенә бүлмәсендә, искерәк бер креслога утырып, «Тапшырылмаган хатлар» повестен тыңлый идем.

Ул зур осталык белән, мавыктыргыч итеп язылган иде. Кутуй аны үзе дә бик оста итеп, дулкынланып, һәр җөмләсенең, сүзенең асыл мәгънәләрен җиткерерлек итеп укый. Икенче хатны укып чыккач, миңа карап:

– Яртысы тәмам, әле тагын ике хат укыйсы бар, әллә примуста чәй кайнатып, чәй эчеп алабызмы?

– Юк, юк, – мин әйтәм, – нинди чәй ди ул! Бөтен тәэссоратны бозып! Әйдә, укы! Ахырына кадәр, туктамыйча...

Бу әсәрне хәзер уннарча телдә яратып, дулкынланып укыйлар...»

Язучы Риза Ишморат истәлекләреннән.

Гадел Кутуйның фронтта чагы. 1943 ел.

«Без – сталинградчылар!» әсәренең рус телендәге тәрҗемә басмасы. Кутуй Сталинград сугышлары вакытында бик каты өшеп калган була. Атакага күтәрелергә сигналны көтеп, карга күмелеп кайвакыт сәгатьләр буе ята солдатлар. Соңрак тиешенчә дәвалап җиткерелмәгән авыруы яңадан калкып чыга...

«КҮЗЛӘРЕМӘ КАЗАН КҮРЕНӘ...»

«Сугыш вакыты. Бу елларда татар телендә чыга торган бердәнбер өлкә газетасы «Кызыл Татарстан». Фронттан яраланып яки ялга кайткан язучы һәм журналистлар иң элек безгә киләләр.

Менә беркөнне өске каттан:

– Кутуй кайткан, Кутуй килде, – дигән сүзләрне ишетәбез.

– Кутуй?!

Йөгерә-йөгерә баскычтан менәбез. Әле берничә генә көн элек Мәскәү радиосыннан аның тавышын ишеткән идек бит. Ялкынлы чыгышында ул кырыклап фашистны үз куллары белән дөмектерүе турында сөйләгән иде. Менә хәзер үзен дә күрәбез икән...

Салкын һәм ярым караңгы коридорга таба борылугa, бер төркем иптәшләрне күреп алабыз. Алар стена буена чүгәләп утырган Кутуй тирәсенә җыелганнар. Башында – колакчынлы бүрек, өстендә – кыска тун. Тунын чишеп җибәргән, гимнастеркасында орден-медальләре күренеп тора. Үзе ябык, авыру. Әмма күзләре, иреннәре елмая.

Без аны бүлмәгә чакырабыз. Ул кычкырып шигырь укып җибәрә:

Хыял күзе белән илгә карыйм,
Карап туймыйм – рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә...»

Журналист Мәрьям Дибаева истәлекләреннән.

«БЕРЛИНГА БАРЫБЕР ҖИТӘЧӘКМЕН!..»

«Гадел Кутуй Варшава һәм Одер өчен барган сугышларда солдатлар белән берләттән катнашты, автоматын кулына алып, танкларга утырып, сугыш эченә керде. Колак төбеннән сызгырып үткән пуляларның, җирнең астын-өскә актарган бомбаларның ярчыклары үзенә тимәвенә гаҗәпсенеп, киләчәктә дә сау калачагына ышаныч белән сөйли иде ул.

Җиңү язы килде. Познань шәһәрендә идек. Берлин операциясе өчен зур хәзерлек бара. Кутуйга, сәламәтлеге начар булганлыктан, врачлар барырга рөхсәт итмәде. «Кайдан күрендем шул врачларга? Мин Берлинга барыбер барып җитәрмен!» – дигән сүзләре колак төбемдә яңгырап тора...

Апрель урталарында госпитальгә керде. Мин килгәндә караватында мендәргә сөялеп утыра иде. Кәефе күтәрелеп китте, елмаеп җибәрде. Кулларымнан тоткан килеш, шатланып, нәрсәләр генә сорашмады! Берлинга барырга ашыгуын әйтте, врачлар рөхсәт бирми, дип зарланды. Бакчага чыктык, эскәмиягә утырдык. Көн аяз, җылы. Күктән төрле якка самолетлар үтеп тора...

Көн кичкә авышкач, урыннан тордык, ләкин Гадел бүлмәгә берүзе керә алмады. Ике кулын минем иң башларыма салды да, караватына кадәр күтәреп алып бардым. Тагын мендәренә сөялеп утырды; тагын кочаклаштык... Таш баскычка басу белән нинидер көч мине туктатты һәм шул чакны Тукайның больницада төшкән рәсеме күз алдыма килеп басты. Нинидер сизенү белән Гадел янына борылып кердем дә:«...Без Берлинда очрашырбыз, әүвәлгедәй кайнар чәйләр эчәрбез, без сине сагынабыз, көтәбез... Сине халкың, туган илең көтә...» – дидем.

Гадел 27 апрельдә автоматын ала (ул аны газета исеменнән командировкаларга чыкканда да калдырмый иде) да үтеп баручы бер машинага утырып Берлинга юл тота. Юлда барышлый хәлдән тая, врачлар аны янә госпитальгә озата...

Тиздән Берлин өстендә җиңү байрагы җилфердәде. Без Гариф Галиев, Ибраһим Гази, Шәрәф Мөдәррис белән бергә Рейхстагның җимерек стеналарын тамаша кылып йөргәндә, ташларга язылган меңләгән исем арасында «Кутуй» дигән исемне дә укыдык. Кем язганы билгесез иде. Әмма кем генә булмасын, ул «Без – сталинградчылар», «Сагыну», «Тапшырылмаган хатлар» белән рухланып, Берлингача килеп җиткән совет солдаты иде».

Әдәбият галиме Шакир Абилов истәлекләреннән.

«МИНЕ ГАДЕЛ ДИП АТАГЫЗ…»

«Аның белән беренче тапкыр 1945 елның 14 гыйнварына каршы төндә, Висла елгасының аргы ягындагы плацдармда очраштым.

– Кутуй, Беренче Белоруссия фронты газетасы хезмәткәре, – дип, кул биреп күреште. Аннары, кинәт, күңелләләнеп китеп, малайларча шуклык белән, кулын бүрегенә тидереп, честь бирде.

– Кутуй, дип, яисә исемем белән Гадел дип кенә атагыз, – диде ул, яныма утырып. Үзе йөзен балкытып дустанә елмая, чак кына кысылган күзләрендә кешегә ышаныч һәм кызыксыну чагыла иде. Аягындагы киез итеге, окоп тузаны кунган сырган чалбары, бил каешына таккан трофей маузер, иңенә аскан иске кыр сумкасы – барысы да аның сугыш ачысы-төчесен инде җитәрлек татыган фронтовик икәнлегеен әйтеп тора иде.

…1945 елның марты. Ландсберг шәһәреннән көнбатыштарак урнашкан бер авылдагы өйдә Гадел бик мавыгып офицерлар белән әдәбият, сәнгать турында сөйләшә. Шунда кайсыдыр үз иҗаты турында сөйләвен үтенде. Әмма Гадел язган түгел, ә язачак әсәрләре турында әйтте:

– Сугыштан соң, – диде ул, – «Тапшырылмаган хатлар»ның икенче китабын язарга, «Рөстәм маҗаралары»н тәмамларга уйлыйм. Аннары Бөек Ватан сугышы турында бер повесть язмакчы булам. Аның өчен материал җитәрлек…

Кәефе китебрәк тора иде, температурасы күтәрелеп. Бу аерылушыбыз соңгы аерылу булыр дип башыма да китермәдем…»

«Красная звезда» газетасы хәбәрчесе М.Новигатский.

– Ул шәхес буларак бик күркәм кеше иде. Юк-бар нәрсәгә тавыш куптаруны, вакланыны, кешене хаксызга кимсетүне һич кенә дә күтәрә алмый. Кутуйның кешеләрне яратуына, аларны эчке бер җылылыгы белән әсир итә алуына таң калырлык. Кая гына бармасын, кем белән генә сөйләшмәсен, һәркайчан үз эзен калдыра иде.

Фронтовик дусты, язучы Гариф Галиев.

«КУТУЙ ҮЛДЕ…»

«Познаньда бик әйбәт госпиталь бар иде. Комиссары үзебезнең Казан кешесе, медперсоналдан да татарлар бар. Кутуйны шушы иптәшләр кулына калдырып, редакция алгарак китте. Кире Познаньга барганда Кутуй янына кердем. Ул инде госпитальдән чыккан, өйдә. Бик беткән. Тукайның үләр алдыннан Клячкин шифаханәсендә төшкән соңгы рәсеменә охшап калган. Юка одеал астында беләк буе гына булып ята. Хуҗа хатыны алдына йомыркалар, пирожкилар куйган. Ләкин бу берсен дә ашамый икән.

Икенче көнне госпитальгә озатканнар. Кайсы госпитальгә? Белүче юк. Сораша торгач, әллә ни ерак түгел бер немец шәһәрендә ятуын белеп алдык. Гариф белән (Гариф Галиев) икәү юлга чыктык, госпитальне барып таптык. Анда аны «дәвалану өчен тылга озатылган» диделәр.

– Нинди стадия?

– Ачык процесс.

Андый авыру белән кешеләр гомер буе яши. Кутуй терелмәс дигән уйны башка да китермәдек. Берлинда көтмәгәндә аңардан открытка алдык. Юлдан җибәргән. «Поезд мине тылга алып китеп бара, ләкин мин әле кире борылып кайтырмын, Берлинны алуда катнашырмын», – дип яза. Күптән язган, открытка кайдадыр адашып йөргән. Кутуйның үз кулы белән язган бу открыткасына куандык: димәк, кайтып, инде Казанны «алганда» очрашырбыз.

Кинәт хат: «Кутуй госпитальдә үлде…» Гариф Галиев, тиз генә җыенып, ул вафат булган госпитальне эзли китте. Польша җирендә, Лодзь шәһәрендә булып чыкты (Гадел Кутуй чынлыкта Згеж шәһәрендәге госпитальдә вафат була. – **Авт.**). Госпитальдәге татар кызлары: «Кутуй абый безнең кулда үлде», – дигәннәр.

Ул гел алда булырга тырышты һәм гел алда булды да…»

Язучы Ибраһим Гази истәлекләреннән.

ТР Дәүләт архивы, Милли китапханәсе фондларында сакланган материалларга, «Илһам» җыентыгы, «Гадел Кутуй турында истәлекләр» китапларына нигезләнеп әзерләнде.



ТЫҢЛЫЙ ТОРГАН КИТАПЛАР, ЯКИ КӨТЕЛГӘН ТАТАРЧА ФОРМАТ



Сүз татар телендәге аудиоформат турында бара. Татарстан китап нәшриятының аудиокитаплар чыгара башлавы татар җәмәгатьчелеге тарафыннан бик хуплап, сөенеп кабул ителде. Чыннан да, күптән көтелгән заманча формат иде. Без аңарга болай да урау юллар аша озаклап килдек. Хәзер, ниһаять, бу өлкәдә дә «Булдырабыз!» дип әйтә алабыз, аның каравы.

Автор:
Луиза Янсуар

КУЛЫБЫЗ ҖИТСЕН!

Аудиокитаплар турында матбугатта яңалык пәйда булуга, https://tatkniga.ru сайтын даими күзәтеп бара башладым. Әйтергә кирәк, «эленә» барган китаплар моңарчы гел куандырып килде. Әлбәттә, барысын да тыңлап бетерергә өлгереп булмады, әмма күпчелеген тыңладым, тагын бер өлешен якын арада тыңларга әзерләп куйдым. Бу процессның үз ләззәте, үз тәме дә бар бит…

Нәшрият командасының бу эштә аудиториягә ачык булуы ошый. Заманча һәм оператив эш итәләр: социаль челтәрләрдә кемнең укуы яхшырак, туры киләрәк икәнен дә сораштыралар, тәнкыйтьне тыңларга да әзерләр, кыскасы, аудитория белән диалогта торалар, тыңлаучыларның фикерләренә колак салалар…

Аудиокитапларны тыңлаулары буенча мониторинг алып барыламы, дигән сорауга **Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррир урынбасары Венера Шәмсетдинова** болай дип җавап бирде:

– Сайтка беренче аудиокитапларны урнаштырган, ягъни проект старт алган көннән башлап, Татарстан китап нәшриятына карата булган кызыксыну күзгә күренеп артты. Сайтка керүчеләр саны буенча гына да билгеләп була моны: аудиоформат урнашканчы, керүчеләрдән өч тапкырга күбрәк хәзерге аудиториябезнең колачы…

Мин исә үзем аралашкан татар җәмәгатьчелеге вәкилләреннән шулай ук сораштырдым: кызганыч, күбесе, бу яңалыкны ишетсә дә, әле кереп тыңларга, танышып чыгарга «куллары җитмәгән». Бу нигездә әдәбият-сәнгатькә якын торган даирә: редакция хезмәткәрләре, язучылар, мәктәп укытучылары, артистлар, режиссёрлар, рәссамнар, композиторлар… Югыйсә, алар, иң беренче булып, ябырылырга тиеш иде бит инде нәшрият сайтына… Хәер, вакыт тыгыз, тормыш динамикасы котылгысыз заманда яшибез шул. Ә менә алда – Яңа ел «каникуллары», юллар, сәфәрләр, сәяхәтләр, буш вакыт, дигәндәй. Кулларыбыз җитәр, ниһаять, дигән өметтә калыйк. Үзебезнең милли контентны үзебез дә кирәк санамасак, санламасак, коммерция теле белән әйткәндә, «кулланмасак», аның ни хаҗәте бар…

Мин үзем бөтенләе белән аудиоформат тарафдары түгел, электрон формат – анысы әле бер хәл. Әмма бу очрак – икенче. Чөнки үзебезнең милли контентны алга җибәрү, популярлаштыру турында сүз бара…

Фотолар: Татарстан китап нәшрияты сайтыннан алынды

«МИЛЛӘТТӘШЛӘРГӘ ЯКЫНАЮ МАКСАТЫННАН...»

Илдар Сәгъдәтшин, Татарстан китап нәшриятының генераль директоры:

– Заманында «Таткнигафонд» дигән сайтыбыз бар иде. Анда 1,5 меңнән артык электрон китап урнаштырылды, ләкин тора-бара ул яңарту таләп итте. Китаплар юкка чыкмасын өчен, өр-яңа сайт ясадык. Аны эшләгәндә, электрон китаплар өчен дә, аудиокитаплар өчен дә бөтен мөмкинлекләр исәпкә алынды.

Соңгы арада аудиокитапларга сорау зур, ул без бүген генә уйлап тапкан ихтыяҗ түгел. Хәзер күпләрнең озаклап китап укырга вакыты юк. Укучыларыбызның күпсанлы мөрәҗәгатен исәпкә алып, милләттәшләребезгә тагын да якыная максатыннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановтан аудиокитаплар әзерләүдә булышлык итүне сорадык. Аңа бик зур рәхмәт, ул бу идеяне хуплады. Әлеге эшкә ике куллап тотынганчы, юридик мәсьәләләрне хәл итәсе бар иде. Аудиокитапларны эшләгәндә, авторлык хокукларына зур игътибар бирәбез. Моның өчен дә шактый вакыт таләп ителде. Һәм, ниһаять, быел без бу проектны башлап җибәрдек. Шулай итеп, аудиокитаплар www.tatkniga.ru сайтына урнаштырыла башлады. Аларны тыңлау бушлай һәм теләгән һәркем файлны үзенә күчереп алырга мөмкин. Моннан тыш, бүген сайтта 1 меңгә якын электрон китапны да бушлай уку мөмкинлеге бар.

Коммерцияле оешма буларак, безнең бурыч – нәшриятка табыш китерү дә. Шуңа, социаль автор китапларын бушлай куярга теләмәсә, аны шунда урнаштырабыз. Киләчәктә аудиокитаплар белән дә нәкъ шул рәвешле эшләү теләге бар. Татар әдәбиятының иң асыл үрнәкләреннән гыйбарәт аудиокитаплар базасы туплансын иде.

«ПРОЦЕСС – ҮЗЕ БЕР ЛӘЗЗӘТ...»

Айсылу Галиева, Балалар әдәбияты редакциясе мөхәррире, махсус проектлар өчен җаваплы:

– Проектның бюджеты нинди һәм бүгенге көндә ул ни дәрәҗәдә сарыф ителде?

Узган елда безгә проект өчен 2 миллионнан артык акча бүлеп бирделәр. Әлеге бюджетка барысы да керә: авторларга, артистларга түләү дә, студиядә яздыру да, монтаж да... 2018 ел азагына студиядә 162 сәгатьлек продукция яздырдык. Аудиокитапларны яздыру быел да дәвам итәчәк, монда инде күбрәк вакыт – 580 сәгать каралган.

– Кайсы әсәрләрне яздырасын кемнәр сайлады?

– Киңәш-табыш итешеп, үзебез сайладык. Бүгенге көнгә яздырган аудиокитапның 97се – татар халык әкиятләре, 46сы – матур әдәбият. Бу балалар өчен татар халык әкиятләрен яздырудан башланган процесс иде, алга таба инде менә XX йөз башы классик мирасыбызны да, Бөек Ватан сугышы чоры әсәрләрен дә, 60–70 нче еллар әдәбияты үрнәкләрен дә эшләдек. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Мәҗит Гафури, Мөхмүт Галәү, Һади Такташ, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Роберт Әхмәтҗан, Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан... Киләсе елга актив рәвештә бүгенге заман әдипләрен яздыру күздә тотыла. Шулай итеп, без, кулыбыздан, көчебездән килгәнчә, татар әдәбиятының иң матур үрнәкләрен укучыга тәкъдим итә алачакбыз.

«Сыйфат билгесе» булган, «алтын фонд»ны тәшкил иткән әсәрләр сайланды, иң беренче чиратта. Шулай ук, төрле яшьтәге укучыларыбыз өчен эшләргә тырыштык. Кайсы аудиториягә икәнлеген исәптә тотып, текстларны аерым яздырдык. Мәсәлән, Тукайның балалар өчен әсәрләре аерым аудиокитап булып бара, олкәннәр өчен язганнары – аерым. Башка язучылар белән дә шундый ук хәл. Тагын бер техник моментка басым ясыйсым килә: кулланырга уңайлы булсын өчен, без һәр шигырьне аерым файл итеп саклап бардык. Мәсәлән, Мөдәррис Әгъләмнең аудиокитабында 60тан артык шигырь бар, алар һәрберсе аерым сакланган. Бу бигрәк тә укытучылар өчен уңайлы – дәрестә кулланганда аңа, бәлки, аерым 1 генә шигыре кирәктер авторның, димәк, шул шигырьне аерып алып тыңларга да куя ала. Ә тулаем яздырган очракта, ул шигырьне эзләп табасы була бит әле, язманы әйләндереп, көтәсе...

– Борынгы әдәбият белән ничегрәк хәлләр?

– Бу очракта сүз, әлбәттә, яңа заман әдәбияты турында бара, әлегә без татар укучысына аны җиткерүне максат итеп куйдык. Борынгы чор, урта гасырлар әдәбияты – аларын да колачлап булыр, бәлки, киләчәктә. Әмма ул бик четерекле эш, чөнки борынгы әдәбиятның үз спецификасы бар, анда махсус белгечләр таләп ителә. XX йөз башына кадәр иҗат иткән әдипләрнең теле дә шактый катлаулы. Каюм Насыйриның «Әбүгалисина»сын яздырдык, аны, сайтка кереп, тыңларга мөмкин.

– Актёрлар, музыкантлар, көйләр сайлау буенча эш ничек алып барылды?

– Артистлар да, музыкантлар да бик теләп катнаштылар проектта, аларга зур рәхмәт. Үзләренә дә рәхәт булды шикелле, ошады... Мәсәлән, Илдус абый Әхмәтҗановның әкиятләрне яздыруын карап, ишетеп тору – үзе бер ләззәт. Ул аларны яхшы белә, су урынына эчә, «Су

анасы», «Шүрәле»ләрне яттан сөйли... Шулай яттан яздыра да...

Сайлау процессына килгәндә, табигый рәвештә, үзеннән-үзе килеп чыкты. Әйтик, Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» әсәрен Фәнис Җиһаншадан башка кемнеңдер укуында күз алдына да китерүе кыен. Аяз Гыйләҗевның «Яра»сын Илдар Кыямов бик тетрәндергеч итеп укыды, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы»н – Эмиль Талипов, «Гөләндәм туташ хатирәсе»н – Резеда Сәләхова... Артистлар белән генә түгел, ә музыкаль бизәлеш ягыннан да шулай. Әсәрнең үз тукымасында булган музыка, көйләр дә юнәлеш бирә кайчак, аның аһәңе, яңгырашы да көйне сорап, сайлап ала. Әйтик, «Гөләндәм туташ хатирәсе» ничек инде Салих Сәйдәшев музыкасыннан башка була ала ди? «Әйтелмәгән васыять»тә башкорт көе «Элмәлек» искә алына, без аны, язылу барышында, әлбәттә, аудиокитапка да кертеп җибәрдек. «Остазбикә» әсәрен яздырганда Динә Закированың скрипкасы соралды, ул әсәрнең яңгырашын тагын да тирәнәйтте. Монтаж ясаган вакытта студиядәге хезмәткәрләр дә музыкаль бизәлешне тагын да тәэсирлерәк итү турында кайгырта. Алар бик яратып эшли үз эшен, команда бик көчле!

– Авторлык хокуклары мәсьәләсе проблема тудырмадымы?

– Авторлык хокуклары мәсьәләсе һәрчак четерекле мәсьәлә инде ул. Тере язучылар белән бездә, гадәттәгечә, ике яклы килешү төзелә, бу очракта да шулай булды, ә исән түгелләренең исә – варислары белән. Варисларны эзләп табу шактый кыенга килә. Чыбык очы туганы табылса да әйбәт... Гаяз Исхакыйның варислары табылды менә... Язучының мирасы өчен кем җаваплы, шуларга түләнә.

– Кире элемтә бармы?

– Социаль челтәрләрдә бик күп язалар безгә, шалтыратып та рәхмәт әйтәләр. Шулай ук тәнкыйть белдерүчеләр дә, анализ ясап, җитешсез якларны күрсәтүчеләр дә бар. Бу бик мөһим! Әйтегез! Без бит эш процессында кайбер җитешсезлекләрне күреп җиткермәскә мөмкинбез. Консультантлар бар бу өлкәдә үз фикере, мөнәсәбәте булган, аларның тәҗрибәсенә дә таянабыз.

Сайтка кереп тыңлаучылар инде хәзер: «Кайчан диск итеп чыгарасыз?» – дип сорыйлар. Югыйсә, сайттан хәзер дә йөкләтеп алып, рәхәтләнеп өйдә, юлда, әйтик, машинада барганда тыңлап йөрергә була... Әмма тышкы бизәлеш, тәкъдим ителеш – болары да әһәмиятле, күрәсең. Менә сорашабыз, белешәбез хәзер: ничек итеп чыгарыйк икән – дисктамы, флешкадамы? Өлкән һәм урта буын вәкилләре күбрәк дискта чыгарыгыз, ди, яшьрәкләр өчен, мөгаен, флешкада җайлырак булыр иде.

– Миңа калса, махсус кушымта итеп эшләргә дә мөмкин...

– Барлык яшьтәге аудиторияне дә колачлый алсак, шәп булыр иде... Без хәзерге көндә һәркемнең фикерен тыңларга әзер: продуктив тәкъдимнәр киләчәктә безгә сыйфатны яхшыртырга ярдәм итәр иде.

«ЗАМАННАН АРТТА КАЛА АЛМЫЙБЫЗ!»

Данил Салихов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе:

– Электрон формат белән аудиоформатка йөз тоту – заман таләбе. Без заманнан артта кала алмыйбыз. Бу бүгенге көндә татар китабына укучыны җәлеп итүнең иң үтемле һәм дөрес юлларыннан берсе, дип уйлыйм. Татар укучысына заманыбызның затлы артистлары тавышы белән әдәби ядкәрләрне җиткерү – нинди шәп чара.

Заманында радио өчен минем бер әсәремә инсценировка эшләгәннәр иде. Шуны искиткеч күп халык тыңлаган булып чыкты. Китапны кулга алып укымаучылар да тыңларга мөмкин бит аудионы. Күзләре зәгыйфь, йә бөтенләй күрми торган кешеләр, йә булмаса... Димәк, аудиторияң күзгә карап киңәя, дигән сүз.

Безнең хәзер ярты гомеребез юлда уза, тормыш тынгысыз, тизлекләр зур. Бишәр, алтышар йөз километр юлга чыгып китүләр – гадәти эш. Менә шунда куясың да, барып җиткәнче рәхәтләнеп повесть, роман тыңларга өлгерәсең. Әдәбият дөньясыннан ераграк торган кешеләр өчен дә бик кулай формат. Җитәкчеләр өчен – әйтеп тә торасы юк, аларның китап укып утырырга вакытлары аз, ә болай – менә дигән форсат.

«МИЛЛИ ДӘ, ЗАМАНЧА ДА...»

Динә Закирова, Г.Камал театры оркестры скрипкачысы:

– Әдәбиятка гашыйк кеше буларак, мине әлеге проектта катнашырга чакыргач, бик сөендем. Әсәрләргә музыкаль бизәлеш буларак, скрипкада татар халык җырларын уйнап яздырдык, милли көйләребезне: «Галиябану»ны, «Тәфтиләү»не, «Әллүки»не... Яздыру процессы бик тыныч, рәхәт иде – тавыш операторы зур профессионал, команда җайлы эшли. Хәзер язмаларны үзем дә рәхәтләнеп тыңлыйм, киләчәктә, чакырсалар, проектта тагын да катнашырга телләр идем. Уңышлы, озын гомерле проект булсын...

«ТАРИХИ ПРОЦЕССНЫҢ ӨЛЕШЕ БУЛУ – ЗУР ДӘРӘҖӘ»

Резеда Сәләхова, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры актрисасы:

– Бу – искиткеч идея! Беренчедән, мәктәп укучылары һәм укытучылары, студентлар өчен – бик шәп чыганак. Гомумән, татар дөньясы өчен бу – бик кирәкле, көтеп алынган проект. Катнашырга чакырулары өчен мин бик рәхмәтле. Шулай итеп тарихка кереп калу – зур дәрәҗә.

Минем укуымда Гаяз Исхакыйның – «Көз», Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларын яздырдык, берничә хикәя. 2019 елда да чакырабыз катнашырга, зур гына роман көтә, диделәр. Бу – Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәре. Мин инде канатланып көтәм яздыру вакытын...

Яздыру процессы – катлаулы эш. Чөнки бер дубльдан гына килеп чыкмый. Кайта-кайта укыйсың, ялгышсаң, яңадан башлап, тиешле интонацияне эзлисең, яңгырашны иң камил дәрәҗәдә бирергә тырышасың. Нәкъ менә шул яңгыраш аша тыңлаучы әсәрне беренче тапкыр кабул итәргә дә мөмкин бит. Ә ул аны кызыктырмаса... Кызыктырырга тиеш!

ӘДӘБИЯТНЫҢ КЫЙММӘТЕН АҢЛАСАК...

Раил Гатауллин, Татнетны үстерү фонды, Белем.ру компаниясе һәм #әдәбимарафон җитәкчесе:

– Татарстан китап нәшриятының аудиокитаплар әзерләгәнен алдан ук ишетеп белә идем. Без (Татнетны үстерү фонды) Татарстан китап нәшрияты белән берлектә бик матур әдәби чара – әдәби марафон проектын үткәрәбез. Марафонда катнашучыларыбыз да бу яңалыкны иң беренчеләрдән булып ишеттеләр.

Нәшриятның сайтында (tatkniga.ru) «Аудиокитаплар» бүлегендә минем иң беренче тыңлаган аудиоязмаларым Хәсән абый Туфанның шигырьләре булды, анда 60 тан артык шигырьне профессиональ актер башкаруында тыңларга мөмкин.

Татарстан китап нәшриятының әлеге адымын чын күңелдән хуплыйм, татар теленең һәм татар әдәбиятының кыйммәтен аңлаган кешеләр әлеге фикеремә кушылырлар, дип ышанып калам.

«КУХНЯ ТЕЛЕ ГЕНӘ БУЛМАСЫН...»

Лилия Ярхәмова, яшь әни, Казан:

– Улым белән сайттан нигездә әкиятләр тыңлыйбыз. Үзем исә, иң беренче эш итеп, шагыйрьләрне тыңладым: Хәсән Туфанны, Һади Такташны... Без рус телле мохиттә яшибез бит, шуңа күрә татарчаны камил итеп сөйләгән артистлардан ишетеп үссен, дим, балабызны. Кухня теле генә булмасын иде татар теле аның өчен. Минем буыным да шәһәрдә татарчаны тиешле дәрәҗәдә үзләштерә алмады. Әле ярый, бәхеткә, безне авылга әби-бабайларга кайтарып куялар иде, шунда җай буе телең рәтләнеп өлгерә, чын татарча сөйләшә башлыйсың. Әмма аннан соң кабат рус телле Казанга киләсең. 90 нчы еллардан соң хәл үзгәрде, дибез дә диюен, әмма «двор»лар, күпчелек садик-мәктәпләр бит барыбер русча сөйләшеп үсте... Минем улым да тиздән шул мохиткә барып эләгәчәк...

«ТАВЫШНЫҢ ТАРТУ КӨЧЕ»

Эльвира Хафизова, укытучы, Әлмәт:

– Татарстан китап нәшрияты үз сайтына аудиокитаплар элә башлаган, дигән хәбәр ишеткәч, шулкадәр сөендем: ниһаять, балаларга әсәрләрне яхшырак сеңдереп булачак икән, дидем. Мин өлкән сыйныфларда укытам, яшерен-батырын түгел, хәзерге балаларны утыртып куеп, калын-калын томнар укыту – мөмкин булмаган эш. Кыскарак әсәрләрне әле – бер хәл. Кайчандыр без томлап-томлап укыган классиканы алар инде ябышып ятып укымый. Игътибар итегез: сүз борынгы әдәбият үрнәкләре турында түгел, ә XX йөз башы һәм узган гасырның урталарында язылган әсәрләрдәге тормыш картинасы турында бара. Ул да инде әллә ни таныш түгел алар өчен. Әмирхан Еникиләр, Мөхәммәт Мәһдиевлар сурәтләгән чынбарлык, мисал өчен...

Аудиокитапның үзенә күрә бер тылсымы, тарту көче бар. Үз балаларыма да тыңларга куям. Бу проектта бик күп затлы артист-музыкантларыбыз катнаша, аларны тыңлап кына да сәнгатькә якынаясың бит.

«ЯҢА ӘСӘРЛӘР КӨТЕП КАЛАБЫЗ...»

Илдус Хөснетдинов, пенсионер:

– Безнең заманда радиодан шундый яхшы радиоспектакльләр тапшыралар иде. Татар язучыларының әсәрләре буенча. Халык шуларны бик яратып тыңлады. Менә бу аудиокитаплар да – шул матур традициянең дәвамы кебек тоелды миңа. Яңа буынга телебезне үзләштерер өчен дә – бер форма. Юкса, мин телне вата-җимерә акцент белән сөйләшкән балаларны тыңлап шаклар катам... Оныкларга тыңлата башладык. Яңа әсәрләрне көтеп калабыз.

P.S. Йомгак ясап, шуны да искәртәсем килә: бер төркем әдәбият-сәнгатьне күзәтеп баручы яшьтәшләрем һәм миннән яшьрәкләр, ягъни, 40-35 ләр тирәсе һәм аннан яшьрәкләр (ә бит аудиоформат белән электрон форматны нәкъ менә «аларныкы» дип исәплибез), бүген, ни гаҗәп, кәгазь форматка өстенлек бирә башлады. Кайбер психологлар һәм социологлар әйтүенчә, әлеге тенденция бүген аеруча актуаль. Массачыл рәвештә кәгазь китапка «кайту» процессы. Кәгазь китап культурасын трендка әверелдерергә омтылу.

Менә шундый парадокс! Хәер, асылда, бик тә аңлашыла торган күренеш: билгеле бер ыргылыштан соң, дулкын да, ярларны юып, кабат үз стихиясенә кайта лабаса.

МӘШҺҮР ХАНБИКӘЛӘР: НУРСОЛТАН

Әле борынгы күчмәннәр җәмгыятендә үк, бигрәк тә Төрки каганлыгы чорыннан башлап, соңыннанрак исә инде Урта гасырлар чорында мөселман дәүләтләрендә хатын-кызлар хакимият эшендә һәрчак актив катнашып килгәннәр. Җучи Олысы (Алтын Урда) ханнарының сөекле хатыннары дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәт юнәлешләрен билгеләгәндә, хан тәхетенә яңа кандидатлар сайлаганда кайвакыт хәлиткеч роль уйнаганнар. Казан ханлыгында безгә мәгълүм күренекле затлар арасында Фатыйма-солтан, Нурсолтан, Гәүһәршад һәм Сөембикә ханбикәләрнең исемнәре бар.

Автор: Фаяз Хуҗин

Ни кызганыч, язма чыганакларда бу ханымнар турында мәгълүматлар бик аз. Бигрәк тә Фатыйма-солтан турында. Нурсолтан белән Гәүһәршад исемнәре елъязмаларда күбрәк очрый, чөнки алар Казан ханлыгында гына түгел, күрше илләрдә дә сәясәтче һәм дәүләт эшлеклеләре буларак танылганнар. Сөембикә-ханбикәнең сәяси эшчәнлегенә карaганда, фаҗигале язмышы күбрәк билгеле. Гәүһәршад һәм Сөембикә турында сүз киләчәк язмаларыбызда булыр. Ә хәзер Нурсолтан турындагы язмабызны Фатыйма-солтаннан башлап китәргә ниятлибез.

КЕМ УЛ ФАТЫЙМА-СОЛТАН?

Элек-электән, борынгы кешелек җәмгыяте чорларыннан башлап диярлек, ыруг-кабилә юлбашчыларының, патша-корольләрнең, хан-солтаннарның кайчан һәм кем белән никахлашуларына нык игътибар биргәннәр. Бу эшләрдә инде беренче планда мәхәббәт түгел, бәлки сәясәт торган. Шул күзлектән чыгып, тәхеткә куелган дәүләт җитәкчеләре хатынлыкка яраклы чибәрләрне үзләре арасыннан түгел, күрше илләрдән, чит дәүләтләрдән сайлап алырга тырышканнар. Әлбәттә, идарәче аксөякләр катлавыннан. Кайчакта хәтта кәләшләрнең бөтенләй ят телдә сөйләшүләренә һәм башка дин тотуларына да игътибар итмәгәннәр. Ни генә димә, югары катлау әһелләренең никахлашуы нәтиҗәсендә «туганлашкан» дәүләтләр арасында ызгыш-талашлар, сугышлар сирәгрәк булган.

Фатыйма-солтан – Нугай морзасы Мусабәк кызы (сүз уңаеннан: Мусабәкнең өлкән улы Йосыф морза – Сөембикәнең атасы). 1467 елда аны, Казанга алып килеп, Ибраһим ханга кияүгә бирәләр. Ибраһим хан белән Фатыйма-солтанның Илһам, Ходайкол һәм Мәлик-Таһир исемле өч уллары була. Без инде алар турында узган язмабызда сөйләгән идек. Исегездәдер, 1479 елда, Ибраһим хан үлгәннән соң, тәхеткә аның олы улын – Илһамны утырталар. 1485 елда Мәскәү гаскәрләре ярдәмендә ул тәхеттән куыла, әмма тиз арада нугайлар ярдәме белән яңадан тәхет хуҗасына әверелә. 1487 елның язында Иван III гаскәрләре Казанны камап ала, июльдә исә алар алдында шәһәр капкалары ачыла. Илһам ханны тәхеттән бәреп төшерәләр (Иван III кулына аны үзебезнең татарлар үк китереп тоттыралар) һәм хатыннары белән башта Мәскәүгә, аннан соң Вологдага сөргенгә озаталар. Әнисен, энеләре Мәлик-Таһир белән Ходайколны һәм сеңелләрен Белоозеро тирәсендәге Карголом шәһәрчегенә сөрәләр. Фатыйма-солтан һәм аның улы Мәлик-Таһир шунда үлеп калалар.

ТИМУР-БӘК КЫЗЫ НУРСОЛТАН

Ул да, Фатыйма-солтан кебек үк, Нугай далаларында туып-үскән кыз. Унҗиде яшьләр тирәсендә Нурсолтанны Казан ханы Хәлилгә кияүгә бирәләр. Хәлил ханлык белән озак идарә итә алмый, яшь кенә килеш гүр иясе була. Тол калган Нурсолтанны, борынгыдан килгән йола буенча, аның энесе Ибраһим

хан үзенә икенче хатынлыкка ала. Бу никахтан аларның Мөхәммәдәмин һәм Габделлатыйф исемле уллары, Гәүһәршад исемле кызлары дөньяга килә.

1479 елда Ибраһим хан, яшь кенә балаларын – ятим, хатыннарын тол калдырып, якты дөнья белән хушлаша. Мәрхүмнең өлкән хатыны Фатыйма-солтан Казанда кала, чөнки улы Илһамны әтисе урынына хан тәхетенә утырталар, Нурсолтанны Кырым ханы Миңлегәрәй үзенә хатынлыкка сорый – ул бу чибәр һәм акыллы хатынны кыз чагыннан ук белгән була инде. Нурсолтан ризалыгын бирә һәм тиздән, яңа гына ун яшен тутырган Мөхәммәдәминен Мәскәүгә, Иван III хозурына озатып (Мәскәү күзгә күренеп ныгый-көчәя, Казанны тынычлыкта калдырмас, бәлки, улымнан хан да ясап куяр әле, дигән өмет беләндер, күрәсең), төпчек улы Габделлатыйфны үзе белән алып, Кырымга – Бакчасарайга китеп бара. Аның яңа ире Миңлегәрәй – Кырымны Алтын Урдадан аерып алып, мөстәкыйль ханлыкка нигез салган атаклы Хаҗигәрәй ханның улы. Миңлегәрәйнең Нурсолтанга кадәр дә берничә хатыны булган, әмма Нурсолтан тиз арада һәм, әйтергә кирәк, җиңел генә аның иң дәрәҗәле һәм сөекле хатынына – олуг ханбикәгә әверелә. Чибәр, мөлаем һәм сөйкемле ханым башкаларыннан, күрәмсең, үзенең зирәк акылы, тыныч табигате, түземлелеге һәм кешеләр белән уртак тел таба алу сәләте белән аерылып торгандыр.

Миңлегәрәй күзлегеннән чыгып караганда исә, Нурсолтан аның никахлы хатыны гына түгел, бәлки Казан ханлыгын һәм Ногай Урдасын Кырым белән туганлаштырган илче-дипломат та. Өстәвенә, әле ул Мәскәү кенәзе белән дә дустанә мөнәсәбәттә тора – олы улы Мөхәммәдәмин Иван III кул астында Каширада яши. Шунлыктан Нурсолтанның әкренләп хан киңәшчесенә әверелеп китүен аңлау бер дә авыр түгел. Казан ханнарына, Нугай морзаларына Нурсолтан аша йогынты ясап тору үзе дә – Кырым файдасына.

Мәскәү ныгыса, Казанга тыныч яшәргә ирек куймас, дип, Нурсолтан дөрес уйлаган икән. 1487 елгы вакыйгалар шуны күрсәтә: Иван III, Казанны яулап алып, биредә Мәскәү протектораты урнаштыра. Илһам хан илдән сөрелә, Мәскәү тәрбиясе алган Мөхәммәдәмин исә, нәкъ әнисе фаразлаганча, хан тәхетенә утыртыла.

Эшләр әйбәт бара, инде төпчек малай турында да уйларга вакыт, ул да балигъ булып килә бит. Миңлегәрәй, сәясәт ихтыяҗларын күз алдында тотып, Габделлатыйфны Мәскәүгә, Иван III тәрбиясенә җибәрергә тәкъдим ясый. Нурсолтанның аны читкә җибәрәсе килми, әмма ире белән ризалашырга мәҗбүр була. 1493 елның 6 августында Габделлатыйфны Мәскәүгә озаталар.

Нурсолтан, улының язмышы өчен борчылып, Иван III кә хат юллый:

«Үзең аңлыйсыңдыр, кадерле улымны мин, зур ышаныч вә өметләр белән, синең карамакка җибәрдем. Ул бала язмышын үзең теләгәнчә хәл ит: йә үзеңдә тот, асра, йә олы абыйсы Мөхәммәдәмин янына җибәр, колыңнан килгәнче тынычландыр аны. Ул үзе дә, аның абыйсы да бик яшьләр. Алар берберсен яратып яшәрләр. Безнең үтенечебез шул: син аларга үзең белгән кадәр яхшы шартлар тудырсаң иде. Алланың рәхмәте төшсен сиңа дип, теләктәш булып калабыз. Ә без инде синең туганың Миңлегәрәй патша белән бергә, үзебез исән-имин чакта вә әлегә хәлдән килгәнчә, синең һәрбер эшеңдә ярдәмче булырбыз. Әгәр Мөхәммәдәминнең угланнары вә морзалары, хәтта казанлыларның барысы да, сиңа баш иеп һәм яхшылап үтенсәләр, син Габделлатыйфны алар янына җибәр. Әгәр инде җайлап, бик теләп, чын күңелдән үтенмәсәләр, үзең кара, үзеңдә тот, үзең белгәнчә асра... Энесен олы агасы янына җибәрсәң дә, үз яныңда калдырсаң да, аңа абыз (тәрбияче) дәрәҗәсендә бик яхшы бер кеше билгелә. Иң яхшысы аның әтисе Ибраһим кешеләреннән берәрсен...»

Иван III Нурсолтанның теләгенә каршы килми: Габделлатыйф Мәскәүдә калдырыла, «туенып тору өчен» аңа Звенигород шәһәре бирелә. Күңеле бераз тынычлангач, 1495 елда абыйсы Хәсән морза һәм илледән артык сакчысы белән Нурсолтан Мәккә-Мәдинәгә хаҗ сәфәренә чыгып китә. Кайтыр юлын Мисыр аркылы билгели. Озакка сузылган бу сәфәр аның исемен Мисырда гына түгел, Төркиядә һәм Якын Көнчыгыш илләрендә дә киң танытуга ярдәм итә.

Әмма сәфәрдән әйләнеп кайтуга, Нурсолтанга Казандагы улының хәлләре турында борчулы хәбәрләр ишеттерәләр. Биредә Шәрыкка йөз тоткан төркем Мәскәү яклы Мөхәммәдәмин ханга каршы көрәш башлаган икән. Бу көрәш хан тәхетенә Мөхәммәдәмин урынына Себер угланы Мамыкны (ул Бату ханның энесе Шәйбан нәселеннән) утырткач, беразга сүрелеп тора. Әмма Мамык уңышсыз хан булып чыга, берничә айдан аны куып җибәрәләр.

«ТУГАНЛЫК ҺӘМ ДУСЛЫККА ЧИК КУЯСЫҢ...»

1497 елдан башлап, тәхеттә – Габделлатыйф хан. Мәскәү воеводалары алдында ул Казан халкына гына түгел, шәхсән Иван III кә дә тугрылыклы булырга ант итә. Хакимлек итүенең беренче елларында ул үз антына, чыннан да, тугрылыклы кала, әмма соңрак озак еллар Кырым шартларында тәрбияләнгән хан мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый. Моңа хөкүмәт башында торган Коләхмәт катгый каршы чыга. Ике төркем арасында бәхәс куба, көрәш башлана. Көрәш 1502 елда Габделлатыйфның тәхеттән куылуы белән тәмамлана. Аны тоткын итеп, Мәскәүгә алып китәләр һәм Белоозерога сөргенгә озаталар. Казан тәхетенә яңадан Мөхәммәдәмин менеп утыра.

Мөхәммәдәминнең Казанга кайтуы Нурсолтанны сөендерсә, Габделлатыйф язмышы кайгыга сала. Иван III нең мондый кыланмышы хәтта Миңлегәрәйнең дә ачуын чыгара. Кырымнан Мәскәүгә хатлар агыла башлый. Миңлегәрәй ханның 1503 елда язылган хатыннан бер өзек:

«Без бит аны синең яныңа ачлыктан-ялангачлыктан җибәрмәдек. Син бездән, яхшы ният белән җибәрегез, дип үзең үтендең. Без җибәрдек. Хәзер инде үтенечем шул: яхшы гына, кадерләп кенә асра, яшәт үзеңдә, бир аңарга җир. Әгәр шулай итәргә теләмәсәң, җибәр аны үзебезгә. Син аны бер тапкыр җәзага тарттың бит инде. Җитәр, гафу ит аны! Әгәр безнең үтенечне үтәмәсәң, шуның белән безнең туганлык вә дуслыкка чик куясың булып чыга. Ул чакта безнең арадагы хаклык бетте дип уйларга кирәк».

Иван III Габделлатыйфны сөргеннән азат итәргә мәҗбүр була, аңа Мәскәүдә яшәргә рөхсәт итәләр. Әмма Нурсолтанның күңеле, олы улы хан тәхетен биләп торса да, тыныч түгел. Ул аңлый: Мөхәммәдәмингә бик авыр. Өстәвенә, әле бит Фатыйма-солтанның улы Илһам да Вологдада тоткынлыкта. Әйе, барысының да язмышы Иван III кулында, һәм ул бу хәлдән бик оста файдалана.

Шөкер, дөньялар үзгәреп тора, бу дөньяга беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Әнә, Мәскәүдән Иван III нең авырып китүе, үлем түшәгенә ятуы турында хәбәрләр килеп тора. Мөхәммәдәмин Мәскәүгә каршы түгел, әмма үз дәүләтеңнең мәнфәгатьләрен дә онытырга ярамый бит. Һәм ул, килеп туган уңайлы форсаттан файдаланып, Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген кире кайтару өчен көрәшергә карар кыла.

1505 елның 24 июнендә, зур ярминкә башланасы көндә, Казанда рус сәүдәгәрләренең товарларын талап алалар, үзләрен үтерәләр, әсирлеккә алалар, кыскасы, мәхшәр була. Алай гына да түгел, Мөхәммәдәмин 40 мең казанлыдан, 20 мең нугайдан торган гаскәр белән рус җирләренә бәреп керә. Түбән Новгородны яндыралар, талыйлар. Сугышлар 1506 елда да дәвам итә. Казанга ук килеп җиткән рус гаскәрләре, артык уңышка ирешә алмыйча, кире чигенә.

ХӘЛЛӘР КИСКЕНЛӘШКӘНДӘ

Мөхәммәдәмин авыр хәлдә: руслар белән гел сугышып торып булмаслыгын да аңлый, Мәскәүнең ныгуын, Казанның исә отыры көчсезләнә баруын да күреп тора. Ни генә булмасын, үзең тәхеттә утырганда, дәүләтең турында күбрәк кайгыртырга кирәк. Һәм ул, әнисе киңәше белән булса кирәк, Мәскәүнең яңа бөек кенәзе Василий III кә, кылган гамәлләре өчен гафу үтенеп, хат яза. Энесе Габделлатыйфны әсирлектән тулысынча азат итеп, Кырымга кайтаруларын сорарга да онытмый. Бу теләккә Василий бик җитди карый, Мөхәммәдәмин хаты хәтта Боярлар Думасында (!) тикшерелә, анда Габделлатыйфның «гөнаһларын» гафу итәләр, әмма үзен Мәскәүдә калдыралар.

Василий III нең бу гамәлләре Нурсолтанны канәгатьләндерми. Ул үзе Мәскәүгә омтыла. Ниһаять, ире Миңлегәрәйдән рөхсәт алып, 1510 елның җәй башында Нурсолтан Мәскәүнең Кырымдагы илчесе Морозов, Миңлегәрәйнең кече улы Сәхибгәрәй, ханның өч илчесе, сакчы-хезмәтчеләре белән Мәскәүгә чыгып китә. Василий III Нурсолтанны кадерле кунагы буларак кабул итә. Нурсолтан Мәскәүдәге улы янында бер ай чамасы яши. Аннан соң Казанга юл тота, биредә бер елга якын яши, Мөхәммәдәминне Мәскәү белән дус яшәргә, сугышлар белән мавыкмаска чакыра.

1511 елның 22 июнендә Нурсолтан – яңадан Мәскәүдә. Кече улы янында ярты елга якын яшәп, декабрь башларында Кырымга кайтып китә. Габделлатыйфны әсирлектән ахыргача азат итә алмый ул, әмма Мәскәү дәүләте белән Кырым ханлыгы арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнашуына сөенеп, бик канәгать булып кала.

Кырымның исә үзенең проблемалары: Миңлегәрәй авыру, урын өстендә; уллары әтисенең Мәскәү белән мөнәсәбәтләрендә урнаштырылган тышкы сәясәтен бер дә хупламыйлар. Литва кенәзе Сигизмунд та аларны Мәскәүгә каршы котырта. 1512 елда алар хәтта Мәскәүгә яу чабалар. Нәтиҗәсе бик аяныч: Василий III Габделлатыйфны тагын иреген нән мәхрүм итә. Тагын Кырым белән Мәскәү арасында хатлар. Миңлегәрәй белән Нурсолтан Габделлатыйфны катгый рәвештә әсирлектән азат итүләрен таләп итәләр. Мәскәүдән уңай җавап килми.

1515 елда Миңлегәрәй хан үлеп китә. Кырымның яңа ханы Мөхәммәтгәрәй Мәскәү белән кырыс сөйләшә – сабырлыкның да чиге була ич. Василий III Габделлатыйфны азат итәргә сүз бирә. Шул арада Мөхәммәдәминнең озакка сузылган каты авыруы башлана. Ул тәхетне энесе Габделлатыйфка калдырырга теләве турында белдерә. Казан илчеләре бу турыда Василийга хәбәр итәләр. 1516 елда Василий III Габделлатыйфны әсирлектән азат итеп, «туенып тору өчен» аңа Кашира шәһәрен бүләк итә. 1517 елның ноябрендә 42 яшьлек Габделлатыйф кинәт үлеп китә. Көтелмәгән үлемнең сәбәбен ачыклый алмыйлар, әмма күпләр өчен ул сер булмый.

1518 елда Мөхәммәдәмин дә якты дөнья белән хушлаша. Өч иренең, сөекле улларының үлемен күреп тирән хәсрәтләр кичергән, җитмештән артык яшәп олы дөнья мәшәкатьләрен татыган Нурсолтан бикә бу хәлләрдән соң озак яши алмый. Инде 72 яшен тутырган ханбикә 1519 елда Бакчасарай шәһәрендә вафат була. ■

МАХСУС ПРОЕКТ

— 38нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Альберт Петров,
«Камгэсэнергострой» КТИ» ҖЧҖ җитәкчесе,
февральдә үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә.

РУХЫ БУЕНЧА ТӨЗҮЧЕ

Санкт-Петербургтагы «Конгресслар сарае» дәүләт комплексында «Камгэсэнергострой» КТИ» ҖЧҖ Чаллы предприятиесен «Россиянең ышанычлы төзүчесе 2018» – өлешләп төзүдә җәмәгать контроленең Алтын билгесе белән бүләкләү тантанасы бара. Ышанычлы эшлеклелек абруе – югары профессиональ коллективның аерылгысыз сыйфаты. 1991 елдан бирле әлеге коллектив белән РФ һәм ТРның атказанган төзүчесе, техник фәннәр кандидаты, Халыкара тормыш куркынычсызлыгы һәм экология фәннәре академиясенең мөхбир әгъзасы, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының мактаулы профессоры, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданины һәм Чаллы якташлыгы президенты Альберт Петров җитәкчелек итә. 12 февральдә атаклы төзүче үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә.

Альберт Петров – легендар КАМАЗ төзүчеләр токымыннан. Яр Чаллы – аның кече Ватаны. Альберт Николаевичның бөтен балачагы биредә – Чулман ярында урнашкан тын шәһәрчектә үтә. 1971 елда Казан дәүләт инженер-төзелеш институтын тәмамлаганнан соң, ул гигант төзелеш мәйданчыгына әверелгән туган шәһәренә юллама ала. Шулай итеп Бөтенсоюз удар комсомол төзелешенең үзәгенә эләгә. Эшен мастерлыктан башлый, аннан соң «Камгэсэнергострой» ҖБнә караган 1нче Эретмә-бетон заводының тимер-бетон җыю полигонында башлык булып эшли. Заводның баш инженеры урынбасары вазыйфасы һөнәри үсешендә тагын бер баскыч була. Җитмешенче еллар уртасында ул инде көчле лидерлык сәләтенә ия талантлы инженер, җәмәгатьчелеккә яхшы таныш шәхес (һәм үз тармагында гына түгел) булып җитешә. Алдагы дистә ярым ел аралыгында җаваплы партия һәм хуҗалык постларын били. КПССның Яр Чаллы шәһәр комитетының төзелеш бүлеге инструкторы, аннан соң – мөдире, «Камгэсэнергострой» ҖБ баш инженерының шәһәр төзелеше буенча урынбасары, КПССның Алабуга шәһәр комитетында икенче секретарь, Яр Чаллы шәһәр башкарма комитеты рәисенең төзелеш буенча урынбасары булып эшли.

1991 елның декабреннән Альберт Николаевич «Камгэсэнергострой» Капиталь төзелеш идарәсе» ҖЧҖнә җитәкчелек итә башлый. Идарә башта торак һәм социаль-мәдәни объектлар заказчысы ролен башкара. 28 ел дәвамында Альберт Николаевич җитәкчелегендәге коллектив тарафыннан комплекслы төзелешкә караган 70 проект тормышка ашырылган, 427 мең квадрат метрдан артык торак инде төзеп тапшырылган. Саклык банкының Яр Чаллы бүлеге, Промстройбанк, Мәгълүмат-исәпләү үзәге, пединститут биналары кебек мөһим объектлар сафка бастырылган.

Идарә балалар, спорт, дини оешмаларга, мөмкинлекләре чикле кешеләргә хәйрия ярдәме күрсәтә. Әлеге игелекле эшчәнлеккә башлангыч бирүче дә, аны әйдәп баручы да – Альберт Николаевич үзе. Төзүче һөнәренә фидакарьләрчә бирелү күп вакытын алса да, ул гармониядә яшәүче кеше булып кала. Буш вакытларын ике баласы, алты оныгы сөендереп торган гаиләсенә багышлый. Туган як табигатен ярата, ау, балык тоту белән мавыга. Хезмәттә һәм җәмәгать эшчәнлегендә ирешкән казанышлары өчен юбиляр дәүләт бүләкләренә лаек булган. Шулай да аның өчен иң кыйммәтле бүләк – якташларының мәхәббәте, ихтирамы һәм хөрмәте. Идарә коллективы, күпләгән дуслары, коллегалары, туганнары һәм якыннары, юбилярга рәхмәтле Яр Чаллы халкы Альберт Николаевичны 70 яшьлеге белән тәбрикли һәм иң җылы теләкләрен юллый.

Фото «Камгэсэнергострой» КТИ» ҖЧҖнән алынды.

Реклама

Юрий Аляшев,
ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары

– Альберт Николаевич Петров – төзелеш тармагы җитәкчелегенең Татарстан корпусының күренекле вәкиле. Аңа үз эшен тирәнтен белү, туктаусыз иҗади эзләнү халәте, югары дәрәҗәдәге җаваплылык, көчле оештыру таланты һәм кешеләргә игътибарлылык, дуслыкка тугрылык кебек күркәм сыйфатлар хас. Мин чын күңелдән Альберт Николаевичны юбилее белән котлыйм һәм иң изге теләкләремне юллый алуыма шатмын!

Илгиз Хәбибуллин,
«СМУ-51» ҖЧҖ директоры

– Альберт Николаевич Петров – төзелеш тармагында бик кадерле нәрсәләр – профессионализм, җаваплылык һәм ышанычлылык үрнәге. Ул үз тирәсенә белгечләр командасын туплый, шәһәрдә инженерлар һәм төзүчеләрнең берничә буынын үстерә, Яр Чаллыны төзүгә һәм үстерүгә гаять зур өлеш кертә алды. «СМУ-51» ҖЧҖ коллективы Альберт Николаевичны күркәм юбилее белән чын күңелдән котлый. Сәламәтлек, актив озын гомер, иминлек һәм яңа казанышлар тели!

Марат Беляев,
бизнесмен

– Күптәнге дустымны һәм уртак эш буенча иптәшемне 70 яшьлеге уңаеннан шатланып һәм зур горурлык белән тәбриклим. Безгә бергә укырга һәм туган шәһәребез Яр Чаллы иминлеге хакына хезмәт куярга насыйп булды. Язмыш шулай язгандыр: Альберт Николаевич Петров төзелеш тармагында профессионал һәм оста җитәкче буларак автоградта барган Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше шартларында формалашты. Бөек мәктәп узды ул. Һәм мин дустыма ныклы сәламәтлек һәм игелекле эшендә яңа уңышлар телим.

Марат Фадауллин,
«Челнинское МУС-2 ТСТМ» ҖЧҖ директоры

– Абруйлы компания җитәкчесе буларак, Альберт Николаевичның республика төзелеш тармагы өчен яшь кадрлар әзерләүгә җитди игътибар күрсәтүе бик югары бәягә лаек. Үзе белем алган вузы – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының мактаулы чыгарылыш вәкиле буларак, ул белем бирү учреждениесе эшчәнлегенә мактаулы профессор һәм Дәүләт аттестация комиссиясе әгъзасы сыйфатында үз өлешен кертә. Бу төзелеш ветераны күрсәтә торган шәп үрнәк! Нык сәламәтлек һәм озын гомер сезгә!

Сергей Ямашев,
«Камгэсэнергострой» ГАҖ директорының төзелеш буенча урынбасары

– Альберт Николаевич Петров шәхесенә, һөнәри эшчәнлегендә бөек казанышларга ирешү белән берррәттән, һәрвакыт җаваплы гражданлык позициясе, көчле иҗтимагый темперамент, дәүләт дәрәҗәсендәге ир-ат зирәклеге хас булды. Бу турыда, мисалга, аның шәһәр Советындагы депутатлык эшчәнлеге сөйли. Кешеләр аңа тартыла, чөнки Альберт Николаевичта чын күңелдән ярдәм итәргә тырышучыны һәм шуны башкаручыны, туган шәһәрен яратучыны күрә. Юбилярыбызга сәламәтлек, бәхет, игелекле эшләрендә яңа уңышлар юлдаш булсын!

Равил Кашапов,
Чаллы якташлар җәмгыятенең башкарма директоры

– Яр Чаллы шәһәрендә туган, аның үсеше һәм чәчәк атуы өчен күп көч сарыф иткән кеше буларак, Альберт Николаевич Петров лаеклы рәвештә якташлары арасында лидер санала һәм «Чаллы якташлыгы» иҗтимагый оешмасының президенты булып тора. Аның әле бүген дә сафтагы җитештерүче, оста җитәкче, шәһәр төзелеше ветераны, галим һәм педагог, намуслы шәхес һәм менә дигән гаилә башлыгының шәхси үрнәге яшьләрне тәрбияләүгә, үз шәһәрләрен сөюче барлык кешеләрне изге эшләргә туплауга хезмәт итә. Мин Альберт Николаевичка юбилей уңаеннан ихлас котлауларымны җиткерәм!

Камил Исхаков, ТР Президенты ярдәмчесе, Болгар ислам академиясен гамәлгә куючылар Советы рәисе, февральдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Сез башкарган һәр эш алга таба да үссен, дәвамлы булсын!

– Хөрмәтле Камил Шамилевич! Шәхсән үз исемемнән һәм безнең коллектив исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихластан котлыйм, иң изге теләкләр юллыйм.

Көчле кеше теләсә нинди кыенлык килгәндә дә мөмкинлекләр күрә, дигән гыйбарәне хәтерлисез булыр. Ул Сезгә бик тә туры килә, чөнки Сез беркайчан да күңелегезне төшермисез, бик читен вакытларда да дөрес карарлар кабул итә, мәсьәләне чишү юлларын таба беләсез. Эшләгән эшегез өчен җаваплылык тоясыз, искиткеч эшлеклелек сыйфатларына ия булуыгызны даими раслыйсыз. Шуның белән беррәттән яңалыкны тоеп ала торган тынгысыз зат булып та каласыз. Шуңа да Сез башкарган һәр эшнең алга таба да үсүен, дәвамлы булуын телим.

Без Сезне уналты елдан артыграк Татарстан башкаласы мэры вазыйфасында эшләгән кеше буларак беләбез. Сез Казанны үстерү, бирядә яшәүче кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту өчен гаять зур өлеш керттегез. Сез халыкны иске торактан күчерү, бик күпләр шикләнеп караган Казан метросы кебек олы проектны тормышка ашыру буенча төп инициаторларның берсе булдыгыз. Болар барысы да – республика җитәкчелегенең зур ярдәме һәм Сезнең команданың тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Сез мәркәзебезне 1000 еллык бәйрәменә әзерләү барышында зур эш башкардыгыз. «Шаляпин Палас», «Кекин йорты» кунакханәләрен проектлаганда да, староверлар чиркәве белән лютеран кирхасын, И.И. Алафузов (Алафузов театры) Халык йортын, Рус православ староверлар чиркәве кафедраль соборы комплексын, Александр пассажын, шулай ук КФУның 26 объектын «Казан шәһәренең тарихи үзәген саклау һәм үстерү» федераль программасы кысаларында торгызганда да без чын мәгънәсендә эшен таңнан төзелеш мәйданнарында башлап, төн уртасында гына җитди шәһәр проблемаларын хәл итеп тәгәлләгән Мэрны күрдек. Сез кулыгызны бу киң колачлы хуҗалыкның пульсында тоттыгыз. Татарстан башкаласын үстерүгә керткән өлешегез бәяләп бетергесез!

Башкалабызга православ дине вәкилләренең изге ядкаре – Казан Изге Ана тәресен кайтару буенча да Сез башлап йөрдегез. Һәм, бәлки, нәкъ менә Сезнең католик чиркәү башлыгы белән булган очрашуыгыз һәм әйтелгән сүзләрегез дә бу карарны тизләтергә булышкандыр. Сез аңа: «Изге кешенең тәкъдире – ядкарьне кешеләргә күбрәк бәхет һәм игелек китерсен өчен, беренче табылган урынына кайтару», – дигән идегез.

Кайда гына эшләсәгез дә, Сезнең үз эш стилегез бар – проблеманы хәл итүдә төпле итеп якын килү, максатка ирешү хакына үз вакытыгыз һәм энергиягезне соң тамчысына кадәр сарыф итү, эшне җиренә җиткереп башкару, беренче чиратта, үзегезгә һәм хезмәткәрләрегезгә карата да зур таләпчәнлек. Сезне кул астында эшләүчеләргә аталарча кайгыртучанлык белән каравыгыз да аерып тора, һәркайсына теләсә кайсы вакытта ярдәмгә килергә әзерсез.

Сез бүген дә Татарстан үсеше хакына уңышлы хезмәт итүдән туктамадыгыз. Барлык эшләрегезнең дә уң булуын, яхшы кәеф телим, авыр ситуацияләрдә фикердәшләр белән иңдәшләрегез һәрчак янәшәдә булсын! Сез уйлап йөргән бәрәкәтле идеяләр һәрвакыт тормышка ашсын!

Чын күңелдән Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, оптимизм, иминлек телим.

«Елларым – байлыгым ул минем» дигән атаклы гыйбарәне нәкъ менә Сезнең кебекләрне күздә тотып әйтәләр. Һәм ул сүзләрдә чынлап та дөреслек бар икәненә төшенәсең. Сезнең бәяләп бетергесез эш тәҗрибәгез, казанышларыгыз, зирәклегегез, әйләнә-тирәдәгеләр белән урнаштыра алган кешелекле мөнәсәбәтләрегез – чын-чынлап олы байлык. Аны югалтырга мөмкин түгел!

Сезнең үзегезгә дә, якыннарыгызга да һәрчак уңыш юлдаш булсын!

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапромы» АҖ генераль директоры

Фото «Казан Гипронииавиапром»АҖнән алынды.

Реклама

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ генераль директоры,
февральдә үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Мәрьям Дәүләтшина,
ТРнда ВТБ (ГАҖ) банкы идарәчесе

Республиканың иҗтимагый үсешенә – лаеклы өлеш

– Хөрмәтле Леонид Витальевич! ТРнда ВТБ банкы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Без республика инфраструктурасын яхшыртуга йөз тоткан тармакларга һәрвакыт зур теләктәшлек белән якын килдәбез һәм ярдәм күрсәтәбез. Бу юнәлештә Сезнең кебек үз һөнәренең чын остасы булган шәхесләр белән хезмәттәшлек итү – үзе бер шатлык. Үз эшчәнлегегез белән Сез Татарстанның иҗтимагый үсешенә икеләтә өлеш кертәсез. Сезнең ныклы, тотрыклы җитәкчелек итүегез «Грань» ҖЧҖнә, күпләрне эш урыны белән тәэмин итеп, актив рәвештә үсәргә мөмкинлек бирә. Йортлар төзелеше тармагындагы үсеш векторлары Сезнең бизнеска карашыгызның коммерция, табыш алуга гына корылып калмыйча, киң колачлы булуын раслый. «Яңарыш» объектларын төзүдә катнашуыгыз гына да Сезгә һәм компаниягезгә карата зур ихтирам уята.

Сезгә яңа җиңүләр, тотрыклы үсеш һәм иминлек теләп калабыз. Үзара хезмәттәшлек өчен рәхмәт, алга таба да Сезнең белән эшлекле мөнәсәбәтләрне саклап кала алсак иде!

Реклама Фото ТРнда ВТБ (ГАҖ) банкы матбугат хезмәтеннән алынды.



Юлия Халитова,
«Инженерлык-төзелеш тикшеренүләре» ҖЧҖ генераль директоры

Ышанычлылык һәм төгәллек – профессионалларның төп сыйфатлары

– Хөрмәтле Леонид Витальевич, Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм! «Инженерлык-төзелеш тикшеренүләре» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә иң яхшы теләкләр юллап калам. Профессиональ осталык үрнәге һәм үзара уңышлы хезмәттәшлек өчен рәхмәт Сезгә. Безнең компания Сез эшләгән объектларны проектлауда катнаша алганына шат. Үз сүзегездә тора белү сәләте, ышанычлылык һәм исәп-хисаплардагы төгәллек – Сездәге бу сыйфатлар безнең өчен дә кадерле. Сайлап алган ышанычлы партнерларыгыз исемлегенә «Инженерлык-төзелеш тикшеренүләре»н дә кертүегез – безнең өчен зур дәрәҗә. Алга таба да уңышлы хезмәттәшлек итәргә насыйп булсын.

Сезгә киләчәктә киң колачлы проектлар һәм аларны тормышка ашыруда зур уңышлар теләп калабыз. Эшчәнлегегез һәрвакыт югары бәясен алып торсын. Сәламәтлек, бәхет юлдаш булсын! Максатларыгызга ирешеп яшәгез!

Реклама Фото «Инженерлык-төзелеш тикшеренүләре» ҖЧҖнән алынды.

Илгиз Гафиятов,
КМТТУ-КХТИның Нефть химиясе инжиниринг үзәге директоры, февральдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Тәҗрибәнең күпбаскычлы үрләре

– Хөрмәтле Илгиз Зыйниятуллович! КМТТУ-КХТИның Нефть химиясе инжиниринг үзәге коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәбез!

Татарстанда туып-үсеп, туган төбәгегезнең үсеше һәм чәчәк атуы хакына искиткеч күп көч куеп эшләдегез. 25 еллык тырыш хезмәт аралыгында «Түбән Кама Нефтехим» җитештерү берләшмәсендә төрле вазыйфаларга караган үсеш баскычларының барысын да уздыгыз. Һәр баскычта зиһенегезнең ни дәрәҗәдә үткен булуын күрсәтеп кенә калмадыгыз, ә профессионаллыкта ни дәрәҗәдә алга китүегезне дә һәрчак дәлилләп килдегез.

Сезнең биографиядә интеллектуаль мирасны тәшкил иткән фән белән мөнәсәбәтләр аерым бер урынны алып тора. Сез 100дән артык фәнни эш авторы: алар арасында 6сы – фәнни әсбап, икесе – фәнни монография. Алар чын мәгънәсендә үз өлкәсендә үрнәк санала торган хезмәтләр.

Ә икътисад өлкәсендәге тикшеренүләрегез белән фәнни хезмәтләрегез, аерым алганда «Институциональная природа корпораций в современной российской экономике» монографиясе дәүләт дәрәҗәсендә югары бәяләнде. Без, коллегаларыгыз һәм хезмәттәшләрегез, 2008 елның 21 мартында фән докторы дәрәҗәсенә ия дип табылуыгызны да зур горурлык белән кабул иттек. 2010 елның 20 октябрендә Сез шулай ук кафедра профессоры дигән фәнни дәрәҗәгә ия булдыгыз, «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» һәм «Россия Федерациясенең югары профессиональ белем бирүнең мактаулы хезмәткәре» кебек исемнәр алдыгыз.

Мәгариф өлкәсендәге алга карап фикер йөртә белү сәләтегез һәрчак зур ихтирам уята иде. Түбән Кама мәгълүмат технологияләре һәм коммуникацияләре институты директоры вазыйфасын башкарганда, нәкъ менә Сез әле мәктәп эскәмиясеннән башлап ук предприятиеләр өчен кадрлар әзерләү чылбырын грамоталы итеп оештырдыгыз. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау буенча Фәнни совет әгъзасы сыйфатында Сез үзегез туплаган бәһасез тәҗрибәне тагын 8 фән кандидатына тапшыра алдыгыз. Сезнең үзегез эшләгән шәхси фәнни эшләнмәләрегез һәм патентларыгыз турында да әйтми калырга ярамый. Алар барысы да файдалы модельләр дәрәҗәсенә җиткерелгән.

Сездәге инициативалылык сыйфаты иҗтимагый тормышта актив катнашуыгызга да этәргеч булгандыр. 2006 елдан Сез – Түбән Кама шәһәр Советы депутаты, 2016 елдан – Түбән Кама муниципаль районы депутаты һәм Түбән Кама муниципаль районының икътисадый үсеше буенча депутатлык комиссиясе әгъзасы. Бу вазыйфаларга алыну Сезнең туган төбәгегездә яшәүче халыкның иминлеге хакына эшләргә, үзегез туплаган тәҗрибә белән бүлешергә омтылуыгызны дәлилләп тора. Моны дәүләт җитәкчелеге дә күрә һәм югары бәяли: башкарган эшегез Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән билгеләнгән, алар арасында «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән Татарстан Республикасы Президентының Мактау хаты аерым урынны алып тора.

Без Сезнең ышанычлы җитәкчелек астында эшләвебезгә сөенәбез. Сез алып барган күпкырлы эшчәнлек безне дә зур эшләргә рухландыра, илһамландыра.

Киләчәктә Сезгә сәламәтлек һәм энергиягезнең саекмавын телибез!

КМТТУ-КХТИның
Нефть химиясе инжиниринг үзәге коллективы

Виталий Маргелов, генерал-полковник, Россия Федерациясенең Тышкы разведка хезмәте директорының оператив мәсьәләләр буенча элеккеге урынбасары

Бәяләп бетергесез хезмәт

– Юбилей белән, Илгиз Зыйниятуллович! Мин Сезне күп еллар дәвамында актив тормыш позициясе булган җаваплы кеше буларак беләм. Россия яшьләренең хәрби-патриотик үсешенә керткән өлешегез – бәяләп бетергесез.

Сезнең инициатива буенча оештырылган Советлар Союзы Герое Василий Маргелов исемендәге «Взлётная полоса» хәрби чакырылуга кадәрге әзерлек үзәгендә йөзләгән курсант тәрбияләнде, алар барысы да – курку белмәс егетләр. Шуларның 126сы һава-десант гаскәрләрендә хезмәт үтәп кайтты. 2008 елдан үзәккә йөрүче курсантларның Һава-десант гаскәрләре көнендә Мәскәүдәге Кызыл мәйданда Татарстан Республикасын тәкъдим итүләре дә – игътибарга лаек күренеш.

Сезнең «Россия десантчылары берлеге» күзәтчелек советы әгъзасы буларак, курсантларга юнәлеш бирүегез һәм алар белән бергә парашюттан сикерүегез дә зур ихтирамга лаек. Сезгә тапшырылган «Маргелов» кортигы да, «Армия генералы Маргелов» ордены да, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының мактау грамотасы да, «Россия десантчылары берлеге»нең «Хәрби-патриотик тәрбия» номинациясендә тапшырыла торган «Бакыр десантчы» премиясе дә хезмәтегезне һәм дәрәҗәгезне лаеклы рәвештә бәяләү ул.

«Россия десантчылары берлеге» күзәтчелек советы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә ныклы сәламәтлек, куйган максатларыгызга ирешеп кенә калмыйча, яңа үрләрне яулавыгызны теләп калабыз.

Валерий Востротин,
«Россия десантчылары берлеге» рәисе,
Советлар Союзы Герое, генерал-полковник

Фото КМТТУ-КХТИның Нефть химиясе инжиниринг үзәгеннән алынды.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

КЕЧЕ ЮЛДА – КЕЧЕ ЕЛГА

Лаеш районының Кече Елга авылына кузгалгач, котырып буран чыкты, хәтта юл күренми башлады. Ялгышлык белән Балык Бистәсе юлына кереп киткәнбез. Шулай итеп 70 чакрым араны ике сәгатьтә үттек. Кече Елгага килеп җиткәндә буран тынды. Ап-ак ябалдашлы агачлары белән каршы алды безне авыл.

Автор:
Руфия Фазылова

«ҖИДЕ ЕЛ КӨТТЕМ...»

Кече Елга белән Олы Елга авылы арасы ике генә чакрым. Ләкин беренчесе – Лаеш, икенчесе Балык Бистәсе районнарына карый. (Олы Елга дип язылса да халык аны «Юлга» дип йөртә.) Сугыштан соңгы елларда ике авылга бер мәктәп булган. Бүген исә ике авылда да урта мәктәп эшли.

Кече Елга авыл җирлегенә тагын ике авыл – Шуран, Полянка керә. Исемнәреннән күренгәнчә, алар рус авыллары. Аларда кеше саны аз. Мисал өчен, Полянкада җиде генә йорт бар. Дөрес, җәй көне «дачник»лар кайта икән. Кече Елга исә шактый зур авыл – биредә 717 кеше яши, 251 хуҗалык бар. Авыл төзек, аягында нык тора.

Кече Елганың үзәгенә килеп туктап, яңа ике катлы, зур хәрефләр белән «Театр» дип язылган бинаны күргәч, аптырап куйдык. Мондыйны әле күргәнебез юк иде. Бу бит Буа дәүләт драма театры, Әлмәт татар дәүләт театры биналары югарылыгында! Имәндә икән чикләвек! Баксаң, ремонттан соң авылның мәдәният йортына шундый исем бирелгән.

– Мәдәният үзәгебез бик начар хәлдә иде, – диде Равилә Кадыйрова. – Мәдәният йортларына капиталь ремонт ясау программасы

Фото: Лилиана Вәлитова

кысаларында 8 миллион сум акча бүлеп бирелде. Ләкин бинаны баштанаяк ясап чыгарга ул сумма җитмәде. Район башлыгыбыз Михаил Афанасьевка ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек. Ул, үз чиратында, Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка хат язды. Шулай итеп, тагын 8 миллион сум акча күчерделәр. Авыл өчен зур, тиңсез бүләк булды ул, рәхмәт яусын җитәкчеләребезгә...

Эш менә нәрсәдә икән: Кече Елга авылы мәдәният йортында күп еллар дәвамында Халык театры эшләп килә. Авыл кешеләре белән ел саен икешәр спектакль куялар икән. Режиссерлары – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Равилә Вәлиуллина. Театрның аерым бинасы моңарчы булмаган. Менә шуны сәбәп итеп, Президентка хат язганнар. Нәтиҗәдә мәдәният йорты «Театр»га әйләнгән. Чыннан да, бизәлеше, аерым театр почмагы булу аны башка мәдәният йортларыннан үзгә итә.

Разия апа Кашапова бүген кызы Илшат тәрбиясендә яши.

Кече Елганың тарихы белән кызыксынгач, авыл җирлеге башлыгы Лилия Кыямова безне Разия апа Кашапова янына алып китте. Ул 37 ел мәктәптә татар теле, әдәбияты укыткан. Бүген авылның иң өлкән бу кешесе инде 96 яшен тутырган икән. Разия апаның тормыш иптәше Габделхак абый да күп еллар Кече Елга урта мәктәбендә тарих укыткан. Сигез ел элек мәрхүм булган. Үзе исән чагында туган авылы турында бик күп мәгълүмат җыеп, туплап калдырган. Әтисенең хезмәтләрен кызы Илшат апа (әнисе шундый исем кушкан кызына) китап итеп чыгарган.

– Менә бу китапта барысы да бар, сеңлем, – диде Разия апа. – Кече Елга белән Олы Елга бер вакытта оешкан. Ике юл булган, берсе олы юл, икенчесе җәяүлеләр юлы. Абыйлы-энеле ике туган, кардәшләрен алып, берсе олы юлга, икенчесе кече юлга урнашкан. Бабайлар шулай сөйли торган иде. Тарихи документлар да шуңа ишарәли...

Менә шуннан аңлашыла да инде ни өчен авыл исемнәре Елга дип язылса да, халык арасында Юлга дип аталуы, дип уйлап куйдым мин.

Разия апа бүген кызы Илшат апа тәрбиясендә. Зыялы, бик мөләем апа. Шүрлектә берничә дистә китап тезелеп тора. «Укырга бик яратам», – ди ул.

Безгә аның язмышы зур сабак булды. 1944 елда сөйгәне белән никах укытып, рәсми рәвештә гаиләләрен теркиләр.

– Син укытучы, барыбер ач калдырмаслар, дип, Габделхак сугышка китәр алдыннан өйләнде миңа, – дип сөйләде Разия апа. – Аның ике кечкенә энесе, авыру әнисе бар иде. Минем дә үземнән кечкенә өч туганым бар. Шулай сигез җан бер гаилә булып сугышны кичтек. Ирем хезмәтен тәмамлап авылга 1951 елны гына кайтты. Ике арада гел хатлар йөреп торды. Менә шулар җылысы тормыш авырлыкларын күтәрергә көч бирде...

Бизәлеше, аерым театр почмагы булу Кече Елга авылы мәдәният үзәген башка мәдәният йортларыннан үзгә итә.

Шәвәлиевлар әниләрен бик хөрмәт итәләр. Вакыт табып, бергә җыелып килүләре үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

АНАНЫҢ ҖИДЕ УЛЫ

Кече Елга авылы җирлеге башлыгы Лилия Кыямова авылның тагын бер хөрмәтле кешесе – Маһирә апа Шәвәлиева янына да барырга тәкъдим итте. Җиде ир бала үстергән ана ул. Ә иң кызыгы һәм гаҗәбе – җиде улы да Кече Елга авылында төпләнеп калган. Бүген инде иң кечкенә дигәненә дә 35 яшь. Кече улы Илнурны санамаганда, барысының да гаиләләре бар. Тагын бер кызык мәгълүмат – киленнәр дә Кече Елга авылыныкы!

Маһирә апага 78 яшь. Ул әле һаман да тормыш арбасын булдыра алганча тарта. Бакчасында ел саен йөз баш помидор, кыяр, башка төр яшелчә үстерә. Аннан уңышны җыеп алып, банкаларга яба. «Әни тозлаган кыяр-помидорларны әле дә килеп ашыйбыз. Хатыннарыбызның да аныкы кадәр кадәр килеп чыкмый», – диде уллары.

– Маһирә апа, улларыңны барысын да янында калдырырга ничек үгетләдегез? – дидем.

– Әллә тагын... Читкә китәргә дип уйлап та карамадылар алар. Үсә тордылар, авылдан җир алып, йорт сала тордык.

– Мәрхүм әти һәрберебезне йортлы итеп калдырды, – дип сүзгә кушылды әбинең иң өлкән улы Нургали абый. – Карап торып нигез казытты. Аннан өйне энекәшләр белән бергәләп салдык. Төп нигез белән бергә җиде йортны шулай бергәләп эшләдек, читтән кеше чакырмадык.

Малайларның һәркайсының яшь аермасы ике ел. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, җиде бала, өстәвенә барысы да – малайлар... Күп кебек! Тик Маһирә апа балаларыннан бер дә зарланмады:

– Кызларны алыштырырдай булдылар: күземә генә карап тордылар, – диде.

– Алай җиңел генә булмый бит ул, балалар үскәндә сугыша да, тавыш та чыгара, – дим.

– Алары булды инде. Тик минем талкан коры иде. Тәртипсезләнә башласалар, тотам да эш өям. Селкенергә дә вакытлары калмый. Тыңламасалар, хәзер эләктереп алам...

– Әниегез усал идеме? – дим төп йортка җыелышып килгән улларга.

– Усал түгел, әтидән күбрәк курка идек без, – диделәр.

Улларының күңелендә берничә тирән уелып калган вакыйга да бар булып чыкты. Шулай бервакыт язгы ташу вакытында Нургали исемлесе аздан гына суга агып китмәгән икән.

– Безнең артта гына инеш бар, – дип сөйләде Нургали абый. – Без кечкенә вакытта тагын да зуррак иде. Менә шул инеш язгы ташу вакытында ярыннан ташып ага. «Суга якын бармагыз», – дип әни гел әйтсә дә, тәки бардым бит. Ничек суга агып киттем, үзем дә аңламадым...

– Әле ничек батып үлмәгән диген, Алла саклагандыр, күрәсең, – дип сүзгә кушылды Маһирә апа. – Куркудан, ачудан резин итеге өзелеп чыкканчы ярдым. Энеләре күреп торды. Аларга да сабак булгандыр.

Шәвәлиевларның барысы да әтиләре юлыннан киткән – тракторчыга укып, озак еллар механизатор булып эшләгәннәр. Колхозлар таралып, эш беткәч кенә төрлесе төрле хезмәткә күчкән. «Капка төбенә алтышар трактор кайтып туктаган чаклар бар иде», – диделәр.

Механизатор дигәннән, Маһирә апа тагын бер кызык очракны әйтеп шаккатырды: өйләнгәнче, улларының акчасы бары аналарында торган. «Мин аларның хезмәт хакларын «кәнсәләр»дән үзем барып ала идем», – диде.

Шәвәлиевлар әниләрен бик хөрмәт итәләр. Бу бөтен нәрсәдә чагыла: Маһирә апаның күзенә карап, ул сөйләгәндә бер ярату белән тыңлап торалар. (Вакыт табып, бергә җыелып килүләре үзе үк күп нәрсә турында сөйли). Безгә дә: «Әнине хөрмәтләп килүегез өчен зур рәхмәт», – дип кат-кат әйттеләр. Хатыннары да үзләре кебек булып чыкты – рәхәт кешеләр. Уйнап-шаярып сөйләшәләр, өйгә кайткандай тоясың үзеңне.

– Без әнигә бик рәхмәтле, – диде киленнәрнең берсе Фәридә апа. – Шәвәлиевларның кайсын гына алсаң да, хатын-кызга хөрмәт белән карыйлар. Куллары да җиңел, эшкә дә батырлар: өчпочмакка кадәр пешереп ашатырга мөмкиннәр.

Җиде бала анасының юмартлыгы турында да әйтми калу дөрес булмас. Кем килсә дә – чәе кайнаган, ризыгы пешкән. Олы Елга авылындагы йорты янгач, бер хатын аларда ике ел яшәгән. Әле без килгән көнне дә Кече Елгага эшкә килгән бер ир-ат тукталган булып чыкты.

– И, Илнур эштән кайткан төшкә ашарга барыбер пешерәм, – диде Маһирә апа. – Барыбыз да кешеләр. Болын хәтле йортта урын җитә бит.

«ДӨНЬЯ – МАТУР!»

Кече Елгада фермер булып теркәлгән Эдик Зарипов хуҗалыгы бар. 29 баш мөгезле эре терлек тота ул. Биредә күпләп кәҗә асрыйлар. Җәйләрен – йөз, ике йөз баш кош-корт асрау авыл халкы өчен гадәти хәл икән. Тик без бу бу юлы авыл хуҗалыгына кагылмаска булдык. Кече Елганың кешеләре үзенчәлекле тоелды. Аларның берсе турында язып, икенчесен аерып калдыру бик үк дөрес булмас, дип уйладык.

Тумыштан ДЦП диагнозы булган Венера Хәсәнова турында авылга килгәнче үк ишеткән идек. Шигырьләр яза ул, сөйләннән картиналар ясый. Тагын әллә нинди матур әйберләр дә бәйли булып чыкты.

– Үсә-үсә үземнең халәтемә башкача карый башладым: Аллаһы Тәгалә һәр кешегә төрле сынау бирә, – ди Венера Хәсәнова. Рәсемдә – аның кул эшләре.

– Тыйнак, сабыр һәм бик зәвыклы, – диделәр безгә аның турында.

Бибинур апа белән Нургали абый Хәсәновлар өч кыз үстергән. Венера – уртанчысы. Олы кызлары Алсу – кияүдә, балалар үстерә. Кечесе Эльмира – Казанда, ә Венера әти-әнисе янында Кече Елгада яши. Хәер, ул да бер елдан артык Казанның «Ярдәм» мәчете кибетендә эшләгән. Әти-әнисе янына көзен кайткан.

– «Ярдәм» мәчетенә тагын чакыралар, бәлки барырмын да, – диде Венера.

Хәсәновларның йортлары да үзләре кебек нурлы. Аналы-кызлы намаз укыйлар. Үзләре әйткәнчә, һәр көнгә сөенеп яшиләр.

– «Ярдәм» мәчетенә баруымның сәбәбе – намазга өйрәнү иде, – диде Венера. – Мин аннан икенче кеше булып кайттым, рәхмәт «Ярдәм» мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитовка, аның ярдәмчесе Мәликә ханым Гыйльметдиновага. Әле ярый алар кебек кешеләр, үзәкләр бар. Гарипләр дөньясы бик катлаулы. Аны аңлау бөтен кешенең дә хәленнән килми. «Ярдәм» мәчетенә баргач, күп кенә дусларым барлыкка килде. Алар белән Интернет аша аралашам.

Әйткәнемчә, Венера шигырьләр яза. Үсмер чагында ук кулы каләмгә үрелгән. Беренче китабы 2011 елда дөнья күргән. Инде тагын бер китаплык шигырьләре җыелган. Тик әле аны нәшер итәргә мөмкинлеге юк. Бәлки иганәчеләр килеп чыгар, дип өметләнә.

Венера мәктәпкә йөрмәгән, укытучылары өйгә килеп укыткан. Шуңа карамастан, авылда аны һәркем белә, якын итә. Кече Елга мәдәният йортында узган концерт-кичәләрдән калмый, коляскасы белән үзе генә дә бара. Авылдашлары килеп тә ала икән.

– Яшьрәк чакта ни өчен мин башкалар кебек урамга чыгып, алар белән йөгереп йөри алмыйм, дип елый идем, – дип сөйләде Венера. – Тик үсә-үсә үземнең халәтемә башкача карый башладым: Аллаһы Тәгалә һәр кешегә төрле сынау бирә. Миннән дә авыррак хәлдәге кешеләр бар. Әле мин, таяк белән булса да, йөри алам, ашарга әзерлим. Әти-әнием, туганнарым исән-сау. Дөнья – матур!..

Кызның сәйләннән ясалган картиналарын күреп тә сокландык. Бу шөгыльгә «Ярдәм» мәчетендә өйрәнеп кайткан. Гыйнвар уртасында Кече Елга авылы мәдәният йортында Венераның кул эшләреннән торган күргәзмә дә эшләгәннәр.

Без килеп киткәннән соң, үзешчән шагыйрәнең күңелендә шигырь туган.

Яңабаштан гашыйк булдым әле,
Гашыйк булдым яңа көнемә.
Гашыйк булдым яңа яуган карга,
Һәр бөртеге матур күренә...

Гел әзләнүдә, үсештә булган Венерага киләчәктә дә уңышлар телим! Юлында яхшы кешеләр генә очрасын...

P.S. Кече Елга авылында алган тәэсирләр җылысы Казанга кайткач та җитте. Дөньяда шундый кешеләр булганга, тормыш дәвам итә.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

«Идел һәм Чулман елгалары буенда борынгы кабиләләр моннан 40 мең ел элек яши башлаган. Безнең эрага кадәр VIII йөздә Чулманның уң як ярында борынгы кабиләләр яшәве билгеле (Ананьино культурасы). Алар яшәгән шәһәрлекләр хәзерге Кече Елга, Саескан Бистәсе, Шуран, Имәнкискә авыллары территориясенә кергән.
Болгар дәүләтенең төзелүе оешуы бу урыннарда яшәүче халыкка зур йогынты ясый. Тарихи мәгълүматларга караганда, аның гомуми территориясе Идел, Чулман елгалары буйлап еракка сузылган. 1236 елда Биләр шәһәре Алтын Урда тарафыннан җимерелгәч, Биләрдә яшәүче халыкның бер өлеше Чулман елгасының уң як ярына – Кашан каласына күченә. Кече Елга авылы тарихта мәгълүм Кашан каласы белән турыдан-туры бәйле.

Кашан каласы Алтын Урда ханы Тимер Булат (1393 ел) тарафыннан тиешле салымнар түләмәгән өчен җимертелә һәм элекке куәтенә кире кайта алмый. Кашан каласыннан 7–8 чакрымнарга төньяктарак исеме билгесез болгар авылы урыны бар. Бу авылдан Кашан каласына ике юл илтә: җәяүле сукмак һәм зур ат юлы. Кашан каласы җимерелгәннән соң, Тимер Булат гаскәрләре ул авылны да аямый. Туздырылган авылдан исән калган кешеләр Кашан каласына илтә торган ике юл чатына барып урнаша. Шулай итеп берьюлы ике авыл – Олы Елга, Кече Елга оеша».

Габделхак Кашаповның «Татарстанның Лаеш районы Кече Елга авылы тарихы» китабыннан.

ТАТАРСТАН-2019: ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘР БУСАГАСЫНДА

Лариса Усманова, астролог, 2019 елда Татарстанныниләр көтүе турында

ТОРМЫШКА АШКАН **ФАРАЗ**

Һәрбер фараз беренче чиратта шуның белән кызыклы – тормышка ашамы ул, юкмы? Узган ел фаразларын ачабыз да тикшереп карыйбыз. Без 2018 елда республика көчле басымга дучар булачак һәм 30 ел элек яуланган суверенитетның бер өлешен югалтачак, дигән идек. Фараз чынга ашты: милли мәктәп реформасы, татар теленә басым, вәкаләтләрне киметү.

Июнь-июль айларында Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты үткәрелү республиканы туризм үсешендә яңа баскычка күтәрде, аны бөтен дөнья җанатарлары яхшырак белә башлады – бу фараз шулай ук тормышка ашты.

Күп кенә астрологлар Марсның ретроградлык чорында озак вакытлы перспективасында сугыш хәрәкәтләре башланудан курыккан иде. Шөкер, аңа ук барып җитмәде. Шулай да хәрби риторика һәм куркытулар – хәтта атом коралы куллану дәрәҗәсендә үк – җитәрлек булды.

2019: ФИНАНС РЕФОРМАЛАРЫ ЕЛЫ

Хәзер инде башланып килгән яңа елга күчәбез. 2019 ел, шаять, дөньяга хәрби хәрәкәтләр куркынычын китермәс. Әмма 2019 ел финанс өлкәсендә чыннан да җитди реформалар елы булачак. Моның башлангычы 1918 елның май уртасыннан августка кадәрле чорда ук салынган иде, ләкин яртылы елга тукталып торды. Безнең әле 2019 елның мартыннан башлап, ел ахырына кадәр, бәлки июль һәм декабрьдә көчәергә мөмкин булган финанс кризисы алдыннан тәнәфес ясап алу мөмкинлеге бар. Июльдә җимерелү дулкыннары булып узачак, ә декабрьдә финанс мөнәсәбәтләренең яңа моделе туачак.

КАТЛАУЛЫ АЙЛАР: ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЭЛЕМТӘЛӘР

Республика өчен гыйнвар һәм июль катлаулы булачак. Транспорт өлкәсендә һәм халыкара элемтәләрдә тотрыксызлык күзәтелергә мөмкин. Әмма 2019 ел ахырында, ниһаять, югары тизлекле тимер юл магистрале транспорт проектын тормышка ашыруга старт бирeләчәгe фаразлана.

ХАКИМИЯТ: НЫГЫТУ МАКСАТЫ БЕЛӘН ҮЗГӘРЕШЛӘР

Әгәр хакимият 2018 елда аягында басып калган икән, 2019 елда да калачак.

Хәтта федераль дәрәҗәдә җитди үзгәрешләр булу ихтималлыгына да карамастан. ТРда хакимият вертикале үзгәрүне 2020 елда гына көтәргә мөмкин, 2019 елда үзгәрешләр булачак, ләкин гамәлдәге структураны ныгыту максаты белән генә.

ЯҢА ЦИКЛНЫҢ БАШЛАНУЫ: ӘЗЕРЛЕК ЭТАБЫ

Гомумән алганда, ел бик әһәмиятле 2020 елга – яңа 60 еллык цикл башлануга әзерлек булачак. 1989, 2007 һәм 1995 елларда ниләр булганын исегезгә төшерегез. Шундый ук вакыйгалар, әмма бер әзлеклелеккә тупланган хәлдә, югарырак дәрәҗәдә 2019 елда кабатланырга мөмкиннәр. Без җитди үзгәрешләр бусагасында торабыз, аларның кайберләре 2019 елның икенче яртысында башланырга мөмкин, әмма 2020 елда алар инде һичшиксез үз көченә керәчәк. ■

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

2019 ел. Компьютерда җыю.
Офсет басма. ТГЖН.

Луиза Шарова фотосы

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый



1975 ел. Кайнар ысул белән хәреф җыю.
Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы музее.

Александр Ефремов фотосы

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ